PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2019 СЕНТЯБРЬ № 9

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ӨЙ ҖЫЕШТЫРУ СЕРЛӘРЕ
дөрес гадәтләр

БАЛАДАН КӨНЛӘШӘМ
кем артык: минме, улмы

СОЛЫ КӨРПӘСЕННӘН... КОЙМАК
зифа булыйм дисәң

Рима САФИУЛЛОВА:

АВЫЛЛАРНЫ ҮЗГӘРТЕРГӘ ТЕЛИМ!

Ак Барс
Банк





Барсик белән дуслары цивилизацияне коткара



Беренче сыйныф укучылары өчен татар һәм рус телләрендә өйрәтү уены



Уенны App Store һәм Google Play Маркетыннан телефонга түләүсез урнаштырып була. Шулай ук компьютерда браузер версиясе — game.akbars.ru

- Ак Барс Банкының «Беренче сыйныф укучысына бүләк» проекты 1997 елдан бирле Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән гамәлгә ашырыла
- Биремнәр беренче сыйныф укучыларына логик фикерләү, сизгерлек сәләтен һәм игътибарын үстерергә, тирә-юнь хакында яңа белемнәр үзләштерергә ярдәм итә

«АК БАРС» БАНК ААҖ. РФ ҮБ тарафыннан 12.08.2015 бирелгән 2590 номерлы генераль лицензия.

РЕКЛАМА

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото : Софья Богданова

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Рима Сафиуллова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 5.09.2019 ел.
Заказ О-2411
Тираж 4982

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



Илсөяр ИКСАНОВА

Әбиләр чуагы

I

Җирдә әбиләр чуагы –
Очалар пәрәвезләр.
Имәннәрнең яфраклары –
Утлы карашлы күзләр.


Толымнар алтын чулпылы
Талларда, юкәләрдә.
Миләшләрнең хисе яна –
Гашыйклар микән әллә?

Каеннар моңлы җыр суза
Мәхәббәт исеменнән.
Ак толымлы иртәләрдә
Җәй кызы яшеренгән...

II

Һаваларда җилбер яфрак исе,
Һаваларда дымлы җир исе.
Соңлап килгән бу җылыга сөенеп,
Озак-озак килә яшисе.

Үрмәкүчләр пәрәвездән үрә
Ефәк шәлләренең бизәген.
Миләшләр ут дөрли,
әбиләрнең
Җылытырга теләп соң җаен.



Кояш нурын эчә күбәләкләр –
Әйтерсең лә алда – мең гомер.
Бу яктылык җирдә мәңгелектер,
Бу җылылык җирдә мәңгедер!

Кошлар белә ләкин:
әбиләрнең
Җәе кыска, озын кышлары.
Җылы җәйне эзләп китеп бара
Төркем-төркем урман кошлары.

Безнең җәйләр инде артта калды,
Бөресенә посып талларның.
Чит якларның җылы җәйләре дә
Җылыта алмас сезне, җаннарым.
Мин бу кадәр асыл көзне ташлап
Китә алмас идем, кош булсам.
Әбиләрнең җәе озын булсын! –
Килми торыр идем, кыш булсам!..

Мадияр Хажиев эше. «Авыл. Көз.»

Безнең тышлыкта

20



«Эш кушканда тавыш күтәрсәң, кычкырсаң, сине, әлбәттә, берәү дә тыңламаячак. Эшләсә дә, җиренә җиткереп эшләмәячәк. Ә мин мактыйм! Бөтенебезгә дә яхшы сүз кирәк бит...»

«Мин көчле булырга тиеш...»
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6 Эшче һөнәрләр трендта булырмы?
Чулпан Галиәхмәтова

10 Кояшка үрелүче көнбагыш
Гөлнур Сафиуллина



14 Мәдәният – кешелек сакчысы
Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпованың тормыш кагыйдәләрен Чулпан Галиәхмәтова әзерләде

24 Җыештырыр өчен – туздырабыз?!
Раилә Хәялиева

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы




28 «Сайлаганым гомерлек»
Мәдинә Авзалова

Мәдәни тормыш



32 «Күкрәгемнән кошлар очырам...»
Нәзифә Кәримова



38 Калайчы Кәлүк
Асия Юнысова

Яшәеш

46 «Минем мәктәп – дөньяда бер!»
Эльмира Закирова



50 Ирландия
Айсинә Минһаҗева

Хатын-кыз галәме



60 Авар хинкале



62 Зифаларга – солы коймагы

»

Казанда үткән «WorldSkills» һөнәри осталык буенча 45 нче Дөнья чемпионаты эшче профессияләренә башка күзлектән карарга мәҗбүр итте. Бездән бигрәк, балаларыбыз үзләренә яңалык ачты кебек. Үсмер кызым, чемпионат уза торган мәйданнарны карап кайтканнан соң, бик җитди итеп: «9 нчы сыйныфны тәмамлап та һөнәр алып була икән бит. Алар әле кызыклырак та кебек. Ник сез миңа ул хакта да сөйләмисез, һаман институт дисез. Миңа табиб буласың дип башка әйтмәгез! Һөнәрне үзең уйлап, йөрәк белән сайларга кирәк икән», – дип безне кисәтеп куйды. Фәлсәфәгә бирелеп, гламур тормыш хакында сөйләшергә яраткан түгел, ә бәлки үз куллары белән нәрсә дә булса булдыра ала торган яшьләрне күреп, аның күзләре янды. Без, ата-аналар да, аңладык кебек: уңышка ирешү өчен берничә диплом кирәк түгел, ә бары тик үз эшеңнең остасы булу зарур. Дәүләт сәясәте генә һөнәри осталарны үги итмәсен...



ЭШЧЕ ҺӨНӘРЛӘР ТРЕНДТА БУЛЫРМЫ?



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Өлкәннәр сөйләве буенча, 50–70 нче елларда эшчеләр дан пьедесталында булган. Хөрмәт, лаеклы хезмәт хакы, социаль гарантияләр... Ә иң мөһиме: аларны бушлай фатир белән тәэмин иткәннәр. Тик үзгәртеп кору елларында күпчелек завод-фабрикалар яңа эш системасына күчә алмады. Ягъни дәүләт заказларын үтәүдән китеп, мөстәкыйль эшчәнлек алып баруга җайлашмады. Еллар буе хезмәт хакы күрмәгән кешеләр яраткан эшләрен ташлап, башка өлкәләргә күчәргә мәҗбүр булды. Илдә шәхси эшмәкәрләр катламы барлыкка килде. Заводларда тәртип урнашып өлгергәнче яңа буын үсте. Ата-аналарының хезмәт хакы ала алмый интегүләрен онытмаган, үсмер елларында бәрәңге (анысы да авылдан килсә генә!) белән ипи генә ашап яшәргә мәҗбүр булган балалар, билгеле, зур көндәшлек булуга карамастан, алга киткән өлкәләрдәге хезмәт хакы күп түләнгән һөнәрләр сайлады. Шул рәвешле, кайбер гаиләләрдә буыннан-буынга килгән эшчеләр династиясе өзелде. РАНХиГС гамәли икътисадый тикшеренүләр институтының өзлексез белем бирү икътисад үзәге үткәргән сораштырулар нәтиҗәләренә күз салсак, ата-аналарның 71,7% ы баласы нинди дә булса югары белем алырга тиеш дип саный. Балалар үзләре дә әти-әниләрнең бу фикеренә альтернатива тудыра алмый. Россия Мәгариф министрлыгының «Киләчәккә билет» проекты кысаларында уздырган сораштырулары шуны күрсәткән: мәктәп укучыларының 90% ы нинди һөнәр үзләштерәчәген,

һөнәри ориентлашу буенча кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген белми. 90 нчы елларда башланган бум әле һаман да үзгәрми. Ул вакытта яшьләр, бигрәк тә аларның ата-аналары югары уку йорты дипломы артыннан куа башлады, чөнки кешелек кыйммәтләре һәм дөньяга караш формалашуга Көнбатыш мәдәнияте экспансиясе йогынтысы башланды. Кино һәм сериаллардагы геройлар – банк хезмәткәрләре, адвокатлар, бизнесменнар. Эшчеләр күренеп алса да, алар уңышсыз бер кеше итеп сурәтләнә. Шул ук хәл җыр клипларында да: кыйммәтле машиналар, йортлар, матур тормыш... Аларда төп элемент – байлык. Ә эшче һөнәр иясе экран кумирына охшар өчен зур күләмдә акча ничек тапсын? Бу мөмкин түгел! Димәк, югары белемле булу мөһим дигән нәтиҗә ясала. Ихтыяҗ булгач, тәкъдимнәр дә булдырылды. Ул елларда нинди генә исемле уку йортларының филиаллары барлыкка килмәде. Балаларының белемен раслаган кәгазь алыр өчен ата-ана соңгы акчаларын институтларга илтеп тапшырды. Тик ул уку йортлары әзерләгән юрист, менеджер, икътисадчыларны эш урыны белән тәэмин итүне дәүләт кенә кайгыртмады. Бу хәтле кадрлар аңа кирәк тә түгел иде. Әлеге дипломлы белгечләр бәхетенә хезмәт күрсәтү сферасы киңәя башлады. Андагы хезмәт урыннары аларга эшсез калмаска ярдәм итте. Шул рәвешле, югары белемле официантлар, маникюр осталары, массажистлар, супермаркет эшчеләре барлыкка килде.

Һөнәр ияләренә ихтыяҗ булса да, яшьләр бу өлкәгә барырга атлыгып тормый. Ә производствода югары квалификацияле эшче кадрларга кытлык турындагы хәбәрләр даими ишетелеп тора. Моның сәбәбе тагын шул ук дөнья токтасы – акчага килеп төртелә. Эшче һөнәре алган яшь белгечнең әле тәҗрибәсе юк, шуңа күрә квалификациясе дә югары булмый. Шунлыктан хезмәт хакы да башка һөнәр вәкилләренекенә караганда түбән. Дөрес, авыр, кара, перспективасыз эш башкаручылар күбрәк акча алырга да мөмкин. Тик алар якты киләчәкне, ай-һай, күрер микән? Яшьлек белән сәламәтлек мәңгелек түгел, ә мондый «эш тәҗрибәсе»

Җәмгыятьтә эшчеләргә **аз хезмәт хакы алган** икенче сортлы кеше итеп карау гадәте әле дә бетми.

киләчәктә һөнәри осталыкны арттырырга ярдәм итми, билгеле. Шуңа күрә нинди дә булса һөнәр үзләштерү – кеше тормышында бик мөһим! Хезмәт шартлары да эшче һөнәрләргә ихтыяҗ түбән булуның бер сәбәпчесе булып тормый микән әле? Смена буе тузанлы һәм шау-шулы цехта станок артында басып торган яшь слесарь да, чиста, тыныч офиста, кулыннан телефоны төшмәгән (җай чыкканда социаль челтәрләргә селфи куярга кирәк бит!) гади вазыйфалар башкаручы да бер үк хезмәт хакы ала икән, һөнәр сайлауда бизмәннең кайсы ягы басачагына һичкемнең шиге юк.

Бүген югары уку йортлары дипломнары һөнәри ихтыяҗның гарантиясе булып тормый. Superjob порталы мәгълүматлары буенча димломлы белгечләрнең 80% ы эшкә урнашканда каршылыклар белән очраша, 40% ы эш тәҗрибәсе булмаганга, сайлап алуны узмый. HeadHunter интернет-рекрутмент компаниясе исә кызган майга су сала. Компания фаразлары буенча якын елларда эшче һөнәр ияләре югары хезмәт хакына дәгъва итә ала. 2018 елда һөнәри осталыклары булганнарга сорау 205% ка арткан. «Работа России» вакансияләр базасына кереп карасак: илдә һөнәр ияләре арасында иң зур хезмәт хакы алучы – эретеп ябыштыручы. Айга 100 мең сумнан ким түгел. Казанда электрогаз эретеп ябыштыручыга 117 мең сум вәгъдә итәләр. Шулай ук металл конструктор җыю буенча V разрядлы слесарьга да аена 100 мең сумга кадәр түлиләр, кран машинистына да 90 мең бирәбез диелгән. Дөрес, мондый төр белдерүләр әлегә бик аз, әмма алар бар.

Ниһаять, ил өчен яхшы фал барлыкка килә башлады. Россиядә эшче һөнәрен үзләштерергә теләүчеләр саны арта. Россия Мәгариф министры Ольга Васильева

Фикер



Анна ПРОКОПЕНЯ,
кондитер, WorldSkills Champion Trustта Европа вәкиле:

«...Камиллеккә юл кызыксынудан башлана, әмма дөньядагы бар өлкәне дә колачлап бетереп булмый. Билгеле бер вакытта без сайлау алдында калабыз: кем булырга? Сез үз юлыгызны сайлаганда йөрәк белән уйладыгызмы, әллә акыл беләнме? Мин кондитер булырга карар кылдым. Кайберәүләр вакытыңны бушка уздырасың, мөмкинлекләреңне юкка сарыф итәсең, бу бик гади шөгыль, диделәр. Ләкин мин үземдә бер кисәк торт белән башкалар тормышын яхшыртa алырлык көч тойдым. Бу көчне һөнәри осталык, эчтә булган дәрт бирә. Әйдәгез, аны кулланыйк та, дөньяны үзебез теләгәнчә үзгәртик...»

Фото: WorldSkills International

Фото: www.pixabay.com

PRESSA

Елдан-ел ихтыяҗ арткан югары квалификацияле эшчеләрне гастарбайтерлар белән алыштырып булмаячак.

белдерүенчә, соңгы ике елда 9 нчы сыйныфны тәмамлаучыларның 60% ы укуларын урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Дөрес, монда укучылар һәм ата-аналарның котын очырган бердәм дәүләт имтиханнары да роль уйнамый калмагандыр. Анысы – икенче мәсьәлә. Ә ил өчен бу – яхшы яңалык. Димәк, Россия ипи пешерүче, механик, слесарь кебек бүген кытлык булган белгечләргә, ниһаять, байый.

Әле тагын берничә елдан халык телендә «Путин балалары» дип йөртелгән буын үсеп җитүен искә алсак, урта звено уку йортларында абитуриентлар саны бермә-бер артачак. Россия Мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, урта һөнәри белем бирүдә иң популяр юнәлешләр: пешекче-кондитер, автомеханик, эретеп ябыштыручы, чәчтараш, электромонтер, цифрлы мәгълүмат эшкәртү буенча мастер, локомотив йөртүчесе, авиадиспетчерлар. Түрәләр белдерүенчә, бүген ил икътисадына нәкъ менә әлеге кадрлар кирәк. Алар «табылмый» икән, якын киләчәктә илдә эшләргә кеше калмаска мөмкин. Дәүләт бу юнәлештә әкрен генә булса да, кыймылдый башлады. Укучылар һәм ата-аналарны урта һөнәри белем бирү йортлары ул кадәр үк куркытмый хәзер. Элек, начар билгеләр ала башласак, акылга килергә әти-әниләрнең бер сүзе җитә иде: «Укымасаң, әнә, ПТУга барырсың». Шәхсән мин үзем ул уку йортын шпаналар шыплап тулган, куркыныч бер урын итеп күз алдына китерә идем... Хәзер ил, аеруча Татарстан, бу учреждениеләрнең имиджы өстендә эшли. Алар – бай материаль базасы булган ресурс үзәкләр. Казан халык сәнгате һөнәрләренең техникумы директоры Раушания Сәүбанова әйтүенчә, кепкасын кырын салган, киң ыштан кигән, директор белән сөйләшкәндә тәмәкесен дә авызыннан алмаган студентлар, бәлки, башка төбәкләрдә бардыр, ә Татарстанда алар юк.

– Безгә аттестатларында «дүртле», «бишле» билгеләре булганнар гына килә. «Өчле» билгесе белән колледжларга керә алмыйсың. Техникумга укырга керү өчен конкурс зур. Мәсәлән, дизайнга бер урынга – 5, ювелир һөнәрен үзләштерү өчен – 2,5 кеше. «Элек үзебездә укырга алу өчен балаларны урамнан эзләп, җыеп йөри идек. Әле 2010 елда гына да шулай иде бу. Дөрес, ул вакытта техникумның материаль базасы начар иде. Хәзер абитуриентларның ата-аналары безгә керәләр дә, бу бит музей, дип гаҗәпләнеп йөриләр. Мохит тудыру, мастерларның белемен әледән-әле арттырып тору кирәк. Бала, кызыгып, үзе укырга килергә тиеш. Безнең техникумнан җәмгыятьтә кирәк булмаган һөнәр ияләре чыкмый, – дип сөйли Раушания Сәүбанова. Ул үзе дә заманында СПТУ тәмамлаган. Педагогика институтына укырга кергәч, әнисе авырып китеп, аны карарга кайта. Авылда өч ай торып килүенә, аны институттан чыгаралар. Аптырап тормаган, слесарь-шлифовщик булып эшкә урнашкан да, СПТУга укырга кергән. «Менә шуннан күтәрелдем. Бу хакта һәр сентябрь саен укучыларга да сөйлим. Урта һөнәри белем бирү учреждениесендә укуның бер ояты юклыгын төшендерергә тырышам. Башында акылы булганнар «мин булдырам, укыйм» дип, үзенә максат куя. Хезмәт белән кеше күтәрелә генә, ул начарга илтми», – ди Раушания Кыяметдиновна.

Илдә башланган WorldSkills хәрәкәте дә эшче һөнәр үзләштерүчеләргә зур мотивация булды. Әнә кичәге укучысы Фәнүр Вәлиуллин Россия буенча үткән «Яшь һөнәрчеләр» бәйгесендә «ювелир эше» компетенциясендә чемпион булды. Ә бит заманында аздан гына ялгыш юлга басмый калган... Бүген ул – квалификацияле иң уңышлы яшь белгечләрнең берсе. Үзе чемпионатка укучылар әзерли. Җитмәсә, үз брендын ачу турында хыяллана. «Максатыма таба барам инде... Зур эшләр кечкенә станоктан башлана. Заказлар кабул итә башладык», – ди Фәнүр. Кулы эш белгән белгеч инде беркайчан да югалмаячак. Дөрес, барлык эшче һөнәрен үзләштергәннәр дә әлеге дөньякүләм хәрәкәткә кереп китә алмый.

Техникум кебек урта звено уку йортын тәмамлаганнар аның тагын бер плюсын әйтәләр. Арча районы егете Илгизәр Хөсәенов, мәсәлән, медицина колледжында белем алган. «Кыска вакыт эчендә әзер белгеч булып чыктым да, үз көнемне үзем күрә башладым», – ди ул. Хәзер ул үз белгечлеге буенча да эшли, медицина юнәлешендә читтән торып белем дә ала. Киләчәктә табиб-реабилитолог булырга тели. Олы тормышка беренче адымын урта һөнәри белем бирү учреждениесенә таба ясаган амбицияле, актив яшьләр уңышка ирешми калмый, чөнки беләләр: арттан этүче юк, үзләренә тырышырга кирәк! Беренчедән, алар әкренләп карьера баскычы буйлап күтәрелә ала дип саный белгечләр. Производствода карьера ясау өчен белем дәрәҗәсеннән бигрәк, һөнәри осталык таләп ителә. Вузларда белем бирү процессы теориягә нигезләнсә, урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә гамәли эшкә игътибар зур. Бу исә хезмәт базарында бик мөһим. Тәҗрибә туплаганнан соң, югары уку йортына барып кергәч, эшчегә белем алу күпкә җиңелрәк, чөнки ул үз һөнәрен инде практикада белә. Дөньяви риск-менеджер Нассим Талеб белем алуның мондый алгоритмы күпкә нәтиҗәлерәк дип саный. Икенчедән, үзләштергән профессияң буенча үз эшеңне ачарга яки үзмәшгуль булырга мөмкин, чөнки кулың эш белә – тәвәккәллек кенә кирәк.

Дөрес, балалар техникумнарга бара дип, сөенергә иртәрәк. Дәүләткә әле аларны үз һөнәрләре буенча эшләргә күндерергә кирәк булачак. Бүгенге көндә җәмгыятьтә гламур тормыш беренче урынга чыгып, эшчеләр катламы, гомумән, онытылды. Илдә бу уңайдан зур эшләр башкарырга кирәклеге көн кебек ачык. Совет заманындагы кебек эшчеләргә дан җырлау, алар хакында кинолар төшерү (эшчеләр турындагы роман-

тик рухтагы киноларны әле дә яратып карыйбыз бит!) эшче һөнәрен пропагандалаган тапшырулар ясау, мәкаләләр бастыру, гомумән, аның уңай образын булдыру кирәк. Чөнки, ни дисәң дә, дөньяны реклама алып бара. Ләкин иң яхшы реклама җәмгыятьтә квалификацияле эшченең абруен күтәрү булыр иде. Ә моны бары тик дәүләт сәясәте генә булдыра ала. Һәм бу аның мәнфәгате өчен дә кирәк. Россиягә каршы бертуктаусыз санкцияләр игълан ителгән заманда импортны алыштыра алырлык продуктлар эшләп чыгару мөһим. Замана таләпләренә туры килерлек товар җитештерелә торган цехлар югары технологияләр белән җиһазландырылган. Димәк, һөнәр ияләре кул белән генә түгел, баш белән дә эшләргә тиеш. 2024 елга кадәр гамәлгә ашырылачак «Мәгариф» илкүләм проектында да эшче һөнәренең абруен арттыру һәм популярлаштыру өчен чыгымнар каралган. Бу, билгеле, хәзер югары уку йортлары ябылыр да, бөтен финанс урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә генә китәр дигән сүз түгел. Бизмәннең ике ягы да тигез булырга тиеш.

Реформатор-икътисадчы Анатолий Чубайсның «Базар барысын да үз урынына куяр» дигән фаразы чынга ашмады. Димәк, нинди дә булса чаралар күрә башларга вакыт җитте. Бүген эшчеләрнең абруен арттырырга, аларга лаеклы хезмәт хакы түләргә, балаларга кечкенәдән һөнәр алу буенча юнәлеш бирергә кирәк. Шул вакытта гына ил икътисады отачак. Югары квалификацияле белгечлек тә матди яктан тотрыклылык гарантиясе булып тора. Ә аны югары уку йортлары тәмамлап кына түгел, производствода да эшләп алырга, җитмәсә, дөньякүләм уңышларга да ирешергә мөмкин икән бит.

Республикада мәшгульлек төркемнәре буенча эшчеләрнең 2017 елның октябрь аена уртача хезмәт хакы*

	Сумнарда уртача хезмәт хакы
Бөтен эшчеләр	31838
Документ әзерләү һәм теркәү, хисап алып бару, хезмәт күрсәтү буенча һөнәр ияләре	22756
Хезмәт күрсәтү, сәүдә өлкәсендәге эшчеләр, каравылчылар	19153
Авыл, урман хуҗалыгындагы квалификацияле эшчеләр	20835
Сәнәгать, төзелеш, транспорт өлкәсендәге квалификацияле эшчеләр	33213
Производстводагы җиһаз һәм машина операторлары, машина йөртүчеләр, җыючылар	33632
Квалификацияләре булмаган эшчеләр	16771

* Мәгълүмат Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органыннан алынды. Статистика органнары сайлап алу алымы буенча мондый тикшеренүләрне ике елга бер тапкыр уздыра.



Анна СИДОРЕНКО,
Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының һөнәри белем бирү идарәсе башлыгы

Соңгы өч елда Татарстанда эшче һөнәрләрне популярлаштыру буенча гамәлгә ашырылган чаралар нәтиҗәсендә көллият һәм техникумнарга укырга керүчеләр саны сизелерлек артты. Быел чыгарылыш сыйныф укучыларының яртысыннан артыгы белемен әлеге уку йортларында дәвам итә. Диплом алган студентларның 97% ы эшкә урнаша. Аларның 65% ы хезмәт урынын белгечлеге буенча сайлый. 2000 егет һәм кыз (һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларның гомуми санының 11% ы) югары уку йортларына керә.

2019/2020 уку елында республикада төрле ведомство карамагындагы 95 махсус белем бирү учреждениеләре эшли, аларда 70 меңнән артык кеше укый. Иң популяр юнәлешләр: машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, җир өсте транспорты техникасы һәм технологияләре, төзелеш, икътисад һәм идарә итү, энергетика, педагогика фәннәре, азык-төлек продуктлары һәм куллану товарлары технологиясе, нефть һәм нефть химиясе тармагы белгечләре. Эшче һөнәрләрнең популярлыгы артуы шуннан да билгеле, укырга керү буенча конкурслар зурая. Эш бирүчеләрнең таләпләренә туры килерлек кадрлар әзерләү максатыннан белем бирү программаларына робототехника, техник эксплуатацияләү һәм роботлашкан җиһазларга хезмәт күрсәтү, мехатроника һәм мобиль робототехника кебек яңа белгечлекләр кертелде.

2014 елдан башлап Татарстанда ресурс үзәкләрен булдыру программасы гамәлгә ашырыла. Аның кысаларында көллият һәм техникумнарга капиталь ремонт ясала, заманча уку җиһазлары сатып алына. Бүген республикада икътисадның һәм социаль өлкәнең өстенлекле тармакларын кадрлар белән тәэмин итү юнәлешендә 37 ресурс үзәге эшли. Аларда Татарстаннан гына түгел, илнең башка төбәкләреннән дә иң яхшы абитуриентлар белем ала. Ресурс үзәкләрдә ихтыяҗ булган һәм перспективалы 50 белгечлек әзерләү буенча программа булдыру да предприятиеләр белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыра. Балаларга кечкенәдән һөнәр алу буенча юнәлеш бирү өчен илдә, шул исәптән, Татарстанда да, «Киләчәккә билет» проекты гамәлгә ашырыла башлады. Агымдагы уку елында әлеге проектка 5 меңнән артык укучы җәлеп итү планлаштырыла. Проектның максаты – 6–11 нче сыйныф укучыларына булачак һөнәрен мөмкин кадәр күбрәк аңлы рәвештә сайлап алырга ярдәм итү.

WorldSkills чемпионаты хәрәкәтендә катнашу республикада һөнәри белем бирү системасының үсешенә китерде. Эшче һөнәрләр елында Дөнья чемпионатына әзерлек һәм аны үткәрү абитуриентлар арасында һөнәри белемне популярлаштыруга уңай йогынты ясады.



КОЯШКА ҮРЕЛҮЧЕ КӨНБАГЫШ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Без барыбыз – сез кабызган утлар,
Без барыбыз – галим-голәмә.
Хезмәтебез бүген файда итә –
Җәмгыятькә, Илгә, Галәмгә!

Кызык! Әңгәмәне шигырьдән, Һади Такташ, Әмирхан Еники, Бакый Урманчы исемнәрен искә төшерүдән башларбыз дип уйламаган идем... Түбән Камада урнашкан «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводында бит без. Кай якка карасаң да – торбалар, торбалар, торбалар... Бер-берсенә аларны ничекләр ялгап бетергәннәр: цех арасындагы коммуникацияләр өчен генә дә якынча 15 чакрым торба тоташтырылган! Төрле юанлыктагы, төрле озынлыктагы... Торбалардан гына төзелгән җайланмалар янында үзеңне хәтта башка галәмдә дип хис итәсең... «ТАНЕКО»ны исеме янындагы көнбагыш рәсеменнән таныйлар. Кояшка үрелүче көнбагыш... Кояшка, димәк, белемгә, фәнгә, яңалыкка! «ТАНЕКО» – яңа заман предприятиесе ул, монда уникаль белгечләр эшли, иң сыйфатлы продукция чыга. Һәм шушы катлаулы предприятиенең төп терәге – хатын-кызлар. Лаборантлар.

Өч лабораториядә бер айга 25 меңнән артык тикшеренү үткәрелә.

Лаборантның эше читтән караганда берәүгә дә күренми. «ТАНЕКО»да да шулай ул. Лаборатория – ярдәмче производство гына кебек. Ә чынлыкта...

– Чынлыкта, без – предприятиенең йөзе, – ди комплексның Үзәк лаборатория начальнигы Резеда Гыймадиева. – Чын мәгънәсендә шулай! «ТАНЕКО» безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә танылган бик югары сыйфатлы продукция җитештерә. Без исә теге яки бу продуктның норматив таләпләргә туры киләме-юкмы икәнен – сыйфатын раслыйбыз. Автомобиль бензинына, дизель ягулыгына, аэрокеросинга – ә бездә егерме төрдән артык продукция чыга – барысына да сыйфат паспортын без бирәбез.

Яшь кызлар безгә эшкә урнашырга – әңгәмә узарга килгәндә: «Ә нигә нәкъ менә лаборант булырга теләдегез?» – дип сорыйм. Һәр икенчесе: «Бу бит хатын-кыз һөнәре!» – ди. Әйе, алар хаклы.

Лабораториядә ясалган һәр анализ гадәттән тыш төгәллек, җентеклелек сорый. Моңа хатын-кызның гына түземлеге җитәдер... Кул белән башкара торган хезмәт бу: дөресрәге, кул, күз һәм баш белән. Кулың никадәр төгәлрәк эшләсә, нәтиҗә шулкадәр дөрес килеп чыга. Хатын-кыз эшкә күңелен дә сала – бу да бик мөһим. Лаборант кызларыбыз үзләренә бирелгән бу ышаныч белән бик горурланалар.



■ Безнең мәктәпне узган лаборантлар бөтен җирдә дә эшли ала дип саныйм. Гомумән, «ТАНЕКО» – үзе зур мәктәп, ул бездән белгеч кенә ясамый, нык ихтыяр көче дә тәрбияли. Стресска каршы торырга өйрәтә. «Нон-стоп» режимы үз эзен барыбер калдыра инде ул...

Лаборант – производствоның йөзе генә түгел, күзе дә. Монысын безгә технологлар бик еш әйтә. Завод эчендәге җайланмалар – установкалар тәүлек әйләнәсе эшли. Пробалар лабораториягә өчсыз-кырыйсыз бер агым булып килеп тора. Бу анализлар әзер булмыйча, технологлар процессны ничек алып барырга икәнен белми. Нәтиҗәләр әзер булгач, алар процессны җайга сала. Хәер, барысын да кеше белән чагыштырырга була. Әйтик, авырып киттегез ди. Табибка баргач, ул бит сезне иң элек анализ бирергә җибәрә. Аннары шуларга карап диагноз куя, дәвалау юлларын тәкъдим итә. Монда да шулай. Нинди чимал икәнен, сыйфатларын, эшкәрткәндә аның белән ниләр булырга мөмкин икәнен аңлагач, технологлар эш тәртибе төзи. Тайпылышлар килеп чыкса, кабат безгә мөрәҗәгать итә һәм процесска үзгәрешләр кертә...

Резеда Рәшит кызы – «ТАНЕКО»да лабораториягә нигез салган көннән бирле эшли. Дөресрәге, ул эшкә

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



Гөлнара Гарипова, лаборант:

– Мин менә хәзер сульфонолны тикшерәм... Үз эшен яратып башкарган кешегә мавыктыргыч процесс бу. Гомумән, безнең һөнәрне иҗади эш дияр идем: процесс вакытында күрсәткечләр үзгәреп тора, производство алга атлый, шуның белән бәйле рәвештә безнең эшкә яңалыклар керә...

Әгәр мин ялгышам икән... Юк, берничек ялгышырга ярамый! Бездә бөтен исәпләүләрне прибор яза. Минем төп бурычым: теге яки бу күтәрелешне – пикны дөрес тиңләштерү. Менә монда кеше факторы килеп кушыла да инде: әгәр аны дөрес теркәмәсәм, производствода процесс та ялгыш юлдан китәчәк. Без биргән цифрларга бөтен завод карап тора! Производствода икенчел дип саналсак та, беренче урында барыбер без торабыз дип саныйм.

Ирләр бу урында эшли алмыйдыр. Лаборантның эше – ювелир эшенә тиң. Бик четерекле ул. Пөхтәлек тә кирәк монда, кулларның тоемлау сәләте дә, нәрсә эшләгәнеңне белеп, аңлап эшләү дә. Стандарт булмаган уйлау да кирәк, чөнки кайчак гадәти булмаган карарлар кабул итәргә туры килә. Баш белән эшләргә!

Лаборант – шактый куркыныч һөнәр: аның кул астында һәрвакыт нинди дә булса химикат яки кислота бит.



■ Эльвира Хәсәнова *(сулда)*:

Лаборантны мини-инженер дияргә дә мөмкин: ул да шулай ук эшкә тотынганчы инде ниндидер карарлар кабул итәргә тиеш. Җиһазның әзерлеген тикшерә – ул дөрес нәтиҗәне чыгарырга әзерме, юкмы? Әмма иң мөһиме: лаборант моңа үзе эчтән әзер булырга тиеш. Җентекләп, күп көч салып, басылып эшләргә кирәк булган һөнәр бу.

Югары уку йортын «яхшы» билгеләренә генә тәмамлаганнан соң, «Нефтехим» берләшмәсендә, фәнни-технологик үзәктә эшли. Авыр, катлаулы мәсьәләләрне чишү ошый аңа. Катализаторлар, цеолитлар белән шөгыльләнә. «ТАНЕКО»да, лабораториядә эшләргә тәкъдим иткәч, берсүзсез ризалаша: вакыйгалар үзәгендә кайнау аның рухына бик туры килә! Моңа кадәр әйдәп баручы инженер булып эшләгән, хәзер – комплексның өч лабораториясен берләштергән Үзәк лаборатория начальнигы урынбасары.

– Читтән караган кешегә лаборантның эше бик җиңел дә тоелырга мөмкин: пробаны приборга кертә дә, берничә минуттан нәтиҗә килеп чыга... Чынлыкта, лаборатория иң заманча җиһазлар белән җиһазландырылса да, күп этаплы эш бу. Башта әле әзерләнергә кирәк. Беренчедән, пробаны дөрес сайлап алырга (моның белән дә бездә хатын-кызлар шөгыльләнә – алар кулы аша көн саен йөзләгән литр проба уза). Икенчедән, приборның әзерлеген тикшерергә. Өченчедән, кирәкле реактивлар, эремәләрне әзерләргә, аларның сыйфатын тикшерергә... Лаборант авырлыктан курыкмаска тиеш: аның өчен тизлек тә мөһим, тәҗрибә дә, белем дә. Масштаблы уйлау да таләп ителә аннан. «Башка кеше эшләп бетерер әле», – дип әйтү була алмый бездә. Җаваплылык һәркемгә тигез бүленгән.

Лабораториягә эләккәч кенә лаборантның никадәр җаваплы эш икәнен аңлыйсың. Бу хатын-кыз иңнәрендә завод кадәр завод күләмендә күтәрелгән мәсьәләләр ята. Әйтик, заводтагы җайланмалар урынына лабораториядә мини-установкалар урнаштырылган: алар шулай ук ватыла, аларга да запас частьлар, бу прибор белән эшли алырлык белгечләр кирәк. Лаборантның эшен инженер-химиклардан башка күз алдына да китереп булмый: лаборатория начальниклары белән бергә алар барлык тикшеренү эшләренә җитәкчелек итәләр.

урнашканда әле аның нигезе дә салынмаган була. Бирегә эләгү өчен ярты ел эчендә инглиз телен камилләштерә. Өч ел эчендә лаборатория начальнигы вазыйфасына күтәрелә. Хәзер инде әнә Үзәк лабораторияне җитәкли. Аның кул астында ике йөз кеше бүген. Моторлар сынаучы биш ир-ат һәм ике инженердан кала – барысы да хатын-кызлар. (Моторлар сынау – авыр физик хезмәт таләп иткәнгә, заводта ир-ат эше дип санала. Әмма анда да берара хатын-кыз эшләп алган.) Бу коллективка килеп кергән һәркем үзен яңа гаиләгә аяк баскан кебек тоя: алга куелган бурычны үтәү өчен аларга һәрвакыт бердәм булу кирәк.

– Яңа кешене эшкә алганда, аның кулы никадәр җитез икәнен дә, интеллект дәрәҗәсен, инженерларча уйлыйммы, баш мие йөгерек эшлиме-юкмы икәнен дә әле белмибез. Күзләре янып торса, димәк, ул – безнеке! Теоретик белемнәр – күп нәрсәнең нигезе, әмма лаборант булу өчен химияне белү генә җитми. Холыкка да карыйбыз. Бездә сабыр, тотрыклы кеше генә эшли ала, чөнки кайчак анализлар, тикшеренүләр килеп тә чыкмый. Шундый чакта хискә бирелмәскә, салкын канлылык сакларга кирәк. Гомумән, теләсә нинди ситуациядә югалып калмаска тырышырга. Без кешеләр тормышы өчен җаваплы: заводта аварияләр чыгу-чыкмау турыдан-туры лаборантларга бәйләнгән.

Тикшеренүләр үткәргәннән соң, лаборант ниндидер нәтиҗә ала: кайчак үзе исәпләп чыгара яки прибор күрсәткәнне яза. Аны каядыр тапшырганчы, ул бу цифрга бәя бирергә тиеш. Кеше белән мисалны алдарак юкка китермәдем: анализлар дөрес булмаса, дәвалау да ялгыш юлдан китәчәк. Монда да шулай. Лаборант үзе алган нәтиҗәгә анализ ясый белергә тиеш: технология буенча нигә шулай килеп чыкты (яки чыкмады)? Производствоны белмичә, бу сорауга җавап бирә алмыйсың. Һәр анализ алдагысын кабатласа да, ул – башка очрак.

Эльвира Хәсәнова – Үзәк лаборатория җитәкчесенең уң кулы.

Лабораториябез уникаль. Бүгенге көн геройлары эшли монда. Безгә куелган бурычлар бик тирән белемнәр таләп итә. Продукциянең тулы циклын күзәтәбез: чималның ничек керүен, ничек эшкәртелүен, нинди хәлдә чыгуын... Соңгы нәтиҗә безнең коллективта нинди атмосфера тудыруыбызга да бәйле.

Яңа кешене эшкә алганда алар һәрвакыт: «Берәр хоббиегыз бармы?» – дип сорыйлар. Хоббиның эшкә ни катышы бар дисезме? Бар икән шул. Лаборантның кул эше белән шөгыльләнүе аңа һәрчак файдага гына: бармакларының сизгерлеге арта. Шулай, һәр эшнең үз нечкәлеге... Сүз уңаеннан: комплексның Үзәк лаборатория начальнигы Резеда Гыймадиева үзе флористика белән мавыга. Чын-чынлап мавыга! Эше никадәр авыр, катлаулы булуга карамастан, флористика мәктәбен тәмамлаган. Уңышлары бар!

Инде шигырь турында...

Сүзне шигырьдән Эльвира башлады. Остазлары Азат Зыятдиновка багышлап язылган шигырьдән бу юллар. Онытмыйлар... Алар өчен фәнгә генә түгел, мәдәният, сәнгать дөньясына да юлны ачкан шәхес бит ул. Берсе икенчесенә комачауламый.

Фото: Анна Арахамия



Илшат СӘЛАХОВ, «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводының генераль директоры

– Технологик яктан алга киткән су чистарту блогыбыз бар. Комплекста нинди су җыела – ә ул су эчендә нефть тә, нефть продуктлары да, чиста суда булырга тиеш булмаган башка катнашмалар да бар – барысы да шушы блогка килә. Һәм ул аннан Кама елгасындагы суга караганда да чистарак булып чыга! Россия хөкүмәте җыелган суларны чистарту нормативы турындагы карарны безнең предприятие тәҗрибәсенә нигезләнеп кабул итәчәк. Аны Россиядә иң беренче булып производствога без керттек.

Инде һавага ташлаулар турында. Нормалар буенча, шәһәргә кадәр аның 100–200 ppmы гына барып җитәргә тиеш. Бу нәрсә дигән сүз: син торбадан 500 дә, 1000 ppm да ташлый аласың, чөнки шәһәргә барып җиткәнче ул таралып бетә, 200 ppmга гына кала. 2006 елда, проектны эшләтеп җибәрер алдыннан, бу мәсьәләне өйрәнү өчен Европада да, Америкада да, Азиядә дә булдык. Иң каты таләпләр – Европада. Аларда торба өстендәге һавада, әйтик, азот оксиды – 80, күкерт оксиды – 100 ppm гына булырга тиеш. Бу әле торбада! Аларда инде заводтан бер чакрым арада авыллар урнашкан. Без дә «ТАНЕКО»ның шәһәргә бик якын урнашачагын белә идек. «Шундый нормалар буенча эшләргә телибез», – дип «Татнефть» җитәкчелегенә мөрәҗәгать иттек ул чакта («ТАНЕКО» – «Татнефть» компанияләре төркеменә керә. – *Г. С.*). Алар безнең белән килеште – һәр җайланмабыз Европа нормалары буенча эшли бүген. Нигә кирәк сезгә мондый чыгымнар дип, аңламаучылар да булды. Безнең предприятие үзалдына башта ук «барысы да киләчәк буыннар өчен» дигән девиз куйды һәм аннан тайпылырга җыенмый.

Автомобильләр өчен «Евро-5» экология стандарты бар: зарарлы матдәләр күләме төрле ягулыктан һавага төрлечә чыга. Без бүген «Евро-5» дип чыгара торган ягулык, чынлыкта инде «Евро-6» стандартына туры килә. Бу очрак та – Россия өчен бердәнбер. Анысы да тирә-як табигатьне саклауга без керткән өлеш.

Боларны нигә сөйлимме? Һәрберсенең артында сыйфат ята. Аз гына тайпылыш булдымы, лаборатория кызлары шунда ук: «Сезнең монда үзгәреш бар», – дип чаң суга. Сыйфат буенча туры килми икән, алар продукциягә паспорт бирми. Әлеге кагыйдәне 2010 елда үзебез керттек.

Бик җаваплы тагын бер бурыч алар өстендә: технологик процессның үтәлешен күзәтәләр. Нефть тә, аннан эшләнгән продуктлар да, белгәнебезчә, бик тиз яна. Нефтьне дөрес эшкәртмисең икән, җайланмага йә ут кабачак, йә шартлаячак. Бездә бөтен нәрсә автоматлаштырылган. Әмма ул система процессны лаборатория кызлары әзерләгән мәгълүматларга нигезләнеп алып бара. Шуңа күрә лаборант дөрес ясамаган анализның ахыры нәрсә белән тәмамлануын күз алдына китерү дә куркыныч... Ун ел эчендә кызларның бер тапкыр да ялгышканы булмады! Гомумән, алар беркайчан сынатмый. Екатеринбургта узган Worldskills Hi-Tech чемпионатында Елена Сәхибгәрәева, мәсәлән, үз компетенциясендә беренче урынны алып кайтты. Ольга Гусева исә тиздән Сочида узачак чемпионатка безнең завод данын якларга бара. Аны да җиңү белән көтәбез.

Мин дә, Эльвира да эшне «Нефтехим» берләшмәсендә, фәнни-технологик үзәк директоры, галим Азат Зыятдинов кул астында башлаган идек. Системалы фикерләүгә безне ул өйрәтте. Ике-өч кенә түгел, биш-алты адымга алга уйларга кирәк дия иде. Коллективта эшне, кешеләрнең бер-берсе арасындагы мөнәсәбәтләрне оештыру сәләте көчле иде аңарда – моңа мин аңардан өйрәндем. Үз эшеңдә белгеч булырга да ул өйрәтте! Безгә – үзе янына туплаган яшь галимнәргә өмете зур иде Азат абыйның. Һәм без аны акладык. Илдар Әхмәтов, Ринат Гыйльмуллин, Илдар Сәлахов һәм башкалар республикабызның зур предприятиеләрендә җитәкче вазыйфасын башкара. Аның шәкертләре арасында ике доктор, унбиштән артык техник фәннәр кандидаты бар.



МӘДӘНИЯТ – КЕШЕЛЕК САКЧЫСЫ



Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада ӘЮПОВАның тормыш кагыйдәләре

МИНЕМ ӨЧЕН МӘДӘНИЯТ – КЕШЕНЕҢ ТУУЫ, ЯШӘВЕ, НИНДИДЕР ГАМӘЛЛӘР КЫЛУЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МОХИТ. Ул мохит аны рухландырырга тиеш. Образлы итеп әйтсәк, мәдәният күңелгә, җанга кирәк булган һава. Фән ягыннан карасак, ул һәр кешенең төрле охшашлыклары симбиозы. Нәсел охшашлыгы бар. Аны сайлап ала алмыйбыз. Ә менә территориаль, социаль, милли, дини охшашлыкларны сайлау хокукыбыз бар. Уйлап карасаң, кеше туганда ук аңа мәдәни коды салынган була инде. Яшәү дәверендә мохит аңа үзенчә тәэсир итә. Кеше үзгәрә.

Күпләр мәдәниятне күңел ачу чарасы итеп кенә кабул итә. Бу – замана тенденциясе. Сәламәтлекне ныгыту, мускулларны үстерү өчен спортзалга йөрибез. Шөгыльләнгәннән соң бөтен тәнебез авыртса да, кабат барабыз. Мәдәниятне исә йөрәк, күңел күнегүләре дип карарга кирәктер. Һәм ничек кенә авырттыра әле алар! Күңелне, уңайлылык мохитеннән алып чыгып, бераз борчып алырга да кирәктер. Мин Бакуда туып-үстем. Кечкенә чакта бик еш кына Баку сынлы сәнгать музеена йөри идек. Баскычтан күтәрелгәч үк икенче катта «Нерон циркы» картинасы эленеп тора. Бик куркыныч рәсем иде ул. Хайваннарга карата кансызлык сурәтләнгән. Аларны жәлләгәнем һаман да истә. Без һәрвакыт ромашкалар гына ясарга тиеш түгел бит инде! Гәрчә ромашкаларны бик яратсам да... Кем яки нәрсә өчендер борчылуны онытсак, җәмгыять цивилизация буларак үсүдән туктаячак. **ҮЗЕБЕЗГӘ БӨТЕНЛӘЙ ДӘ КАГЫЛЫШЫ БУЛМАГАН ӘЙБЕРЛӘРГӘ БИТАРАФ КАЛМЫЙБЫЗ ИКӘН, ДИМӘК, БЕЗ ИСӘН ӘЛЕ...**

Бүген мәдәният өлкәсендә хезмәтләре иң бәяләнмәгән катлам – иҗат әһелләре: язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар, ягъни сәнгать белән профессиональ шөгыльләнүчеләр. Узган гасырның 30 нчы елларында иҗади берләшмәләр оештырыла башлый. Ул вакытта ил җитәкчелеге идеология алып бару өчен нәкъ менә иҗат кешеләренең иң зур терәк булуын аңлаган. **ИҖАТ КЕШЕЛӘРЕ – МИЛЛӘТ ГЕНОФОНДЫ.**

СӘНГАТЬКӘ ИНВЕСТИЦИЯ КЕРТҮ БИК МӨҺИМ. Талантлы кешеләргә карата капиталлаштыру инструменты булдырырга тиешбез, киресенчә булган очракта, алар бездән китәчәк.

Сугыштан соң бик күп бинаглар төзелгән. Хәзер аларны яңарту, тергезү бара... Мин алардагы декоратив элементларны саклап калу өчен чын-чынлап көрәшәм. Мозаика панносы, витражлар... Гүзәллеккә рухландыручы мохит юк икән, кешедә шәхес үсеше була алмый. **СОРЫ ТАРТМАЛАРДА ЯШӘП ГҮЗӘЛЛЕК ТУДЫРЫП БУЛМЫЙ.**

Татарстан пилот проектта. Тугыз төбәк арасында без мәктәп укучысының мәдәни нормативы буенча хедлайнерлар. Беренче июньнән балалар музейга бушлай йөри ала. Без яңа буынны югалтырга тиеш түгел. Алар бит бөтенләй башкача уйлый, әти-әниләре – миллениаллар, ә үзләре, заманча әйтсәк, Z буыны. **БАЛАЛАР – АТА-АНАЛАРЫ ӨЧЕН МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ҮСЕШ АГЕНТЛАРЫ.** Кызыклы статистика китерә алам: әлеге проект гамәлгә ашырыла башлагач, музейга йөрүче өлкәннәр саны артты. Чөнки кешеләр бик рациональ, бушка булганны барыбыз да ярата. Сүз уңаеннан: һәр айның беренче сишәмбесендә дәүләт музейларына керү түләүсез.

Без хәзер лидерлар үстерү белән мавыгабыз. Тик бөтен кеше дә лидер була алмый. Бар яктан үсеш алган шәхесләр иле төзергә тиешбез. Дәүләт архивында эшләгәндә бер малай язган хатка тап булган идем. Әтисен репрессияләгәннәр, әнисен Чиләбегә сөргенгә җибәргәннәр. Ул Балалар йортында үскән. Шуңа да карамастан, иң кадерле кешеләреннән аерган, бөтен нәрсәдән мәхрүм иткән илне ярата алган ул. Укыган, үзе теләп фронтка киткән. Бу малайның рух ныклыгы сокландырды мине. Ә бездә лидерлыкка өйрәнгән балалар проблемаларга каршы тора алмый. Шуңа күрә дә үз-үзенә кул салу очраклары ешая. Балалар, нинди булуларына карамастан, әти-әнисенең яратуын тойганда гына җәмгыять исән калачак. **ЯРАТА БЕЛҮ ШУЛАЙ УК ЗУР СӘНГАТЬ.**

МИНЕМ ӨЧЕН МИРАС, БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА – ТРАДИЦИЯЛӘР УЛ, ҺИЧ ТӘ АНТУРАЖ ТҮГЕЛ. Аны тарихи нигездә барлыкка килгән һәм сакланган төп кыйммәтләр системасы итеп карарга кирәк. Тагын бер кат үз тамырларыма кайтам. Азәрбайҗанда традицияләрне бик нык саклыйлар. Анда территориаль охшашлык бик көчле. Дөньяда нинди үзгәрешләр булуга карамастан, гаиләләр үз традицияләренә тугрыклы. Мәсәлән, туйларда һаман да мугам яңгырый. Ул – аларның традицион музыкасы. Ә Нәүрүзне бөтен кеше бәйрәм итә. Мин Баку читендә эшчеләр бистәсендә үстем. Безнең ишегалдында төрле милләт кешеләре яши иде. Нәүрүз көнендә без, балалар, һәр ишекне шакып, ишек төбенә башлыкларыбызны куябыз. Хуҗалар, нинди милләттән булуларына карамастан, башлыкларыбызны тәм-том белән тутыра иде.

Традицион мәдәният бәйрәмнәр генә дигән сүз түгел әле. **ӨЛКӘННӘРГӘ ХӨРМӘТ ТӘ – ТРАДИЦИЯ.** Кызганыч, хәзер эмансипация көчле. Бу өлкәгә дә глобальләшү кагылды. Мине бер нәрсә сөендерә: милли кухнябыз сакланып калды.

Татарстанда республика һәм федераль бюджет ярдәме белән 22 яңартылган кинозал ачылды. Шулай ук күчмә кино проекты да эшли. Дөрес итеп оештырылган очракта, авылларда да халыкара премьераларны трансляцияләп булыр иде. Тик халык актив йөрерме соң? **БЕЗГӘ АРАЛАШУ КУЛЬТУРАСЫН ҮСТЕРЕРГӘ КИРӘК.** Өлкән буын кешеләре аралашу өчен яңа мәйдан тапты инде – алар мәчеткә йөри. Бу – бик күңелле күренеш.

Авыл клубы эшчәнлегенә бәйле дәгъвалар күплеге хакында беләм. Бүген без районнар белән берлектә мәдәният йортлары эшенә кагылышлы стандартларны киредән яза-

Фото: Анна Арахамия



быз. Районнар җиде зонага бүленгән, һәрберсе үз күзаллавын әзерли. Сүз төрле чаралар уздыру планы турында гына бармый. **МӘДӘНИЯТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТАЛАНТЛАРНЫ ҮСТЕРҮ ҮЗӘГЕ БУЛЫРГА ТИЕШ. БУ – МИНЕМ ДӘЛИЛЛЕ ФИКЕРЕМ!** Элек мондый система булмаса, Илһам Шакировлар, Әлфия Афзаловалар да үсеп чыкмас иде.

Үзешчән булудан курыкмаска кирәк. Әйе, өлкәннәр артык тыйнак, оялчан, күләгәдә калырмын дип уйлый. Мин үзем дә сәхнәгә чыксам, әйтәсе бөтен сүземне онытам. Ә мәктәптә укыганда бик актив идем. Башка кешеләрнең бәяләвеннән курку, күрәсең, тәрбиядән киләдер. Без бит даими стресс хәлендә яшибез. **СӘХНӘГӘ ЧЫГУ – БИК ШӘП АНТИСТРЕСС ТЕРАПИЯ. ИҖАТ КИЕРЕНКЕЛЕКНЕ ЮККА ЧЫГАРА.**

МИН ХАЛЫКЛАРНЫҢ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН САКЛАП КАЛУ ЯКЛЫ. Моның өчен уңай шартлар тудырырга кирәк. Глобальләшү аркасында чын йөзебезне югалтудан сакланырга тиешбез.

Опера сәнгатенең даими аудиториясе республика халкының 3-4 проценты гына. Бу тагын тәрбия культурасы белән бәйле. Операны аңларга кирәк. Гомумән, **СӘНГАТЬ ӘСӘРЛӘРЕН КАБУЛ ИТӘ БЕЛҮНЕ БЕРАЗ ГЫНА ОНЫТТЫК.** Мәдәният учреждениеләренә «күрдек, булды» принцибы белән йөрибез. Мин Леонардо да Винчиның «Джоконда»сын Луврда алты тапкыр карадым. Барсам, тагын караячакмын, караган саен ул башкача кабул ителә. Бу шушы минуттагы эмоциональ халәт белән бәйле. Театрны да бер тапкыр карау гына җитми. Ул – үзенә бер культура. Аны мәктәптән үк тәрбияләргә кирәк. Балаларны без кат-кат карарлык итеп рухландырырга тиеш.

ҮЗГӘРМИСЕҢ ИКӘН, КЫЗЫКЛЫ БУЛУДАН ТУКТЫЙСЫҢ.

«Татар китабы йорты»н чираттагы гади музей итеп кенә ачмадык. Әлеге музейның миссиясен арттыру кирәклеген тойдык. Ул аралашу мәйданы булырга тиеш. Татар китабы текст кына түгел. Минем өчен анда салынган мәгънә кыйммәте мөһим. **ТАТАР КИТАБЫ – БЕЗНЕН МОҢ УЛ. МИҢА КИТАПНЫҢ МОҢЫ БУЛУЫ МӨҺИМ.** Иртәгә янә ачып укырлык тәэсирләр калдырсын ул.

Үземә каршы чыкканнарын яратам. Мин хөрмәт иткән бер иҗат әһеле: **«КЕШЕ ҮЗЕНӘ КАРШЫ ТОРГАННАРГА ГЫНА ТАЯНА АЛА»**, – дигән иде. Хәзер ул минем тормыш концепциям. Үз фикерләре булган, аны әйтә белгән кешеләрне хөрмәт итәм. Алар үсәргә ярдәм итә. Бәхәскә кереп, үземнең дөрес булуыма инанам, йә хаксызлыгымны таныйм.

БӨТЕН КИТАПХАНӘЛӘР ДӘ НАЧАР ХӘЛДӘ ДИГӘН ФИКЕР БЕЛӘН КИЛЕШМИМ. Бу эштә шәхеснең роле бик зур. Аксубай районы үзәк китапханәсе мөдире Ирина Анатольевна Телешеваның ничек итеп китапханәнең дәрәҗәсен күтәргәнен күрсәгез иде сез! Музей, архив, китапханә – консерватив система. Мин аларның билгеләнешен үзгәртмәскә чакырам. Ул – вакыт сынавы үткән институт. Аларның мемориаль функциясе югалырга тиеш түгел. Моннан кала, китапханәләрдә «китап юк» дип әйтүне дә тәмам тамырыннан бетерергә кирәк. Казанда яңа төзелеп килгән китапханәдә чит илләрнең алдынгы тәҗрибәсен кулланачакбыз.

ТАТАР ТРАДИЦИОН МУЗЫКА КУЛЬТУРАСЫН КАЙТАРУ ТУРЫНДА УЙЛЫЙБЫЗ. Баян яки тальян безгә соңрак килеп кергән. Берничә гасыр элек булган уен кораллары башка төркемгә карый. Хәзер консерватория белән берлектә традицион инструментларыбызны документлар буенча тергезергә тырышабыз. Махсус проект эшләдек. Үзеңне һәм тамырларыңны танып белү бик кызык.

База документларыннан кала, бөтен нәрсәгә ышанабыз. Интернетта шулай язылган диган фикерләрне еш ишетергә туры килә. Ә аның бит төп нөсхәсе бар. **БЕРЕНЧЕЛ ЧЫГАНАКНЫ ХӨРМӘТ ИТҮ ЗАРУР.**

Театр елында, традицион фестивальләр, спектакльләр күрсәтү белән бергә, бөтенләй башка аспектларга кагылган проектлар барлыкка килде. Тамашачыларны тәрбияли торган бик күп вакыйгалар булды. Театраль лабораторийлар эшләде. Кайберләре бәхәсләр, аңлашылмаучанлыклар тудырды. Ләкин сәнгатькә, шул исәптән, театрга, чикләр куярга ярамый. **СӘНГАТЬ – РӘХӘТЛӘНЕП ЯЛ ИТӘ ТОРГАН УРЫН ТҮГЕЛ. УЛ УЙЛАНУГА ҖИРЛЕК БИРӘ.** Тормышымда булган авыр чорда Кафканы укыдым. Минем хәлемнән дә авыррак вакыйгалар барлыгын аңлау гына сыгылмаска ярдәм итте.

Бездә клип фикерләү өстенлек итә. Образлар һәм сурәтләрне кабул итәбез, тик сәхнәдән әйтергә теләгән фикерне ишетмибез. «Китмә, сандугач» дигән җыр бар. Бик озак вакытлар аның мәгънәсен кош белән бәйләп аңлаттылар. Юк, дуслар, бу җыр сандугач турында түгел, ә туган җирләреннән китүчеләр, аларның сагышы хакында. Без эчтәлеккә түгел, клипка игътибар итәбез. **ЮЛЛАР АРАСЫННАН УКЫРГА ӨЙРӘНЕРГӘ КИРӘК.**

Бүген хакимияттә технократлар бик күп. Алар: «Безгә нигә китап, китапханәләр? Барысы да интернетта бар!» – дип уйларга мөмкин. Юк, дөрес түгел. **ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ НИ ДӘРӘҖӘДӘ ЦИВИЛИЗАЦИЯЛЕ БУЛУЫ ХАКИМИЯТНЕҢ МӘДӘНИЯТ, ФӘН, ЭКОЛОГИЯГӘ КАРАТА МӨНӘСӘБӘТЕННӘН ЧЫГЫП БИЛГЕЛӘНӘ.**

Миңа профессиональ яктан кызыклы мәдәни вакыйгалар ошый. Ул опера да, яхшы оештырылган эстрада концерты да булырга мөмкин. Алга таба үсәргә, хәрәкәт итәргә мөмкинлек биргән сәнгать әсәрләрен үз итәм. Аның бурычы да шул бит. **СӘНГАТЬ ТОРМЫШКА МӨНӘСӘБӘТЕҢНЕ ҮЗГӘРТЕРГӘ РУХЛАНДЫРСЫН УЛ!**

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Крестина Романова. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз. Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак. Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.



Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да… Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

«ШӘПШЕНЕ ДӨНЬЯГА ТАНЫТТЫК...»































Фото: Анна Арахамия

Мөнәвәрә Кәримуллина:

Без яшь вакытта эше авыр булса да, тормыш бик күңелле иде. Бәйрәм җитә башласа, тотынабыз концерт, спектакль әзерләргә! Үзебездә куйгач, йөк машинасына төялеп, күрше авылларга чыгып китәбез! Бигрәк дус-тату идек шул. Фермада кызлар белән ярыша-ярыша эшләгән көннәр, җәйләүләрдә җырлый-җырлый сыер сауган чаклар кайчак бик сагындыра.

Шәпше – төз урамнары, зур йортлары, капка төпләрен тутырып үскән каен-миләшләре, балыклы күле белән каршы алды безне. Авыл башында зур-зур ферма биналары тезелешкән. Боларга күз генә сирпеп, Ленин урамын эзләп китәбез. Героинябыз шушы урамда яши. «Безнең Мөнәвәрә апа кызлар кебек әле, күз тимәсен, йөгереп кенә йөри», – дигәннәр иде телефоннан авыл советы хезмәткәрләре. Сүзләре хак икән, август аенда гына юбилеен үткәргән Мөнәвәрә апага бер дә сиксәнне бирмәссең. «Хәтер генә бетеп бара хәзер», – дип елмая үзе.

Мөнәвәрә апа – сугыш чоры баласы. Шушы ике сүзгә алар буыны кичергәннең барысы да сыйган – ачлыгы да, ялангачлыгы да, кул көче белән илне күтәрү михнәте дә...

Фермага сыер саварга менгәндә 16 гына яшь була әле Мөнәвәрәгә. Егерме сыерны көненә өчәр тапкыр кул белән савар өчен кайдан көчләр алгандыр алар?! «Ул вакытта бүгенге шартлар юк. Сөте тә торбадан гына китми – фляга белән үзебез ташыйбыз. Сыерларга дигән суларны, онлы апараларны да көянтәләп китерәбез. Аннары кул арбасы алып, печән чабарга чыгып китәбез. Без бер фермада алты кыз – бер-беребез белән ярыштан эшли идек. Районда иң күп сөт савучылар булдык. Алтыбызны да районга алып барып, партиягә алдылар», – яшь чакларын искә алгач, апабыз тагын да яшәреп киткәндәй була.

Мөнәвәрә апаны «Азат хатын» журналы тышлыгыннан «эзләп таптык». 1972 елның декабрь саны ул. «Биектау районының «Урак-Чүкеч» колхозы сыер савучысы Мөнәвәрә Кәримуллина» диелгән. Безне миләшләре белән сәламләп каршы алган Шәпше – шушы колхозның үзәге булган авыл. Авыл диеп әйтү бик дөрес тә булмас, үзенә генә хас тарихлы бистә ул.

Узган гасырның 50 нче елларында колхозларны эреләндерү башлангач, Шәпшедә берничә хуҗалыкны берләштергән «Урак-Чүкеч» колхозы төзелә. Берничә елдан монда бөтен СССРга үрнәк булырлык зур терлекчелек комплексы һәм икешәр катлы таш йортлардан торган яңа бер бистә калкып чыга. Шундый йортларның берсенә Яңа Чишмә авылыннан әти-әнисе, туганнары белән Мөнәвәрә апалар да күченә.

– Фермабыз үрнәк иде. Бөтен җир чип-чиста, сыерларны юып кына торабыз. Эшкә дә матур итеп киенеп барабыз. Чит илләрдән килеп, фермаларга, йортларга шаккатып, сокланып йөргәннәре истә, – ди Мөнәвәрә апа.

Шаккатарлык булган шул Шәпше. Колхозчылар газы, суы кергән, хәтта җылы суы да булган яңа йортларда яши. Урамнар – асфальт, кибетләрендә муллык. Мәскәү тәэминатындагы бистәдә хәтта Казанда сатылмаган товарларга кадәр гел булып торган.

Кайчандыр гөрләп торган авылларның бушавына, яшьләргә үзләре яшәгән җирдә генә эшләргә эш булмавына, мәктәпләрдә укучыларның саны кимүгә көенүен яшерми Мөнәвәрә апа. Мөлаем елмаеп, тормышыннан канәгать булып, якыннарына хәер-фатихасын биреп, кулыннан килгәнчә булышып, бертуган энесе Мидхәт белән киленнәре Рәмзия тәрбиясендә тыйнак кына яшәп ята ул бүген. Ни кызганыч, фотога төшкәндә күкрәгенә медальләрен тагарга гына күндерә алмадык. Мактауларга күнекмәгән шул алар буыны...

Лилия ГӘРӘЕВА

PRESSA

«МИН КӨЧЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ...»



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

– «Баш төзәтергә бир әле», – дип килде ул хатын яныма. Аягында ике төрле киез итек, өс-башы – карарлык түгел... Урам буйлап инде әллә ничә ел эчеп йөргәнен беләидем. «Әйдә, мин сине Ульянга алып барам, анда бирермен», – дим. Дөресен әйтсәң, дәваларга алып барам дисәң, гомердә дә ризалашмыйлар... Ирем командировкага киткән чак иде. Башта өйгә алып кайтып, шампуньнар белән ваннада юындырдым, аннан табибны чакырттым. Киярлек киеме юк – кеше арасына ничек алып чыгасың? Өч көннән соң кайтырга кузгалдык. Чәчтарашханәгә алып кереп чәчен ясаттым. Матурайды... Авылда танымадылар! Шул көннән соң авызына бер грамм аракы капмады! Фермада сыер сауды. Хәзер лаеклы ялга чыкты инде. Менә дигән итеп яши, балаларына булыша... Искә төшерсәң, миндә мондый мисаллар бик күп...

1997 елның 13 мартында аның ирен Тәтеш районының бер хуҗалыгына рәис итеп билгелиләр. Ульяновск авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган Рәмис Хатыйп улының: «Авылда, җирдә эшлисем килә», – дигән теләге, ниһаять, чынга аша. Унбер ел шәһәрдә яшәп, андагы шартларга күнеп беткәннән соң. Чынбарлык кына хыяллардан шактый ерак булып чыга. Районның иң артта калган хуҗалыгы. Газ кермәгән, юл юк, су юк. Тракторларга салырга солярка юк... Нәрсәгә тотынсаң – шул юк!

«Мин көчле булырга тиеш!» Беренче тапкыр бу сүзне Рима Жуковога аяк баскач әйткәндер.

– Таралып бара торган рус авылы... Хуҗалыкка караган башка авыллар исә аннан да начаррак хәлдә. Торыр җир, әлбәттә, юк иде. Тулай торакка – ике катлы элеккеге балалар бакчасы бинасына урнаштык. Бер канатында – егетләр, икенчесендә – кызлар яши. Ике ел ярым тордык әле без анда. «Китәбез», – дип гел төенчекләр өстендә утырдык...

Китүдән аларны беренче мәлдә ире яшәгән фатир хуҗасы – өлкән яшьтәге бабай туктатып кала. Башта: «Чәчүне чәчеп чыктың, улым, үзең чәчкәнне үзең урып ал инде», – ди. Көзен, ашлыкларны җыеп алганнан соң, кабат ашыкмаска куша: «Үз орлыгыңны чәчеп тә кара инде, улым...» Аннан кабат урак өсте җитә...

Иң арттан – кырык бишенче урыннан агрофирманы беренче рәтләргә күтәргәнче күпме вакыт узамы? Бер гомер! Ә салган көчне үлчәп бетерерлек түгел... 2003 елны Рәмис Сафиуллов республикадан Германиягә фермер хуҗалыклары белән танышырга баручы делегация составына эләгә. Ул аннан дәртләнеп кайта: «Бездә дә анда күргәннәрне булдырасы иде!» Яңа комбайннар, техника ала башлый. Кредитка чумалар... («Безнең хәтта Ульяновск шәһәрендәге фатирыбыз да банкта залогта иде ул чакта. Иремнең эшләре бармаса, аны да югалтасы идек...»)

Ә Рима... Бу вакыт ул иренең уң кулына – иң ышанычлы ярдәмчесенә әйләнә. «Колос»ның өлкән бухгалтеры вазыйфаларын башкара. Һәр уңышка икәүләп сөенәләр: чәчүне вакытында төгәллиләр – шатлык, сөт саву арта – сөенеч...

Эшләр үргә китә.

Булдырыйм, башкалардан уздырыйм дип үҗәтләнеп эшләгән кеше-



гә республика җитәкчеләренең игътибар итүе гаҗәп түгел: 2014 елның 8 октябрендә Рәмис Сафиуллловны Тәтеш районы башлыгы итеп билгеләп куялар. «Колос» агрофирмасындагы директор урынын да, шәхси крестьян-фермер хуҗалыгындагы башлык вазыйфасын да ул хатыны кулына тапшырып калдыра. Рима Гомәр кызының: «Мин көчле булырга тиеш!» – дип икенче тапкыр әйткән көне бу... Шул көннән соң аның тормышында яңа чор башлана.

– Рәмис киткәч, мин бер ел еладым... Моңа кадәр аның җилкәсенә ышыкланып яшәдем бит. Ә хәзер барысына да үзем җавап бирәсе... Ышанычын аклый алырмынмы аның? Аннан да авыррак икенче сорау да бар: халыкның ышанычын аклап булырмы? Рәмисне яратты алар, район башлыгы сыйфатында беренче тапкыр агрофирманың отчет-сайлау җыелышына килгәч, ул залга керүгә барысы торып басты. Кул чабалар, елыйлар... Авылларны ул бит газлы итте, юллы итте. Эшле итте!

Яңа вазыйфама күнегә торган арада яз җитте. Чәчүгә төшәр алдыннан механизаторларны җыйдым. «Егетләр, бөтен өмет сездә, – дим. – Мин – хатын-кыз, бу эшнең әле бөтен нечкәлекләрен белмим. Чәчүне оештырып чыгып булмаса, Рәмис: «Эшли алмадың, бар, өйгә кайт та утыр», – диячәк. Сез миңа сүз китермәгез инде». Ник берсе эчсен! Көнне-төнне белми эшләделәр. Хәзер дә шулай эшлиләр... Шундый рәхмәтле мин аларга!

Эчү дигәннән. Таркалып диярлек беткән өч авылны берләштергән «Колос»ның иң зур проблемасы – эшләргә кеше җитмәү була. Кайдан алырга аларны? Беркем көтмәгән юлны ул чакта Рима таба: исерекләрне айнытырга керешә. Берәмберәм аларны Ульянга – таныш наркологына алып бара: кайсын ачуланып, кайсын хәйләләп... Гомер эчүен ташламас кебек тоелган ирләр аракының ни икәнен оныта, эшкә урнаша, өйгә хезмәт хакы алып кайта башлый... Бу йортлардагы бәхетне, хатыннарының, балаларының Рима ханымга никадәр рәхмәтле икәнен күз алдына китерү авыр түгел. (Берсендә ире әле агрофирмада эшләгәндә Казанга, киңәшмәгә бара. Җитәкчеләр бар да: «Халык эчә», – дип зарлана. «Бездә беркем дә эчми», – ди Рәмис Хатыйп улы. «Ничек инде синдә генә эчмиләр?» – диләр аптырап. «И-и егетләр, – ди ул, – минем хатын моло-

Әнием Сара пенсия акчасын җыеп, 90 яшендә авылыбызда басма-күпер салдырды.

дец, салган кешене күрсә, шунда ук утырта да дәваларга алып китә».)

– Читтән кеше китертергә була анысы... Чит барыбер чит инде ул – үзеңнекеләр кебек тырышмый. Аңа әле иң элек торыр урын табарга кирәк, төшке ашын гына түгел, иртәнге һәм кичке аш мәсьәләсен дә хәл итәргә... Ияләшәме әле ул, юкмы... Үзебезнең механизаторларга җитми! Районда беренче урыннарны алалар әнә. Сыер савучыларның да алышынганы юк... Авыру бит ул эчкечелек, андый чиргә таручыларга вакытында туктарга булышырга кирәк. Махсус журналым бар, кемне, кайчан табибка алып барганмын – язып куям. Дәваларга вакыт җитмәгәнме дип карап кына торам.

«Булдыра алмадың...» Беренче елларда иң курыкканы иреннән шушы сүзне ишетү була. Тик күз курка, ә кул эшли. Хатын-кызларча хуҗалыкка тәртип салырга керешә ул. Беренче эш итеп бухгалтерия кызларын Ульяновск шәһәренә укырга – компьютерда эшләргә өйрәнергә җибәрә. Алар кайтуга, бүлмәләренә компьютерлар алып куя.



Аннан бөтен җиргә видеокүзәтүләр урнаштыра. «Нигә кирәк бу күзәтү?» – дип аптыраучылар, канәгать булмаучылар, хәтта сыер савучылар кебек беренче мәлдә баш күтәрүчеләр дә табыла. Камераларны ватучылар, аны буяп куючылар. Кирәк, бик кирәк була ул – урлаучыларга чик куела. Рима Гомәр кызының үзендә генә түгел, барлык урынбасарлары телефонында да видеокүзәтү тора: дөньяның теләсә кайсы ноктасында булсалар да, хуҗалыктагы хәлләрдән хәбәрдар алар.

Халык бу яңалыкка күнеп кенә җиткәндә, җитәкчеләре яңасын уйлап таба – глонасска чират җитә. Аны бөтен техникага да урнаштыралар: күпме йөргәнен, кайда туктап торганын, никадәр солярка салганын, күпмесен якканын – глонасс барысын күрсәтә. Машина багында алдагы көннән күпме бензин калган, бүген күпме өстәргә – боларның барысын да электрон картага карап, Казандагы диспетчер хәл итә аларда. (Авылдан чыгып киткәч, мине күзәтә алмыйлар дип уйлаган бер йөртүчеләре Ульяновскига баргач, 60 литр солярканы бушата. Электрон картада минуты белән күренә бу. Түләтәләр. Шушы очрактан соң механизаторлар ягулык урлаудан туктый. Эшкә карата яңа мөнәсәбәт урнаша.)

Яңа гына тагын бер яңалык кертkәннәр – урып-җыю башланыр алдыннан электрон үлчәү көйләгәннәр. КамАЗ машинасы үлчәүгә кереп басуга, аның күпме ашлык алып кайтуы турындагы мәгълүмат турыдан-туры бухгалтериядә чагыла. Һәрбер бөртек исәптә!

Тәтештә иң сыйфатлы, иң чиста сөт – аларда! «Чиста» дигәндә, Голландиядән кайтартылган йөз җитмеш сыердан сауган сөтне күз уңында тота Рима ханым. Бер елны аңа тикшерүчеләр килә. Кайда комплексларыгыз, күрсәтегез, диләр. Голланд сыерлары өчен миллиардларга төшереп комплекс төзегән дип уйлаганнар икән... Алай да ерактан кайткан маллар өчен бер шарт тудырылган: лейкоз белән авыручы хайваннар белән аларны кушмыйлар – чир эләксә, савылган сөтнең сыйфаты начараячак. Сөт саву буенча районда беренчелекне берәүгә дә бирмиләр. Һәр көнне 8-9 мең литр сөт савалар. Ә сөт авыл кешесе өчен тере акча дигән сүз!

Иген игү буенча да беренче урында алар. Сүз бу урынга җиткәч, әңгәмәдәшемә тел очында торган соравымны бирәм:

– Сезне комбайнда үзе эшли дип әйтәләр, дөресме? – дим.

– Кирәк булса, бөтен техникага утыра алам анысы. Комбайнга да. Тик аның штурвалын миңа кем бирсен?! Урып-җыю вакыты җитсә, бездә комбайнга чират төзелә. Былтыр, мәсәлән, айга туксанышар мең эшләделәр. Трактористларның аена 40–50 мең алучылары бар. Бүген шартлар бөтенләй икенче. Комбайнерлар яңа. Компьютер күпме иген сугылганын, бункерның күпмегә тулганын күрсәтә. Кондиционер эшләп тора: комбайнер, элеккеге кебек, тузанга батып, тирләп-пешеп йөрми. Смена беткәч, юынырга, өс-башын алыштырырга мөмкинлеге бар.

«Минем комбайнерлар», «минем механизаторлар», «минем сыер савучылар», дип сөйли ул. «Мин аларга шулкадәр рәхмәтле – тырышалар!» – дигән җөмләне әңгәмәнең буеннан-буена ничә тапкыр кабатлавын кызык өчен генә санийсым калган икән.

– Ике хуҗалыкны бергә кушсаң, минем кул астында бүген йөз иллегә якын кеше. Эш кушканда тавыш күтәрсәң, кычкырсаң, сине, әлбәттә, берәү дә тыңламаячак. Эшләсә дә, җиренә җиткереп эшләмәячәк. Ә мин мактыйм! Бөтенебезгә дә яхшы сүз кирәк бит... Халык белән эшләгән җитәкче матур сүзен кызганырга тиеш түгел. Кырларда, фермаларда йөреп кайтам да, бухгалтерия кызлары янына керәм: «Иң яраткан кешеләрем сез! Сездән башка нишләр идем?!» – дим. Чәйне гел алар белән бергә эчәм. Кеше белән кешечә, гади булырга кирәк. Шунда гына эшеңнең нәтиҗәсе була...

Хезмәт алдынгыларына санаторийга юллама, телевизор, кер юу машинасы кебек зур бүләкләр бирү гадәте күптән бар аларда. Ә бер елны ул бухгалтерия кызларына Мисырга юллама бүләк итә! Күбесенең чит илгә беренче чыгуы була. «Без ул сәяхәттән тагын да дуслашып, берләшеп кайттык», – ди.

Яшерен-батырын түгел, күпләр аңа беренче чиратта алны-ялны белми эшләгән хуҗалык җитәкчесеннән бигрәк, район башлыгы хатыны дип карый.

– Бердәнбер өстенлегем – ул үткәргән киңәшмәләргә йөрмим, урынбасарларым гына бара. Аны кыен хәлгә куясым килми: залда мин утырганда безнең хуҗалыкны мактаса да, тәнкыйтьләсә дә аңа читен булыр иде. Мактау кәгазьләрен дә минем исемгә биргәннәре юк. Сабантуй мәйданы уртасына башка җитәкчеләр чыга, мин – юк... Ә болай бик горурлана ул хәзер минем белән!

Райондагы башка җитәкчеләрдән тагын бер өстенлеге бар әле аның: кырларында үз исемен йөрткән сабан бодае – «РИМА» үсә. Озын башаклы, авыруларга бирешми торган бодай. Әмма иренең монда бернинди катнашы юк: Рима Сафиуллованың Мәскәү фәнни-тикшеренү институтлары, селекционерлар белән эшләвенең нәтиҗәсе бу. Капчыклап кына алып кайткан булганнар, хәзер әнә кыр тутырып чәчкәннәр. Элита орлыкның бәясе башка!

– Авылларны матурайтасым килә, – ди ул. – Чит илдәге кебек, чәчәккә күмәсем. Шартлар бар, монда да шәһәрдәге кебек яшәп була... Бездә хәзер бәрәңге утыртмыйлар, терлек асрамыйлар, сөтне сатып алалар. Тик авыл җирендә яшәгәч, боларның барысы да үзеңнеке булырга тиеш дип саныйм мин. Авыл халкы үрнәк алмасмы дип, бәрәңге дә чәчтем. Янган йортыбыз урынына теплица куйдым – помидорлар утырттым...

Татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова тәкъдименә каршы килмичә, Тәтеш районында оешманы җитәкләргә алынуы да авылларны үзгәртергә теләүдән.



Районда ундүрт татар авылы бар – һәрберсендә «Ак калфак» оешмасы эшли бүген. Барысында да театр бар! «Нәни энҗеләр», «Татар малае» бәйгесе үткәргәннәр. Гомер күрмәгәнне, Тәтеш татарча сөйләшә башлаган! Моңа иң сөенгәне – өлкәннәр. Әбиләр шалтыратып: «Рәхмәт, кызым!» – диләр аңа.

«Мин көчле булырга тиеш...» 2013 елны бу сүзне аңа ике тапкыр әйтергә туры килә. Башта гыйнвар аенда йортлары янып китә, аннан сентябрьдә олы уллары авариягә очрый. Хәер, «Мин – көчле...»не көнгә түгел, сәгатенә меңне кабатлаган мәлләре дә була: Эльвир ике ай буе комада ятканда, ул күзен ачканнан соң да... Аннан үзенә сүз бирә: «Башка еламыйм! Күз яшьләрем аңа булышмаячак, улымны аякка бастыру өчен иң элек үземнең аякта нык басып торуым кирәк!» Өмет тулы алты ел узган инде менә. (Кемгә охшап сабыр, нык һәм көчле булырга тиешлеген белә ул – әнисенә! Тугыз бала табып үстергән Сара апа дүрт баласын җирли. «Әни өйдә җырлый иде дә, аннан елый иде – кайгысын кешегә чыгып сөйләмәде, – ди. – Ул шул хәсрәткә дә түзгән, ә минем улым бит исән! Көннән-көн алга бара... Сеңлем Гөлзифа белән киявебез Наилгә рәхмәтлемен: Эльвир янында алар булмаса, миңа эшне күптән ташларга туры килер иде инде».)

Барыбер, яшәргә, алга таба атларга – көчле булып калырга кирәк...

– Балаларга яшь вакытта биргән тәрбия гомергә кала. Туганнар белән очрашканда әни белән әти әйткән сүзләрне гел хәтергә төшерәбез... Үз әниемнең дә, кайнанамның да рәнҗүен алмаска тырыштым. Минекеләр инде мәрхүмнәр, Рәмиснекеләр, шөкер, исән-сау. Әти-әнисенә бик булыша ул. «Син аларга ничек ярдәм иткәнне улыбыз да күрсен, Эмильне үзеңнән калдырма – ул бит безне кабатлаячак», – дим. Чүпрәлегә, Чынлыга гел икәү кайталар хәзер. Әти-әнисе догада, теләктә булганга Рәмиснең, минем эшләр уңышлы барадыр дип уйлыйм.

«Ак калфак»ка йөрүче ханымнарга гел әйтәм: «Гаиләнең ныклыгы – хатын-кыз кулында. Кызларга моны адым саен искәртеп торырга кирәк», – дим. Килен булып төшүгә кайнанамнан: «Рәмис нәрсәләр ашарга ярата?» – дип сорадым. Үзем белдемме икән моны, берәрсе өйрәттеме икән? Бөтен ир-ат та әнисе пешергән ризыкны ярата. Коймакны, кыстырымбыйны (кыстыбыйны безнең Чүпрәледә шулай диләр) нәкъ кайнанамча пешерәм. «Әни ашы!» – дип ашый Рәмис. Авылларыбыз бер-берсеннән ерак булмаса да, мин туып-үскән Яңа Ишледә башта табынга – чәй, аннары аш чыгаралар. Рәмисләрдә – киресенчә. Мин дә беренче көннән аларча эшләдем. Ир йөрәгенә ничек юл табарга икәнен кызларыбызга сөйләргә кирәк. Оныкларыма бу хакта инде әйткәлим – үсеп киләләр бит...









ҖЫЕШТЫРЫР ӨЧЕН – ТУЗДЫРАБЫЗ?!

(үзгәрергә теләмәгән кешеләргә уку тыела!)



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Елена Тимина – өч бала әнисе, хуҗабикә. Моннан ике ел элек «Жизнь – волнующее волшебство уборки» фильмын караганнан соң, тормышында кисәк борылыш ясый. Фармацевтика өлкәсендәге карьерасын калдырып… өй җыештыру эшенә керешә. Курслар уза, мастер-классларда катнаша, системалы рәвештә өйдәге әйберләрне тәртипкә салырга өйрәнә. Гаҗәп, әмма өйдә пөхтәлек урнаштыру өчен дә махсус белем алырга кирәкме икән?! Монда нинди сер булырга мөмкин? Еленаның үзен тыңлап карыйк әле.

Өйдә тәртип урнаштыру серләренә өйрәтүче курска йөрүемне белгәч, кайнанам бик гаҗәпләнде. Аның фикеренчә, өй җыештыруда бернинди сер дә була алмый. Һәм чит кешене өй җыештырырга өйрәтәләр димени?! Һәр кыз бала үз әнисеннән өйрәнә торган эш бит ул: алдың – куйдың, төрдең – салдың…

Ә замана үзгәрә, кызлар. Яңа технологияләр барлыкка килә, көлешә-көлешә өстәл янында кайнатма белән чәй эчеп утыруларны – социаль челтәрләрдә аралашулар алмаштыра. Без бит һәрвакыт камиллеккә омтылабыз! Телләр өйрәнәбез, физик тәнебез турында кайгыртып фитнеска йөрибез, аш-су әзерләү осталыгын үстерәбез. Өйне тәртипкә китерү буенча да уңайлы система уйлап табылган икән, нигә аны кулланмаска, ди?!

Чынлыкта, өй җыештыру серләренә өйрәнү яңалык түгел инде ул. Безнең әби-бабайларыбыз да өйләрен бик пөхтәләп тоткан бит. Затлы нәсел кыз балалар институтында да (Институт благородных девиц) фәнни гыйлем бирү белән бергә кызларны хуҗалык эшләренә дә өйрәткәннәр. Хатын-кыз кулы кагылган җирдә тормыш энергиясе кунып калганны ул чакта ук аңлаганнар!

Гаҗәпләнмәгез, әмма чынлап торып өй җыештыру өчен өч айдан алып алты айга кадәр вакыт китәргә мөмкин. «Өйне гомергә бер җыештырып чыгалар. Аннары шул тәртипне саклап кына яшәргә кирәк», – ди үзенең өй җыештыру системасын уйлап тапкан Мари Кондо. Әлбәттә, өйнең һәр бүлмәсен ничек җыештыру, әйберләрне дөрес итеп саклау турында бик күп итеп сөйләргә, хәтта журналның бер санын шуңа багышларга булыр иде. Әмма бу мөмкин эш түгел. Шуңа иң мөһим кагыйдәләр турында гына сөйләшербез.

Фотолар: Елена Тимина архивыннан

Җыештырыр өчен – туз-дыра-быз!

Нәрсәдән башларга дисезме? Яшәргә комачаулаган, файдасы булмаган, кирәксезгә урын алып торган, шатлык китермәгән һәрнәрсәне ташларга әзер булудан! Уегыз белән моңа әзер булсагыз – алга таба хәрәкәт итәрбез.

Өй җыештыруны… шкафларны туздырып ташлаудан башлыйбыз. Туктагыз, тукта! Бөтен шкафны берьюлы бушатып куя күрмәгез. Иң элек күңелдән генә эш тәртибен билгелик. Мин, беренче эш итеп, киемнәрне тәртипкә китерергә киңәш итәр идем. Аннан, мәсәлән, аш бүлмәсен, ванна, йокы бүлмәсе, ишектән кергән өлешне, китап киштәләрен җыештыруны планлаштырырга була.

Тәк. Шкафны бушатыйк, барлык киемнәр дә күз алдында булсын. Киштәләрдәге тузанны сөртәбез дә, яныбызга ике капчык алып килеп куябыз. Хәзер барлык киемнәрне өч өлешкә бүләбез: яраксыз, ташлый торган киемнәр; сыйфаты буенча әйбәт, әмма күптән киелмәгән киемнәр – мохтаҗларга бирергә яки сатарга була торганы; үзебезгә кала торганы. Күптән алган кием белән кайчак аерыласы килми икән ул! Андый

Иске әйберләрне, кием-салымны озак саклау – безне үткәнгә «бәйләп» тота.

вакытта Мари Кондо киемне кулга алып, аның безгә киләчәктә шатлык китерәчәкме, юкмы икәнен тоеп карарга киңәш итә. Кием илһамландырмый һәм әле аны алыштырырлык тагын берничә шундый ук кием бар икән – мохтаҗларга бирергә дигән капчыкка «озатабыз». Киелер әле, ярар әле дигән акланулар саналмый. Юкса тагын ике-өч айдан нәкъ шундый ук эшне башкарырга туры киләчәк.

Кызлар! Бер әйберне дә «аннары кулланырмын» дип, «кара көнгә» калдырмагыз! Нәрсә көтәсең – шул каршыга килә. Шуңа күрә «киләчәктә тагын да яхшырагын алырга җай чыгар әле», диегез! Киткән урынына яңасы килә. Бу – тормыш балансы.

Карагыз әле, шкафтагы тирән киштәләр һәрвакыт аерым игътибар сорый. Аларда еш кына инде без күптән оныткан, эзләп тә таба алмаган әйберләр «югалып» ятучан була. Андагы киемнәрне бушаткannan соң, аның үлчәмен алып, махсус тартмалар (контейнер) алып кайтыгыз. Хәзер кибетләрдә кием саклау өчен бик күптөрле тартмалар сатыла бит. Эчке кием, носкилар, футболка-майка, балалар колготкиларын һәм башкасын… Менә шундый төркемнәргә бүлеп тутырганда әйберне тиз генә табуы да, шкафны тәртиптә тотуы да бик уңайлы! Тирән киштәләргә бер-берсе өстенә куела торган ике үтә күренмәле тартма урнаштырабыз. Астагысына сирәк кулланыла торган яки бу сезонда кирәк булмаган әйберләрне салып, капкач белән томалап куябыз. Өстәгесен көндәлек кирәк әйберләр өчен кулланырга була. Кирәкле киемнәр күз алдында булсын өчен аларны тартмаларга вертикаль рәвештә урнаштыру җайлы. (Киемнәрне аз урын ала торган итеп төрергә өйрәткән бик күп видеолар бар интернетта!)

Кайсы киемнәр ешрак киелә, кайсыларына кул да тимәгәнне аңлар өчен шкафтагы кием элгечләренә киемнәрне әйләндереп элеп чыгабыз. Бер-ике айдан карагыз инде: кайсы киемнәр әйләндерелмәгән, димәк, шулар киелмәгән.

Киштәләргә урнаштырганда күләмле һәм кара төстәге әйберләрне арткарак, якты төстәге юка киемнәрне алгарак куябыз.

Йә, күрегез әле, шкаф ничек бушап калды! Димәк, өйдә яңа дулкын энергия дә барлыкка килде дигән сүз!

Киемнәрне тәртипкә салып бетергәч, теге ташларга, башкаларга бирергә дигән капчыклар балконга гына чыгып китмәсен. Балконга чыккан әйберләрнең озакка кала торган гадәте бар. Капчыкларны ишек төбенә куеп, икенче көнне үк аларны тиешле җиргә урнаштыру җаен карагыз!

Башкалар идеаль мәхәббәт табарга тырышканда, Мари Кондо үз киемнәрен шкафка **идеаль рәвештә урнаштыру җаен эзли.**

Аш бүлмәсе

Хуҗабикәләр өчен аш бүлмәсе илһам чыганагы, иң яраткан урын ул. Көнебез шуннан башланып, шунда тәмамлана бит. Әйдәгез, анда да кереп чыгыйк.

«Шатлык китерми торган визуаль информациядән арынып, үзегезнең тирәлекне күпкә уңайлырак һәм тынычрак итә аласыз», – ди Мари Кондо. Күз салып карагыз әле, чынлыкта безнең аш бүлмәсе, шкаф эчләре игътибарны үзенә җәлеп итә торган этикеткалар белән тулы. Макарон, чәй каплары, төрле ярмалар салынган пакетлар... бигрәк күп алар! Этикеткалардан арынып, ярмаларны уңайлы контейнерларга бушатабыз. Кайберләре өчен пыяла банкалар кулланса да ярый.

КИҢӘШЛӘР:

- Аш бүлмәсе җыештыруны да кирәкмәгән әйберләрдән арынудан башлыйбыз. (Алюминий кәстрүлләр, чатнаган чынаяк-тәлинкәләр, әллә каян ияреп кайткан пластик савыт-саба, хәзер куллана торганнарына туры килми торган чәнечке, кашыклар, иске себерке, сафтан чыккан техника... Берсе дә калмасын!) Өйдә, бигрәк тә аш бүлмәсендә һәрвакыт илһамландыра торган әйберләр генә булырга тиеш!
- Өстәл, плитә өсте, шкаф алдындагы эш өстәлен һәр көнне сөртеп тору хәерле. Атна ахырына калса, химия кулланып юарга туры киләчәк аларны.
- Аш бүлмәсендәге әйберләр категорияләргә бүленеп сакланырга тиеш. (Ярмалар, яшелчәләр, тастымалсөлгеләр, юганда кулланыла торган химия әйберләре һәрберсе билгеле бер урында саклансын.)
- Сирәк кулланыла торган әйберләрне ераграк киштәдә сакларга кирәк.
- Тәмләткечләрне пакетларыннан кечкенә банкаларга бушатып саклау җайлы.
- Капкачларны һәм табаларны вертикаль рәвештә (болай урнаштырырга мөмкинлек бирә торган җайланмалар кибетләрдә сатыла) кәстрүлләрдән аерым куябыз.
- Аш бүлмәсендәге сөлге-тастымалларны ешрак алмаштырабыз.
- Рецептлар язылган китаплар аш бүлмәсендә сакланырга тиеш.
- Аш бүлмәсендәге алтын кагыйдә – алган әйбереңне урынына куй.

Әни – ул өйдәге чисталык

Миллион эшлә һәм бәхетле бул! Социаль челтәрләрдәге бизнес-тренерлар хатын-кызларны бертуктаусыз акча эшләргә чакыра. Шул миллион артыннан йөреп, балалар төрле түгәрәкләргә таратыла, өйдә җылы ризык пешми, гаиләнең бер өстәл артына утырып сөйләшә-көлешә чәй эчәргә вакыты җитми башлый. Гаиләдәге мәхәббәт учагы сүнеп барганда, кесәдәге миллион ярдәм итми шул... Еш кына хатын-кызлар ирләрнең эштән соң өйгә кайтмауларына зарлана. Йә дуслары белән очраша алар яки машина гаражында эшләре күбәя – сәбәпләр чыгып кына тора! Беләсезме, безнең өй, фатир, кайчак кирәкмәгән әйберләр белән шыплап тула, анда хәтта ир кеше энергиясенә урын калмый башлый. (Игътибар итегез әле: гаилә башлыгы утырып ял итә торган кәнәфи сездә нәрсә өчен хезмәт итә? Үтүкләнмәгән керләр, балалар киемнәре эленмәгәнме аңа? Гардероб ролен үтәмиме ул? Кайвакыт шулай да була!) Ә менә өй җыештырылгач, һәр әйбер үз урынын алгач, аш бүлмәсеннән хуш исләр чыга башлагач, гаражда гомерен үткәргән ирләрнең өйгә кайтасы килә башлый. Балалар да өйгә, әни янына тартыла. Гаилә җылысы арта, өйгә бәхет тула. Күп кенә хуҗабикәләр мине үзләренә ярдәм итәргә чакыра. Бергәләп өйне тәртипкә китерәбез, начар энергиядән арындырабыз. Шуннан соң гаиләләрдә нинди үзгәрешләр башланганны күрсәгез иде?!

Балалар почмагы

Балалар дигәннән... Өйдә кечкенә балалар булганда нинди тәртип инде ул, дип каршы төшә яшь әниләр. Әйе, балалар шау-гөр килеп, һәр әйберне туздырып ташлап уйнарга ярата. Әмма һәрнәрсәнең (балалар уенчыкларын бигрәк тә!) үз урыны бар икән – балалардан соң өйне тәртипкә салырга 15 минут вакыт җитә.

Беренчедән, баланың уенчыклары без уйлаганча күп булырга тиеш түгел. Уенчык күп булганда бала өчен әйбернең кадере бетә. Берсе белән уйный, икенчесе, өченчесе... Берсе җимерелсә, икенчесе була, машина җимерелсә, яңасын алалар... Үскәч, бу сыйфат кешеләр белән мөнәсәбәттә чагыла башлый икән: дусларны, сөйгән ярларны кадерли, саклый, бәяли белмәү...

Икенчедән, без үзебез дә – әле уйнап туймаган балалар. Уенчыкларны балага кирәк булган өчен генә түгел, үзебез кызыкканга да алабыз. Безнең балачакта булмады, янәсе... Аннары, балалар бүлмәсен җыештырганда, инде уйнамасалар да нәкъ менә шул уенчыкны ташларга, кемгәдер бирергә кызганыч була. Кибеттә уенчык сайлаганда да хис белән түгел, акыл белән эш итәргә кирәк дим, кызлар!

Перфекционист булырга да өндәмим. Балалар почмагында уенчыкларны төркемнәргә бүлеп, аерым тартмаларга тутырырга кирәк. Еш уйный торганнары, сирәк куллана торганнары, лего детальләре... Бала кайдан нәрсә аласын белергә тиеш. Кечкенә генә машина көпчәген эзләгәндә зурдый уенчык тартмасын бушатып ташларга туры килмәсен!

Шулай ук бу кагыйдә башка әйберләргә дә кагыла: йоклаган җирдә – йокы киеме, эш өстәле янында ручка-карандашлар, спорт кирәк-ярагы аерым кәрзиндә саклансын.

Нәрсәнең кая куярга кирәклеген белгәндә баланың үзенә дә җыештырырга рәхәт була. Балалар бүлмәсе һәрчак ялт итеп торырга тиеш дигән сүз юк. Бары һәр әйбер үз урынында торсын. Балалар бит алар төрле була! Һәрберсе тәртипне үзенчә күз алдына китерә.

Уенчыклар алып уйнарга да җайлы булсын; курчак, машиналарны – аскарак, пластилин, буяуларны өскәрәк куярга кирәк.

Мәктәп укучыларының дәрес әзерли торган өстәле ишеккә яны белән торса яхшы. Бала арты белән ишеккә утырса, үзен ышанычсыз хис итә, борчыла башлый икән.

Балалар даими гадәтләр булуын ярата. Һәр кичне аерым бер сәгатьтә өйне тәртипкә китерү гадәтен кертегез. Һәркем үз зонасын кайгыртсын: әни – аш бүлмәсен, балалар – уенчыкларын, әти кеше үз эшләрен карасын. Бу бик файдалы гадәт, чөнки иртән торганда сезне пөхтә өй каршы алачак, иртәнге җыенулар тизләнәчәк.

Балаларның кул эшләре белән нишләргәме? Өйнең бер өлешендә күргәзмә зонасы булдырыгыз. Яңаларын шунда куеп, килгән кунакларга күрсәтергә, баланың дәрәҗәсен үстерергә була. Күптән ясалганнарын фотога төшереп, үзегездә саклап калганнан соң, кемгәдер бүләк итегез.

Балалар өчен сезнең гадәтләр үрнәк булып тора, чөнки бала өчен әни ул – чисталык, өйдәге пөхтәлек булып күзаллана.

Дөрес гадәтләр

Дөрес гадәтләр кертүне өстәлдән башларга тәкъдим итәм. Менә хәзер аш бүлмәсенә керегез дә, өстәлне бушатыгыз әле. Бернәрсә дә калмасын анда! Борыч, тоз, шикәр комы, кайнатманы шкафка ук алып куярга була. Өстәл уртасына тыйнак кына чәчәк бәйләме дә куеп җибәрсәң – аш бүлмәсе шундук ямьләнә! Тәмле кичке аш пешерәсе яки хуш исле чәй эчеп куясы, матур күлмәк киеп җибәрәсе килә! Өстәлне аннары җыештырырмын әле дип калдырасы түгел, ашапэчүгә үк ялт итеп куярга кирәк аны. Ипи валчыкларын җыеп, тапларны сөртеп, савыт-сабаны алып куярга 5–10 минут вакыт җитә. Ә нәтиҗәсен – үзегез бәяләрсез.

Икенче матур гадәт итеп чиста раковина кагыйдәсен алыгыз. Бер юылмаган тәлинкә, икенчесе... Раковинада юылмыйча калган бер әйбер икенчесен, өченчесен бик тиз тартып китерә, таулар өелә анда. Ә тәлинкә-кәстрүл «тавын» аннары озаклап җебетергә күпме вакыт сарыф итәргә кирәк. Һәр кич чиста раковина калдыру гадәтен кертегез. Гамәлне гадәт итеп кертер өчен 21 көн дәвамында эшләргә кирәк.

Еш кына шулай була: шимбә-якшәмбе көннәре – әнинең өй җыештыра торган көне. Гаилә беркая да бармыйча әнине көтә. Ә бит атна буе көнгә ярты сәгать кенә җыештыруга, юуга багышлыйсың икән, ял көннәренә эш кими. Балаларны, ирләрне дә ярдәмгә чакырып, бергәләп эшләп куйганда ялыктырмый да, аннары гаилә белән бергәләп кайдадыр барып ял итеп кайтырга да вакыт кала.

Тагын бер гадәт: өйдә хатын-кызның ял итә, уңай энергия ала торган үз почмагы булырга тиеш. Кырыена лампа куелган уңайлы диван, өстәл, чәчәкләр үсә торган балконлы бүлмәме ул... Үзегез турында да онытмагыз, кызлар!

Кайсы гына бүлмәгә тәртип урнаштырырга тотынсагыз да, эшне бер кирәксез артык әйберләрдән арынудан башлагыз. Башта киемнәр, аннары аш, ванна, кунак бүлмәләре, балалар почмагына күчәргә була. Документлар, аяк киемнәре, китаплар, эш коралларын тәртипкә салыгыз. Шулай итеп, өегездә яңа тормыш башланганны сизми дә калырсыз әле! Сүземне йомгаклап шуны әйтәм, кызлар, безнең өйдә хәзер һәркем кибеткә баруга бик җаваплы карый. Нәрсәдер сатып алганда аны кайсы җирдә, нинди урында саклыйсын күз алдына китерәбез. Азрак әйбер кулланабыз, шуның белән планетабызга да файда китерәбез!

Сүз уңаеннан

Иске әйберләрне ташлый алмауның өч сәбәбе:

1. Чөнки алар – үткәннән бер истәлек...

Көндәлекләр, запискалар, инша дәфтәре, иске концерт билетлары, кипкән роза чәчәге, борынгы өстәл, урындык... менә шулар аша үткәнгә таянып торабыз. Алардан арынып, бүгенге көн белән яшәр вакыт. Өегездә узган тормыш энергиясен яшәтмәгез. Кулланмый торган әйберләрдә бик күп тискәре энергия җыела, һәм ул ялкаулыкка, хроник ару халәтенә, депрессиягә китерә, бик күп яшәү көчен үзенә суырып тора, ә тузаныннан аллергия була.

2. «Бу әйберләрнең барыбер бер кирәге чыгачак әле!»

Үкчәсе уңайсыз булган туфли, «ябыккач кияргә» дигән джинсы чалбар, яңасы җимерелгәнне көтүче иске телефоннар, совет заманында чыккан энциклопедияләр... Психологлар, иске әйбергә чат ябышу – хәерчелеккә китерә, ди...

3. Без бик сакчыл булырга өйрәнгән.

Төрле журналлар, китаплар, иске кедалар, уенчыклар, кулланылмый торган техника, банкалар һәм тагын бик күп әйберләрне антресольдә, балконда, бакчада озаклап сакларга яратабыз. Сугыш чорында үскән дәү әни-дәү әтиләргә әйбер ташлавы кыен, ә бездә – геннар...


Фото: Анна Арахамия

Мәдинә АВЗАЛОВА

«САЙЛАГАНЫМ ГОМЕРЛЕК»

Исеме республикада иң яхшылар рәтендә йөргән Кукмара районы баш педагогының үткәне дә, бүгенгесе дә гел «бишле» билгесе белән генә бәяләрлек.

Бик ялындырып кына килгән һәм эссе-кояшлы көннәрен бик иренеп кенә күрсәткән җәй сиздермичә генә үтеп бара. Ай күрде, кояш алды быел җылы җәйләрне. Саубуллашмый китеп тә бара әнә. Ә шулай да ул көнне искиткеч матур иде. Зәңгәр күктә ап-ак болытлар йөзә. Ә без килеп эләккән сихри дөнья шау чәчәктә, агач яфраклары да әле саргаерга өлгермәгән. Җирдәге кып-кызыл алмалар, коелган чәчәк таҗлары көзнең бусагада гына икәнлеген искә төшереп тормаганда, барысы да әйбәт.

Мондый гына матурлыкка иялəнгән күзебез шунда ук ал җилкәннәрен җилдә уйнатып, бакча уртасында утырган нәни корабка төшә. Төшме бу, әллә өнме дип, бермәл хәйран калып торабыз. Уенчык дисәк, уенчык түгел, шактый зур күренә, әнә штурвалы да бар. Ә шул штурвал артында – әле генә безнең каршыбызда җитдидән-җитди булып, үзен борчыган темаларга гәп куертып утырган героебыз Роберт Мияссәр улы Мансуров. Үз куллары белән ясаган корабның капитаны да, матросы да – ул үзе. Кораб янында гына таштан өеп ясалган кыя, аннан шаулап су ага. Йә, кем әйтмәс, корабны диңгез кичеп килә дип?! Ул штурвалны әйләндерә башлауга, кораб та хәрәкәткә килә: әкрен генә әйләнә башлый.

«Оныкларыма дип ясадым», – ди ул, үзе ясаган уенчыгы белән үзе уйнавына уңайсызлангандай булып. Без аны аңлыйбыз. Хәзер ул күңеле



Алар әйтерсең икесе бер калыптан сугылган. Бәлкем, икесенең дә бер өлкәдә эшләүләре ир белән хатынны әнә шулай бер сулышта яшәргә өйрәткәндер.

белән безнең янда түгел, әллә кайларда – Каф таулары артында, Кара диңгез уртасында... Хәрби-диңгез флотына хезмәткә алынган егетнең бөтен язмышын, ярга бәргән дулкыннар шикелле, бер селтәнүдә үзгәртеп ташлаган ул көннәрне Роберт Мансуров һич онытмый.

– Фуражкаңны да ки инде, – ди, безнең янда басып, шушы тамашаны күзәтеп торган хатыны Розалия.

– Ничә тапкыр әйттем сиңа, фуражка түгел, бескозырка дип. Син бит моряк хатыны! – Ул шулай ди дә, рәхәтләнеп бер көлеп куя.

«Укымышлы, зыялы нәселдән»

Әңгәмәбезне ерактан башлыйсы итәбез. Хәер, ул үзе дә сүзне кайчандыр Кукмара районының Ятмас Дусай авылында эше-холкы, уңганлыгы, зыялылыгы ягыннан димме, бар яктан дан тоткан әби-бабаларын искә алудан башлап җибәрә. Районда гына түгел, республикада иң борынгы авылларның берсе булган Ятмас Дусайның беренче старостасы булган, заманында күп итеп атлар тоткан Яппар бабай турында да, сәүдәгәр дә, эшмәкәр дә булган дип, горурланып сөйләп ала. Аның бабасы Мансур көчле, гайрәтле, укымышлы кеше булган. Агач эше остасы да үзе, умартачы, яхшы финансист дигән сүзләр дә аңа кагыла. Нинди генә җиһазлар ясамаган, кемнәрне генә куандырмаган ул осталыгы белән! Гармун ясарга өйрәнәм дип, Казанга чаклы барып җиткән. Гармуннар ясый торган фабрикага эшкә урнашып, тальян гармун ясарга өйрәнгән. Гармунда уйныйсы, шуңа кушылып җырлыйсы килгән аның...

– Мансур бабай сугышта сапер була, – дип сөйли нәсел-нәсәбәсе турында энәсеннән җебенә кадәр белгән әңгәмәдәшем. – Ул Калуга өлкәсенең Жиздри елгасы буенда – Пузановка авылы янында һәлак була. Бу – 1943 елның 14 июле. Коточкыч бәрелешләр. Безгә: «Рәт-рәт – совет солдатлары, рәт-рәт немец солдатлары яткан», – дип сөйләделәр. Сугыш беткәннән соң һәлак булганнарның каберен Пузановка янәшәсендә урнашкан Высокая авылына күчерәләр. Әтием Мияссәр ул чагында – бу 2014 ел – исән иде әле. Әти, Мөдәрис абый, сеңлем Нурия белән бергә бардык. Шул авылның мәктәп директоры янына кердек. Музейда булдык. Анда бабайның исемен үлгәннәр исемлегеннән эзләп таптык. «Баһаутдинов Мансур» диелгән, башка мәгълүмат юк. Бабай күмелгән җирдә нарат үсә. Шу ның бер кечкенә үсентесен алып кайтып, авылыбыз мәктәбе янына утырттык. Ул һаман да үсә әле.

Алар музейдан башка документлар да алып кайта. Солдат йөргән юллар буйлап сәяхәт кыла, үзләре белән алып килгән самавырда чәй кайнатып эчә, блиндажларда йөри. Аннан кайткач, туган авылларындагы музейда Мансур бабай турында да истәлекләр пәйда була.

– Хәзер әни ягыннан булган Васыйл бабабызның каберен эзлибез, – ди Роберт Мияссәр улы. – Ул да 1941 елны сугышка китә дә хәбәрсез югала.

«Әти портреты белән янәшә»

Әтисе Мияссәр Мансуров турында ул аеруча дулкынланып сөйли. «Феноменаль хәтерле, олы шәхес иде», – ди. Чыннан да, шулай булган. Хезмәт юлын трактор йөртүдән башлаган егетнең булганлыгын күрепме, әллә тәвәккәллек сыйфатларына сокланыпмы, башта бригадир, аннары «Алга» колхозы рәисе итеп билгеләләр. Бераздан Кукмара хуҗалыкара төзелеш оешмасын җитәкли. Фидакарь хезмәте өчен ике мәртәбә «Почет билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы, «Ветераннар хәрәкәтендәге казанышлары өчен» орденнары белән бүләкләнә. Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе. Районда мәктәпләр, балалар бакчалары салуга керткән тырышлыгы өчен «Халык мәгарифе отличнигы» дигән исем дә бирелә аңа. «Әтиле-уллы икебезнең рәсем район Мактау тактасында янәшә эленеп торды», – ди Роберт Мияссәр улы.



Роберт Мияссәр улы һаман да диңгез белән хыялланып яши. Аның хис-тойгылары шулай итеп рәсемнәрендә чагылыш таба.

Эшкә таңнан чыгып китеп, төн уртасында гына кайткан әтисен малай сирәк күрә. «Безне – өч баланы – әни үстерде, аның йөзеннән беркайчан да елмаю китмәде. Күзләре гел көлеп тора иде. Кояш иде ул», – дип искә ала да: «Утын ярырга, балта сабын сапларга кадәр өйрәтте ул безне», – дип, янә әнисен мактап куя. Тормышта барысының кирәге чыга соңыннан. Балта-чүкеч тота белү, рәсем ясау, бизәү эшләре... Хәтта чәч алырга өйрәнү дә ярап куя. Монысы инде – армиядә. Матросларның чәчен алдырырга кирәк була башлагач...

86 яшенә җитеп мәңгелеккә күчкән Мияссәр ага соңгы сулышынача актив җәмәгать эшлеклесе була. Ул – районның ветераннар советы җитәкчесе дә, республика ветераннар советы Президиумы әгъзасы, җиде районга куратор да. Иң беренче яңалыкны районгашларына җиткерүче, үзе яшәгән Зур Кукмара авылында урамнарга асфальт сал-

PRESSA

Анда – ата-бабалары каны:

эшне ахырынача җиткерү, һәрчак беренчеләр сафында булырга омтылу аңа да хас күренеш.

дыручы, мәктәп, терлек комплексларын сафка бастыручы, мәчет-чиркәүләр төзүче... Әнә никадәр игелекле эшләр! Шуңа Зур Кукмарадагы музейның һәм аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү гомумбелем мәктәбенең Мияссәр Мансуров исемен йөртүе, анда үткәрелә торган милли ярышларның аның хөрмәтенә узуы бер дә гаҗәп түгел.

Яшьлек еллары

Баһаутдиновлар тамырыннан килгән данлыклы Мансуровлар нәселен дәвам итүе җиңел булмый аңа. Республикада дан-шөһрәт казанган әтиең портреты янәшәсендә тор да! Ул монысын соңыннан – яши-яши аңлый әле. Ә аңарчы... аңарчы бүген ирешкән үрләренә барып җиткәнче, кем әйтмешли, җиде пот тоз ашарга, язмышының ачы җилләренә бирешмичә, сынмыйсыгылмый калырлык көчле ир-егеткә әйләнәсе бар! Ә андый егетләрне кайда үстерәләр? Әлбәттә инде, армиядә! Аны 1976 елны армия хезмәтенә алалар. Хезмәтнең дә ниндиенә әле! Бик сирәкләр генә эләгә торган Хәрби-диңгез флотына! Инеш суыннан башканы белми үскән егет өчен диңгезне күрү, флотта хезмәт итү үзе бер ачыш була. Менә шунда чыныгып кайта да инде ул.

Аннары... Латвиядә өйрәнүләр үтеп, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән гидроакустик һөнәрен үзләштергән, өч ел буена диңгез киңлекләрен айкаган, Сирия чикләренә кадәр барып җиткән диңгезче, хезмәт итеп кайтуга, Казан педагогика институтының география бүлегенә укырга керә. Таныш булмаган илләр, ымсындыргыч җирләр тарта күңелен. Студент елларында да әти-әни кесәсенә карап ятмый ул. Төзелеш отрядлары белән Бөтенсоюз удар төзелешләрендә катнашып, Себергә кадәр барып җитә. Төннәрендә боз каткан, көндезләрен эсселек 40 градускача күтәрелгән якларның ак төннәрен күрә. Табигатьнең бу могҗизасына температураның кискенләшүе сәбәпче икән ләбаса. Студент елларында туган ягы Кукмараның Вахит, Әсәнбаш, Интернациональ хуҗалыкларында комплекслар төзүдә катнаша. Шунда беренче һәм, үзе әйткәнчә, соңгы мәхәббәте – Минзәлә кызы Розалия белән таныша.

Укытучылар гаиләсе

Бер курста, бер төркемдә укыган егет белән кызга бергәләшеп озак кына төзелеш отрядларында эшләп йөрергә туры килә әле. Алар 1983 елның 27 августында, IV курста укыганда өйләнешә.

– Балдакны Украинага практикага баргач алдык, – дип искә ала еракта калган ул чакларны Розалия ханым. – Әле дә хәтерлим: алтын балдакның бәясе 100 сум тора иде. Институтны тәмамлагач, әлбәттә инде, Кукмарага кайттым. Ир кайда, хатын шунда...

Белгечләр җитмәгән чак. Яшь укытучыларны көтеп алалар. Роберт Мияссәр улын – 3 нче мәктәпкә, Розалия ханымны 2 нче мәктәпкә география укытырга җибәрәләр. Розалия Мансурова шул мәктәптә 25 ел эшләп, «Татарстанның атказанган укытучысы», «Россиянең мактаулы мәгариф хезмәткәре» дигән исемнәрне алып ялга чыга. «Аның бер генә укучысы да ул укыткан фәнне «өчле» билгесенә бирмәде. Гел «дүртле», «бишле»ләргә генә укыды. Ул мәктәп дип яшәде», – ди гаиләдә – ир, эштә җитәкчесе булган Роберт Мияссәр улы.

– Кече кызым Айгөлнең унынчы сыйныфта укыган чагы, – дип әлләтереп ала аның сүзен Розалия ханым. – Мин җитәкләгән сыйныф унынчыны тәмамлап чыгып китте дә, бишенче сыйныфны алырга ниятләп йөрим. Шул чагында кызым елый-елый әйтте: «Әни, башка сыйныф алма, син миңа караганда укучыларыңны күбрәк яратасың», – диде. Мин олы кызым Гөлназның сыйныф җитәкчесе дә идем әле. Роберт өйгә йокларга гына кайта, аның эше гомергә җаваплы булды. Инде мин дә өйдә сирәк күренә башласам дип, уйга калдым аннары.

«Әйбәт кеше булу бик авыр...»

Роберт мәктәптә озакка калмый. Өч еллап эшләгәннән соң, аның сәләтен, эшкә бирелгәнлеген, тынгысызлыгын күреп, шундук таркала барган Ядегәр мәктәбенә җибәрәләр. «Анда синең кебек эшнең рәтен белгән егетләр кирәк», – диләр. Барып, җиң сызганып эшкә керешә: мәктәпкә капиталь ремонт үткәрә, спорт комплексы төзетә. Моңарчы күрелмәгән хәл. Сәләтле балалар өчен авылда музыка мәктәбе филиалы эшли башлый. Тормыш җанланып, авыл яшәреп киткәндәй була. Мәктәп гөрләсә, авыл да гөрли бит. Директор яшьтән һөнәр сайлауның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын Ядегәр мәктәбе укучыларына аңлата. Ничек итепме?! Мәктәптә йорт куяннары үрчетү фермасы оеша, суган, бәрәңге үстерү бригадалары эшли. Моңарчы пыскып кына янган учак шикелле яшәп килгән Ядегәр мәктәбе шушы уңышлары өчен Кызыл байракка лаек була. Ә ул үзе? Монысы аерым тарих...

Районның мәгариф бүлеге җитәкчесе, пенсиягә чыгар алдыннан, Роберт Мансуровны чакыртып ала да: «Районга кайт, минем урынга калырсың», – дип, аңа район мәгарифен җитәкләргә тәкъдим ясый. Егет каршы төшә. Юк, ул директор эшеннән бик канәгать. Аннан, дөресен әйткәндә, акчасы да күбрәк. «Инде ияләштем дә...» – ди Роберт. Берничә ай шулай каршы төшеп карый әле ул. Ләкин инде аның янына, кем әйтмешли, олы башын кече итеп райком секретаре Рим Зарипов үзе килеп төшкәч, «юк», дип әйтергә теле әйләнми, ризалаша. Ул да күп сөйләшеп тормый: «Әйдә, утыр машинага», – ди дә,

аны үзе белән район үзәгенә алып китә. Шуннан бирле 31 ел гомер бер мизгелдәй узган да киткән. Шул вакыт эчендә ул мәгариф системасына бик күп яңалыклар кертә, башкаларга үрнәк булырдай эшләре белән хәйран итәргә өлгерә. Аларның барысын да санап бетерерлек тә түгел. Соңгылары турында гына... Былтыр аның инициативасы белән кече яштәге балалар белән «Факел» спорт мәйданчыгында мастер-класс уздырыла. Анда меңләгән бала катнаша. Өстәлләр куела. Һәр өстәл янында – бер бала, бер эксперт. Нәкъ олы бәйгеләрдәгечә! Балага кече яшьтән, кечкенәдән һөнәри ориентация бирү була ул бәйгенең максаты. Сабый табигать биргән осталыгын балалар бакчасына йөргән чагыннан ук чарларга тиеш. Мәгариф башлыгы шулай уйлый. Уйлый һәм уйлаганын тормышка ашыру эшенә әнә шундый вак тоелган чаралардан керешә. Бу чарага Татарстанның Мәгариф һәм фән министрын да чакыралар. Шуның кадәр югары дәрәҗәдә оештырылган ул тамашаны күреп, министр хәйран кала. Кулларына микрофон тотып, өстәл тирәли йөргән мәктәп балалары – яшь журналистларның сорауларны инглиз телендә бирүе һәм инглиз телендә җавап ишетүе үзе бер ачыш була. «Әйе, инглиз телен балалар бакчадан ук өйрәнә, – ди мәгариф башлыгы, сораулы карашыбызны күреп. – Махсус шулай эшләдек. Быелдан берничә мәктәпнең 1–5 нче сыйныфларында укучылар техник фәннәрне дә бары инглиз телендә укыячак. Бу да бер яңалык».

Алар иң авыр елларда да мәктәпләрне саклап кала алганнар. Кукмара үзәгендәге кичке эшче-яшьләр мәктәбе дә, Мәчкәрә авылындагы коррекция мәктәбе дә, заман җилләренә бирешмичә, әйбәт кенә эшләп килә.

– Милли мәктәпләрне саклап калуны да зур казанышыбыз дип саныйм, – ди мәгариф башлыгы. – Районда алты удмурт мәктәбе бар. Нырьяда удмурт балалар бакчасы ачтык. Кукмара районы – дуслык эталоны ул.

Роберт Мияссәр улы Мансуровны узган ел Кукмарада уздырылган август киңәшмәсендә Президент Рөстәм Миңнеханов үзе «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкли. Ул бүген – педагогика фәннәре кандидаты, «Россия Федерациясенең атказанган укытучысы». Үз дәверендә җиде министр, алты район хакимияте башлыгы белән эшләргә туры килә аңа. «Әйбәт кеше булу бик авыр ул», дисә дә, моңарчы аның эшенә дә, үзенә дә моң-зар белдергән кеше булмады әле. Әйе, ул кырыс, таләпчән. Әмма эшләгән кешенең кадерен дә ул бик яхшы белә. «Шундый усал кеше белән ничек яшисең?» – дип сорыйлар. «Өйдә бер дә усал түгел ич ул», – дип елмая Розалия ханым.

Балалары

Кызлары Гөлназ белән Айгөл – әти-әнисенең горурлыгы. Икесе дә урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган. Икесе дә институттан кызыл диплом алып чыккан. Берсе – икътисадчы, икенчесе – юрист. Икесе дә шартлатып инглиз телендә сөйләшә. Кече кызлары Айгөл берара Иннополиста юридик киңәшче сыйфатында да эшләп алган. Хәзер ул Казанда урнашкан Мәскәү фирмаларының берсендә эшли. Олы кызлары Гөлназ гаиләсе белән Яшел Үзән районында яши. Дәрәҗәле оешмаларның берсендә икътисадчы вазыйфасын үти. Ире Самат белән ике бала үстерәләр.

– Кызлар икесе дә музыка мәктәбен тәмамлады, – ди әтиләре. – Җырчы булыгыз дип әйтмим, музыка ул күңел өчен кирәк, дидем. Хәзер әнә гитарада уйныйлар, җырлыйлар...


«Балага бер төрле сөйләп, икенче төрле яшәп булмый», – дип, миңа тәрбия дәресләре биреп алган баш педагогның сүзләреннән үзебезчә нәтиҗә ясыйбыз: булдыклы әти-әнинең балалары да үзләре шикелле тырыш, максатчан була шул!

Әтиләре кызларны машина йөртергә дә өйрәткән. Кирәге чыкмый калмас, дигән. «Бу ризыкны ничек пешерәсе? – дип, әле дә телефоннан киңәш сорап торган кызлары әниләреннән аш-су осталыгына өйрәнгән.

– Без балаларга кырысрак булдык шикелле. Анысы ярамый, монысы ярамый... Һаман тыя килдек. Балага бераз йомшак булырга да кирәк. Гел тыеп тору да дөрес түгел, – ди узганда калган кайтарып булмас ул елларны искә төшергәндә әти кеше.

Роберт Мияссәр улы: «Сайлаганым гомерлек», – дигәндә, мәгариф өлкәсендә 36 елдан артык эшләвен, аңа бүген дә тугры калуын күздә тотып әйтмидер, тормыш иптәшенең дә бер генә һәм гомерлек булуын искәртәдер!







Нәзифә
КӘРИМОВА

«КҮКРӘГЕМНӘН КОШЛАР ОЧЫРАМ...»

Быел көз Мостай Кәримгә 100 яшь тулган булыр иде... Аның бу зур юбилеен Башкортстанда да, башка төбәкләрдә дә бәйрәм итәчәкләр. Казан, Алматы шәһәрендәге урамнарга Мостай Кәрим исеме бирелде. Китапханәләрдә, мәктәпләрдә Мостай Кәримгә багышланган чаралар ел әйләнәсендә дәвам итте. Россиядәге күп кенә театрлар аның пьесаларын кабат сәхнәгә күтәрде. Хәтта быел аның әсәрләре нигезендә берничә нәфис фильм да төшерелде. Кемдер аны шагыйрь, драматург, публицист ди, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты икәнен хәтерли. Ә минем өчен ул беренче чиратта кадерле кайнатам иде...

«Илгиз – ул язучы малае, ә без синең белән авыл балалары», – ди торган иде әткәй.

* * *

Мостай Кәримнең улы, булачак ирем Илгиз белән без Мәскәүдә таныштык. Минем студент чак. Артист булырга хыялланган бер төркем яшьләр Татар филармониясеннән юллама белән Мәскәүгә Эстрада сәнгатенең Бөтенроссия иҗат остаханәсенә ике еллык курсларга укырга килгән идек. Илгиз инде Мәскәү дәүләт университетын тәмамлап, «Литературная Россия» газетасында эшләп йөри. Мин аның шундый зур язучының улы икәнен әле белмим. Мәскәү кадәр Мәскәүдә татар егете белән танышуыма гына шатланам: Илгиз белән кая гына барсак та гел татарча сөйләшеп йөрибез. Бервакыт ул миңа күрсәтергә дип үзләренең гаилә фотоальбомын алып килде. Фотосурәтләрне карый башлагач, таныш йөз чагылып киткән кебек булды. «Кара әле, синең әтиең Мостай Кәримгә охшаган икән», – дим. Үзем эчемнән генә: «Олы кеше бит инде, ә үзе бала-чага кебек кәчтүменә значок тагып куйган», – дип уйлап алдым. Авыл баласы аның күкрәгендә РСФСР депутаты значогы икәнлеген каян белсен инде?! Илгиз шунда ук альбомны кулымнан алып куйды. Берни дә аңлатмады. Мин аның кем улы икәнлеген ярты елдан соң гына белдем.

* * *

Безнең әле өйләнешкән генә вакытлар. Илгиз әтисе – киләчәктә «әткәй» дип эндәшәчәк кешем белән безне бер ел элек үк таныштырган булса да, кайнатам мине яхшы белгәндер дип уйламыйм. Әмма шуңа карамастан, Уфада узган безнең туй мәҗлесендә Мостай Кәрим: «Минем турыда соңгы китапны Нәзифә язачак», – диде... Хәзер дә гаҗәпләнәм, нигә шулай дип әйтте икән? Мин бит ул вакытта артист булырга хыялланып, Мәскәүнең Эстрада остаханәсенә белем эстәргә килгән бер авыл баласы гына идем. Әле бер юл язганым да, язарга уйлаганым да юк...

Бу гаиләгә килен булып төшкәнемә инде 49 ел. Быел тормыш иптәшем Илгиз дә, безне калдырып, бакыйлыкка күчте... Әтисенең 100 еллыгын бәйрәм итәргә насыйп булмады аңа... Мостай Кәримнең барлык прозасын рус теленә тәрҗемә иткән югары дәрәҗәдәге профессиональ тәрҗемәче иде Илгиз. Әтисенең әсәрләре буенча берничә пьесага инсценировканы да заманында ул әзерләде. Ләкин язмам бу хакта түгел. Сүз уңаеннан гына искә алуым.

* * *

Хәзер санап утырам, без Илгиз белән өйләнешкәндә әткәйгә бары тик 50 яшь кенә булган икән. Әле «Озын-озак балачак» та язылмаган, «Җәяүле Мәхмүт» тә планда гына, «Прометей» да юк, «Диктаторга ат бирегез!» дигән фарс та дөнья күрмәгән... «Гомер мизгелләре» исә, бәлки, планда да булмагандыр... «Ярлыкау» да... Болар барысы да һәм тагын бик күп әсәрләре мин инде бу гаиләгә килеп кушылгач, минем күз алдында иҗат ителде. Без Илгиз белән 1970 елда өйләнешкән идек. Әткәй 2005 елда гүр иясе булды. Төп-төгәл 35 ел без Мостай Кәрим белән бер гаилә әгъзалары булдык. Шуңа күрә аның турындагы җылы хатирәләрем белән бүлешергә хакым бардыр дип уйлыйм... Күңелләр бер дулкында иде безнең.

* * *

Җитмешенче, сиксәненче еллар – Мостай Кәрим иҗатында иң югары күтәрелеш чоры дип әйтергә нигез бар. СССРның барлык театрларында диярлек аның әсәрләре куела, сайланма әсәрләре басыла, яңа китаплары дөнья күрә... Язганнары русчага, башка чит телләргә тәрҗемә ителә. Ул әле РСФСР Язучылар берлеге секретаре дә, 20 ел дәвамында депутат та булып торган кеше. Шуңа күрә ул Мәскәүдә бик еш була торган иде. Бәлки, Уфага караганда Мәскәүдә күбрәк яшәгән вакытлары да булгандыр әле... Ул кунакханәдә, йә булмаса язучыларның махсус йортында туктала иде. Вакыты булганда безгә кунакка килә – еш очрашабыз. Кышларын язучыларның иҗат йортында – Малеевкада яки Переделкинода эшли. Аның әле генә язылган әсәрләрен, шигырьләрен иң беренче булып тыңлау бәхете безгә тия иде. Яңа шигырьләрен тыңлаганнан соң нинди фикерләр әйткән булганмындыр, берсен дә хәтерләмим. Фикерләрем булгандыр инде, булмаган түгелдер. Ә бәлки: «Әткәй, чәйне яңартыйммы?» – дип кенә сорый алганмындыр... Ничек кенә булмасын, ул безгә бик якын кеше иде. Аның: «Нәзифә безнең гаиләгә генә кермәде, күңел түрләребезгә дә кереп утырды», – дигән сүзләрен ишеткәч, үземне килен итеп кенә түгел, тулы хокуклы гаилә әгъзасы итеп тоя идем.

* * *

Илгиз белән Уфага кайткан чагыбыз иде. Әткәй безгә: «Ничек дип атарга да белмим, яңа гына язылып беткән бу әсәремә исем табышыгыз әле!» – диде. «Озын-озак балачак» дип исемләнәчәк әсәренә исем эзләргә тотындык... Һәркем үз фикерен әйтә, ләкин ул барысын да кире кага тора. Күп эзли торгач, әсәргә исемне барыбер әткәй үзе бирде дияргә була, ләкин анда Илгизнең дә өлеше бар. Башта әткәй: «Күпер» дип атасак ничек булыр, балачактан олы чакка күпер, минемчә, эчтәлеккә туры килә кебек», – диде. Ләкин әнкәйгә ул исем ошамады. Тагын эзләргә тотындык... Күптөрле атамаларны кире какканнан соң, әткәй: «Әгәр дә «Озын балачак» дисәк ничек булыр?» – дип сорады. Шул чакта Илгиз: «Әгәр дә «Озын-озак балачак» дип атасак, яхшырак булыр сыман», – дигәч, барысы да аның белән килеште. Әткәйгә дә бу исем ошады. Рус теленә дә бу әсәрне минем ирем Илгиз тәрҗемә итте.

Фотолар гаилә архивыннан алынды

Әткәй җөмләдәге һәрбер сүзгә сак, аның һәрберсенә кадерләп карый иде. Артык та булмасын, ким дә булмасын.



Гаилә белән җыелган чакларның берсе. Фотода: мин ирем Илгиз һәм кайнатам Мостай Кәрим белән.

* * *

Тәрҗемә әзер булганнан соң, әткәй белән Илгиз һәр җөмләне кабат тикшереп чыгалар иде. Җөмләнең язылышы гына түгел, яңгырашы да кызыксындыра иде аларны. Бер сүз өчен дә озаклап бәхәсләшәләр...

Бервакыт шулай икәүләп эшләп утыралар. Мин төшке аш әзерлим. Без икенче катта тора идек. Чүп түгәргә дип кенә чыктым да, артымнан ишегем шап итеп ябылды. Үзем белән ачкычны исә алмаган идем. Ишектә кыңгырауны шалтыратам, шакыйм, аптырагач, тибә башладым. Ишетмиләр! Башка бернәрсәдә гамьнәре юк – бәхәсләшәләр, тәрҗемә тикшерәләр бит! Ишеккә типкән тавышны ишеткәч, әткәй: «Нәзифә ит тапый, бифштекс кыздырырга ниятли, ахры», – дип әйтә икән... Урамга чыгып, тәрәзә астына басып, тәрәз пыяласына нәрсәдер атканнан соң гына тегеләрнең игътибарын җәлеп итә алдым. Ниһаять, миңа ишекне ачтылар. Аннан соң бик озак көлештек, әлбәттә! Бигрәк тә бифштекстан! Котлет пешерә идем ул көнне. Аш-суымны яратып ашый иде әткәй. «Кеше хатыннары колбаса кискәнче, Нәзифәнең пилмәне пешеп чыга!» – ди торган иде.

* * *

Үземнең кыска гына бу истәлегемдә бер автограф турында тулырак язасым килә. Кайнатай минем үземә генә атап, автограф белән әллә ни күп китап бүләк итмәде. Казанда татарча басылган бер шигырьләр китабына шундый матур сүзләр язып биргән иде дә, ләкин бер танышым ул китапны «тотып карыйм гына» дип алды да, кире кайтармады. Ә менә кечкенә китаплар сериясендә чыккан «Россиян мин» дигән китапны миңа бүләк иткәндә ул болай дип язган иде: «Татар россиянкасына, минем киленемә». 1997 елда иҗат ителгән бер шигырен, кулдан язып, түбәндәге сүзләр белән бүләк итте: «Нәзифә өчен үзем күчердем. Әткәң Кәрим. 7.02.1997 ел». «Әткәң Кәрим» дигән сүзләре Мостай Кәрим дип языла торган кул тамгасы рәвешендә куелган иде.

Әтәч тавышлары тынды –
Сәгать ничәдә икән?
Без эчәчәк шәрабларны
Кемнәр эчәләр икән?

Җирдә давыл күтәрелде –
Сәгать ничәләр икән?
Без кичәчәк дәрьяларны
Кемнәр кичәләр икән?

Күктә йолдызлар болара –
Сәгать ничәләр икән?
Бу дөньядан икенчегә
Нигә күчәләр икән?

Бу шигырьне укыганнан соң нигәдер минем аңа җавап язасым килде. Юл саен сорау билгесе куелган шигырь, әлбәттә, җавап көтә сыман тоелды.

(Әткәй шигыренә җавап)

Сәгать нәрсә, таң аткандыр –
Әтәчләр тынды инде.
Таң аттырып шәраб эчкән
Кичәләр калды инде.

Дәрьялар күптән кичелгән,
Давыллар тынганы юк.
Безнең өлеш – безгә төште,
Сәгатен белгәнем юк.

Бу дөньядан икенчегә
Күчәләр бүген, элек –
Анда сәгать сорамыйлар
Вакыт анда – мәңгелек.

Ләкин мин үзем язган бу шигырьне әткәйгә ул чакта күрсәтергә оялдым. Хәзер инде әлеге вакыйгаларга 22 ел вакыт узган. Алар истәлек булып калган. Әткәй үзе кул куйган кәгазь битен һаман да кадерләп саклыйм. Бераз саргайган, буяулары уңган булса да, укып була.

Вак мәшәкать, ыгы-зыгы тәмам,
Бар эшемнең чыктым очына.
Шуңа күрә бүген таңнан алып,
Күкрәгемнән кошлар очырам.

Әткәйнең бу шигырен дә, бүтәннәрен дә башка күзлектән карап укыган чак бүген...

Без аның белән һәрвакытта да татарча сөйләштек. Гаиләдә дә татар телендә аралаша идек. «Мостай Кәрим татармы, әллә башкортмы?» – дигән еш бирелә торган сорауга ул: «Минем ана телем – татар теле, рухи телем – башкорт теле. Шуңа күрәдер минем өчен бу ике телнең икесе дә кадерле!» – ди торган иде.



Фәйрүзә МӨСЛИМОВА

Әби белән үсү бәхете насыйп булмады... Ул мәңгелек йортына күчкән чакта миңа 5 яшь кенә тулып киткән иде. Карлы буранлы көндә җеназа артыннан елый-елый зиратка кадәр барганым, әбиең белән бергә салабыз, дигәч, кайтып киткәнем хәтердә.

ЯЛЫНДЫРАМ, ЯНӘСЕ...

Безнең Иске Балтач авылына указлы мулла булып Әҗәкүлдән күчеп килгән Агумов Шаһиарслан бабайның күп балалы гаиләсендә үсә минем Әминә әбекәем. Вакыты җиткәч, күрше Иске Кормаш авылына Акмалетдин исемле егеткә кияүгә бирәләр үзен. Беренче баласы – әнием буласы Фәридәсе тугач, ире авырып үлеп китә. Дин буенча ялгызларны тизрәк парлы итү тиеш. Әбекәмне биш баласы белән тол калган авылдашы Фәрухҗан белән никахлаштыралар. Олы кызы әбекәмнән ике генә яшькә кече... Әбекәй үзе тагын бер-бер артлы биш ир бала таба. Эшләп көн күрә гаилә – иген игә, терлек асрый. Әбекәм тегү тегә.

Әбекәй минем әнкәй-әткәй белән яшәде, шулай булгач, башка оныкларына караганда, барыбер янында күбрәк мин булганмындыр әле. Иркәләп-сөеп утырганын белмим, әйткән сүзен тыңларга, кушканын үтәргә кирәк иде. Без, оныклары, үзара нидер булешә алмый бәхәсләшеп китсәк, шундый бер сүзе бар иде: «Йә, булды, җәдәләшмәгез!» Моның «бәхәсләшмәгез» мәгънәсен аңлатканын еллар үткәч, «Коръәндә» «Муҗәдәлә» сүрәсенә ирешкәч кенә аңладым.

Безнең бәрәңге бакчасы артында җәйләрен бик аз сулы, язларын ташый торган Тукмай дигән ерганак бар. Ташу вакыты булса да, көн җылы булган, күрәсең, әбекәй безне – оныкларын – шунда алып төште. Мин таяк белән суны болгатып маташам. «Су анасы тартып алмасын үзеңне!» – ди әбекәй. Тартып алды бит! – актым да киттем. Таллар арасыннан бормаланып чыккангамы, еракка алып китә алмады агым, әбекәй турыдан каршыга чыгып тотып алды. Бер дә әрләмәде, ә Су анасы барлыгына ышандырды.

Көтү каршылаулар, әби-әниләрнең, көянтә-чиләк белән сөт күтәреп, сепаратлы өйгә сөт аертырга барулары шулкадәр күңелле булган. Без дә барабыз әбекәйгә ияреп. Энекәшем Рәшит – әбекәмнең кече баласы Ясүр абзыкайның улы. Миннән ике яшькә бәләкәйрәк. Сепарат ике йорт аша, Галияттәйләрдә.

Бер барганда икенче күршебез Нәкыяттәйнең нефтьче улы Гаяз абыйның кайткан чагы иде. Фотоаппараты да бар. «Әйдәгез, төшерәм барыгызны да», – ди. Мин исә – киребеткән бала – ялындырам, янәсе: «Юк, мин төшмәем», – дигән булам. «Ярар алайса», – диде дә әбекәй, Рәшитне күтәрде дә төште фотога. И аннары шуның өчен үкенүләреем! Шул фото бөтен туганнарыбызда истәлек булып калды. Ә мин анда – юуук.

Үз гомерендә күпне күргән шул әбекәм. Икенче ире – Фәрухҗаны белән дә парлы гомере озакка бармаган, аны ялган әләк белән Минзәлә төрмәсенә утыртканнар, һәм ул шунда вафат булган. Кулак гаиләсе дип, бөтен мөлкәтләрен конфискациялəгәннәр. Кара-каршы ике өйләрен дә бикләгәч, гаилә бөтенләй урамда калган. Бөтен әйберләрен зират буендагы яланда торг ясап сатып бетергәннәр.

– Караңгы төшкәч, кеше-кара күрмәгәндә безгә тау урамнан Гыйльметдин абзый төште. Безнең чуптарлы чаршавыбызны сатып алган булган. «Солдаттан кайткач, мулла абзыйга хәер бирергә кергән идем. Син, үзеңә бирнә әзерләп, бакчагызда шушы чаршауны чуптарлап утыра идең. Ал, Әминә, үз әйберең үзеңә булсын», – диде. Монысы – миңа әнкәем сөйләгәне.

Әбекәй шулай да бер өйләрен кире кайтара алган. Яшереп калдыра алган алтын беләзеген Минзәләгә илтеп сатып, байтак кына тукыма да алып кайткан ул. Малайларга – чалбар, кызларга күлмәкләр тегеп кидергән.

Әбекәмнең башка туганнарының язмышы да шундый ук фаҗигале, катлаулы. Гыйльмегаян энесен, Троцкий (!) белән хат алышуда гаепләп, юкка чыгарганнар, Галимҗан энесе, Берлинга барып җиткәч, сугышта һәлак булган. Яңа Әлем авылы мулласында кияүдә булган Хәмидә сеңлесе, нәкъ апасы язмышын кабатлап, ире үтерелгәннән соң, балалары белән урамда калган, төрле кешеләрдә өйдәш булып яшәгән... Әмма болар инде – башка кыйсса.

...Берчак Актанышка кайткач, Иске Балтачтан Иске Кормашка (авылларыбыз бөтенләй янәшә) барып килдем. Шунда яныма Вәсимә исемле апа килеп, минем әбекәмне искә төшерде: «Без Әминәттәйгә йортында, бакчасында булышырга бара идек. Безгә күлмәкләр генә түгел, сырмаларга, пинжәкләргә кадәр тегә иде», – диде.

Димәк, күпме еллар үтсә дә, әбекәм кешеләр күңелендә матур булып яши икән әле. Миңа бу сүзләрне ишетү бик рәхәт иде...



Сиреньнең шигырьләре бер тынга укыла. Хатын-кыз зирәклеге, җиңелчә юмор, затлылык, авылча матурлык, ихласлык... Бар да сыйган аларга! Сирень – үзенә бертөрле! Беркемгә охшамаган! Балачакта челюскинчылар турында укып – очучы, Суриков иҗатына мөкиббән китеп – рәссам булырга хыялланган, футбол-хоккей белән «җенләнгән», гармун уйнарга яраткан, барлык фән олимпиадаларында беренчелекне алып кайта торган кабатланмас кыз булсын да! Әлмәт районында бөтен тирә-як авылларга «баш авыл» – мишәр авылы Елховойда үссен дә! Әтисе Хөббәт матур җырлый, рәсем ясый, балта остасы була, күңелдәге бизәкләре тәрәзә йөзлекләренә күчә (менә ни өчен кызы кулыннан буяу-пумалалар төшми!); әнисе Минхәят җырлый да, шигырьләр дә чыгара, үзе авылның иң оста тегүчесе (менә ни өчен кызы балачакта аллы-гөлле тукыма кисәкләре белән мәш килә!). Шигырендәгечә «хыялы артыннан йөгереп», башта Әлмәткә китә, аннан – Чаллыга. «Йолдызлы уйлар», «Өстәгеләрдән дә өстә», «Яшәү сере», «Ике гасыр баласы мин», «Кар юлы» кебек шигырь китапларында исә Сиреньнең төсле дөньясы, фәлсәфи уйлары, кешеләрне яратуы, тәвәккәллеге, җор теле чагыла.

Сирень ЯКУПОВА

АЙ ТУЛЫ... КҮҢЕЛ ДӘ...

* * *

Соң булса да танысыннар дисәң,
Ялкыныңнан кабынсыннар дисәң,
Керә белү кирәк
Миләш булып янып күзләргә.
Йә, һичьюгы,
Төрә белү кирәк
Януыңны тәлгәш-сүзләргә.
Тирәк йота-йота үсен кемдер
Иреннәре, юк, күңеле белән!
«Тфү, әче!» дип сүксен дәме кемдер?
Исең киткән,
Балланулар алда – кышка керәм...

* * *

Пәрдәләрен җайлап тартып куйган,
Көн яктысы тансык.
Үз күзеңә үзең ышанмаслык –
Җеп эрләүче карчык!

Биш катлы йорт, ә ул икенчедә...
Абынмадым чүттән.
Әй, әбием, әбекәем, бәгърем...
Кем әбисе икән?!

Яраннары яна... Янәшәдә
Ике тәрәз тагы...
Челтәр, яулык, чүлмәк актан да ак,
Гүя авыл җаны!
Пәрдәләрен, ярый, ачып куйган,
Карап торам туктап.
Кабада – йон... Күкрәгемнән йөрәк
Суырыла сыктап.

Орчыгын да күрәм... Бөтерелә...
(Һай, гомерләр үткән.)
Таш капчыкны тишәр
безләр дисәм...
Кем әбисе икән?!

* * *

Бүген
Минем күңел керпе инде.
«Йомшагым» дип әйтер иде
Тик әнием, исән булса...

Тырпаешкан энәләрдән
Сыйпар иде тыны белән.
Җылы, назлы кулы белән
Балачагым тәме килгән,
Балачагым исе килгән
Алсу алма бирер иде,
Керпе күңел эрер иде,
Их, әнием исән булса...

* * *

Мине кемдер югалткандыр кебек
Һәм эзлидер кебек тилмереп.
«Мин монда-а-а-а-у!» –
дип кычкырасым килә
Җан авазым белән илереп.

Мине кемдер югалткандыр, беләм...
Аһ, ул мизгел, куллар аерылган,
Күңелләрдән күңел суырылган,
Йөрәкләрдән йөрәк каерылган...

Онытсыннар бер-берләрен диеп,
Аһ, ул вакыт, бөтерелеп аккан...
Аһ, ул гомер, тоташ өннән торган:
«Син түгелме мине югалткан?»

Син түгелме мине югалткан?..

* * *

Күкрәү көтә йөрәк,
Яшьнәү көтә күңел
Тик бер тапкыр тагын
Яшьлектәге кебек...

Чыдар микән йөрәк,
Күңел түзәр микән?!

Тик бер тапкыр тагын
Җанда күкрәү кәтәм...

Җан соң түзәр микән?!
Әйтә алмыйм алдан...
Тик
Кабатлансын мизгел,
Кочагыма күкләр,
Дөнья иңрәп ауган!

* * *

«Уян...» –
Серле пышылдаудан
Ачтым күзем.
Нур көлтәсе төшкән тәрәзәдән...
Зәңгәр яктылыкка чумган бүлмә...
Янәшәдә син. Йоклыйсың...
Йомык күзең...
Сак кына торып,
Нурга таба киттем кулым сузып.
Челтәр читеннән
Күк йөзенә бактым –
Ай тулы!
Түм-түгәрәк...
Шундый сөенде мине күргәч,
Чын әгәр.
«Чык әйдә...»
Белсәң,
Курыктым...
Нидән?!
Айга ияреп китүдән...
Кулым сузып,
Күзем йомып,
Бөтенләйгә...
«Җибәрмим...»
Иңнәремдә кулың,
Чәчләремдә тының...
Ай тулы...
Күңел дә...

* * *

Танымаслык булып үзгәрдем күк...
Авылыма кайтсам – таныйлар!
Әниемне әле хәтерләгән
Күрше-күлән, апа-абыйлар
Таныйлар бит, күрче, таныйлар!
Үзгәрәбез әниләргә охшап...
(Ә минем кыз – нәп-нәкъ атасы!)
Аһ!
Үзен үзе танымаса берчак,
Авылы юк аның кайтасы...
Шәһәре бар... туган, бәлки, газиз...
Мин сайлаган инде (ни уйлап?!)
Гомер иткән, ләкин үз итмәгән.
Һәм үкенгән. Хәер, бик соңлап...
Танымаслык булып үзгәрдем күк...
Авылыма кайтсам – таныйлар!

Саламы ул, олы каламы ул,
Туган җирдә икән тамырлар.
Тамыр кайда, шунда таныйлар...

* * *

Төшләремә яланаяк керәм...
Имеш,
Йә мәктәпкә,
йә кибеткә шулай барганмын.
Матур күлмәк өстә,
Ефәк яулык,
Ә чүәкләр кая калгандыр...
Ялантәпи бер мин генә, имеш,
Оят, читен, тагын әллә ничек...
Балачагым төштә үч аламы
Бүгенгемнең ун туфлие өчен.
Затлы күннән, лаклы, лаксызлары,
Төсләре дә, фасоны да төрле...
Яланаяк җиргә баскан да юк
Авылымнан киткән җәйдән бирле.
Яланаяк җиргә, их, баскан юк!
Чыклы үлән назы онытылган.
Шырпы кадалмый ла табаннарга,
Йөз чытам йөрәк авыртудан.
Төшләремә яланаяк керәм,
Үткәнемне күрәм, киләчәкне –
Ак дөньяга ялантәпи килеп,
Яланаяк кына китәчәкне...

* * *

И шәһәрнең
Уйдык-уйдык кыргый
гөлле ишегалды,
Син бар ярый!
Шул уйдыктан
Һәр иртәне мөлдерәпләр күзләремә
Авыл карый.
Тукранбашлар, зәңгәр чәчәк,
Ак чәчәге...
Бәллүрләнеп җемелдәшә
Чык-яшьләре...
Гөлләр елый, мин чак түзәм –
Ирексездән
Иеләм дә эрем өзәм,
Телгә салам – баллы, чындыр.
Мин чак түзәм, йөрәк түзми,
Әрнеп-әрнеп
Әчеттерә күкрәгемне –
Җирсү шулдыр...
И шәһәрнең
Уйдык-уйдык
үлән-гөлле ишегалды,
Син бар ярый.
Һәр иртәне
Таш сукмаклар арасыннан
Мин – адашкан баласына
Авыл карый...

* * *

Бураннарда адашасы иде (?!)
Кыр-урманда түгел, урамнарда...
Исән-имин табыласы иде
Барлыгыңны барлап торганнарга.

Югаласы иде... вакытлыча,
Уйларыннан түгел, күз уңыннан.
Бәхет булып табыласы иде,
Югалмаган килеш... иң соңыннан...
Мең-мең тапкыр кичерәсе иде
Югалулар, табылулар хисен.
Рәхмәт әйтеп өлгерәсе иде
Аңа... аңа... эзләгәне өчен...

* * *

Мин өзмәдем, җилләр өзгән сезне,
Саргайтмадым –
күзләр саргайткан...
Аһ, ничекләр аңлыйм үпкәгезне,
Аһ, ничекләр сезне яратам!

Җыям-җыям, җыеп туя алмыйм,
Туя алмыйм чөеп һавага.
Яфракларым, алтын яфракларым,
Сез очарга тиеш! Яварга!

Сез кочарга тиеш иңнәремнән,
Чәчләремә сарылырга тиеш!
Яфрак яңгырлары ләйсән түгел...
Имеш...

* * *

Миләш тәлгәшләре ымсындыра,
Өзеп кабар идем, шикләнәм.
Авыр металл тузаннары белән
Ымсынулар безнең чикләнгән.

Урман түгел, шәһәр урамы шул...
Башка бераз акыл өстәлгән.
Яшьлектәге «Әй лә!» артта калган,
Картлыктагы «Әй лә...» җитмәгән.

Ымсындыра миләш тәлгәшләре,
Тик сокланып кына үт икән.
Өзеп кабар, чәчкә кадар түгел,
Җанга кабар гына ут икән...





Асия ЮНЫСОВА

КАЛАЙЧЫ КӘЛҮК

(Хикәя)

Буйлы күлмәк өстеннән арка җылыткыч сырма кигән, башына кара бәрхет түбәтәй элдергән Кәлимулла бабай болдыр ташына чыгып басты. Күтәрелеп килүче кояшка балкып елмайды:

– Әх, көне дә көне! Әх, дөньясы да дөньясы! Яшисе дә яшисе генә бит...

Җиңел сөякле бабай, аягына эрҗинкә галушларын киеп алды да болдыр баскычыннан җәһәт кенә ишегалды чирәменә төште. Тагын бер кинәнеп арлы-бирле йөренгәләде. Алгысый иде аның күңеле, очына иде. Менә нидер эшлисе генә килеп тора бит. Ниндидер бер гайре табигый эш. Әмма дә ләкин файдалы эш булсын иде ул. Хәкимәсе: «Вәт маладис, картым! Вәт булдыргансың, атасы!» – дип әйтерлек булсын. Мактаганны ярата ул.

Карчыгы мичкә ягып җибәргән икән. Ишегалдына җиңелчә төтен исе тарала башлады. Коймак пешерә торгандыр инде. Әллә балалар кайтышка ипи салмакчы микән? Мөгаен, ипидер. Мич башында томаланып утырган күәс чиләге күзенә чалынган иде шул. Ипидер. Ипи ярый ул. Ипи пешкән ис туклык, муллык, иминлек исе бит ул. Бер Ходаем ипидән аерма-сын. Ярабби. Кәлимулла догалы учы белән үзе дә абайламастан битен сыпырып куйды. Каерылып күккә карап алды. Шунда аның күзе морҗа торбасы төбеннән савылып кына сыек төтен саркып торуын абайлады.

Вәт мәсхәрә! Калайчы дигән исем күтәреп йөр тагын. Үз өенең морҗа төбе төтен тотмый башлаган – калай ялгаган урын аерылып киткәнө шиксез инде анда. Юк, тәгаенен белергә кирәк.

Кәлимулла, авылдашлар өчен Калайчы Кәлүк, төз лапаска сөяп куйган баскычны сөйрәп алып килде дә җилтерәп кенә югарыга менеп китмәкче булды. Тик менә протез кигән аягы гына аның каударлыгын кабул итми. Арата саен: «Туктап тор әле, Кәлимулла. Ашыкма әле. Ипләбрәк кылан әле. Мәтәләбез бит», – дигәндәй, шыгыр-шыгыр килә. «Ярар сана, синеңчә булсын. Башта исән аягымны бастырып куярмын, аннан сине тартып алырмын. Шулай итә-итә менәремне беләсең бит инде. Беренче генә түбәгә менүебез түгел. Әбиеңнең көлчәләре пешеп

чыгуга төшеп тә җитәрбез. Мичкә яккач, иң әүвәле ипи камырыннан көлчә пешереп ала ул. Без төшүгә какраз гына булыр. Майлап та куяр, Чатан Кәлүген кайнар көлчә белән сыйлар. Чатан дип сиңа гына зарланам, агач аяккаем, син аны үзең дә беләсең. Рәхмәт авылдашларга, Чатан димиләр, Калайчы диләр».

Кәлүк, өстендәге сырмасын түбә кыегына салып – калай артны кисмәсен тагын – җайлап кына утырды. Аннан түбәнгә карап алды. Өй түбәсе биеклеге генә булса да, барыбер биеклек инде – әллә кай тарафлар уч төбендәге кебек күренә. Әнә, аның Мәрфугасы инеш буеннан кайтып килә. Кулына чыбык тоткан – казларын су буена төшергән инде бу. Ак күлмәк кияргә яратты. Әле дә аклыдан киенгән. Яулыгын әбиләрчә таратып бәйләүләре үк килешле. Матур кыз иде аның Мәрфугасы, инде матур әби булган. «Аның Мәрфугасы», имеш... Кәлүк кеткелдәп көлеп куйды. Мәрфуга Хәмдинеке булып картаеп бетте инде, синеке анда сиңа көлчә пешереп ята. Дөньялары тыныч торган булса, Кәлүк хатыны Мәрфуга булып картаясы иде дә бит ул, бәгырь. Болай инде аңа үпкә юк. Сугышка чыгып киткәндә үзе әйтте: «Йә кайтырбыз, йә юк. Сугыш бит ул. Ялгыз кала күрмә! Малай туса, Бакый кушарсың. Гомерле булсын дип!»

Кәлимулла Яруллин исән кайтты сугыштан. Сугыш бетеп, өч ай үткәченнән. Өчәү кайттылар. Партизан отрядында кавышкан Марфасы, кызы Машасы белән бергә. Мәрфугалар да аны өчәү каршылады. Бакые, Хәмдие белән бергә. Авылга ничекләр кайтып керербез? Мәрфуга белән икенче хатынын ничекләр килештерермен дип бик хәсрәтләнгән иде партизан Кәлимулла. Үзе дә сугыштан ярты кеше булып кайткан Хәмдүш дусты белән тиз аңлаштылар. «Синең улыңны ятим итмәс өчен өйләндем Мәрфугага, – дигәненә ышанды ул Хәмдүшнең, – инде үсеп беткән бу малай икебезнеке дә булыр. Син дә олау төяп кайткансың икән. Без дә монда үрчергә торабыз. Әйдә, кордаш, фашистларга үч итеп, үрчетик татар каумен шулай тату гына. Әллә минем хатын булып, ул тол калса, син аны сыендырмас идеңме? Юк бит, юк!» Әйе, Кәлүк үзе дә, мөгаен, шулай эшләгән булыр – дустының толын алган булыр иде. Язмышларны чуеп, бишташлы уйнаган фашист дошманнар сөенми торсыннар. Тату яшәр алар.

Марфа татар авылына һич тә ияләшә алмады. Суга барса, коянтә иңен басты аның, кер чайкарга төшсә, инешнең суы бик салкын булды. Үзләрендәге чучка итеннән пешкән ризыкларны, гөмбә ашларын юксынды. Белорус урманнарын, кардәш-ыруын сагынды. Ә менә Коленькасын бик ярата иде. «Калашник мой», дип кенә йөрде ул аны. Кәлимулланың улы Бакыйны да, хәтта аның әнисе Мәрфуганы – «тезкасын» да якын итте. Христиан бәйрәмнәре җиткәндә тәмам иләсләнә торган иде: «Калашник мой, поедем ко мне домой», – дип өзгәләнә торган иде. «Доню моя, авылың да юк бит инде синең анда. Авылдашларың белән бергә яндырдылар, көл иттеләр бит инде Ходынкины», – дип, Марфаны иленә кайту ниятеннән күпме генә айнытырга омтылмасын, Марфа белән нәни кызы Машаны поездга утыртып озатмый булдыра алмады Кәлимулла. Киттеләр дә югалдылар. Хатлары да, хәбәрләре дә килмәде. Бәлки, шулай дөрес тә булыр дип, үзе дә сугыш юллары кавыштырган ярын эзләтмәде.

Мәрфуганың сеңлесе Хәкимәгә – балдызына өйләнде ул. Шулай итеп, беренче хатыны белән кодакодача булдылар да куйдылар. Ә менә Бакый ике этиле булып, кинәнеп үсте. Мәрфуга белән Хәмдинең җиде кызлары туды әле тагын. Монысы да Бакыйга файдага гына булды – бердәнбер алтын багана ич ул. Ике йортка берәү, чөнки Кәлүк белән Хәкимә дә өч кыз үстерделәр. Хәзер инде ике капкага кайта торган оныкларның санына чыкмалы түгел. Менә шулай ишәйде татар кавеме Ташлы авылында.

Һау-һау-һау!

Кинәт абалап өргән эт тавышыннан түбә кыегында сакланып кына утырган Кәлүк мәтәлеп китә язды. Хәерсез алабай! Тамагыңа пычак кергере! Кереп ят ояңа! Йодрык чаклы песи баласына шулай кыланып өрмәсәң!

Яратмый иде Кәлүк этләрне. Үзләрен түгел, өрүләрен. Күршеләрнең олы башлы алабае бигрәкләр дә немецчәләтеп өрә. Теге чакта, әсирлек камалышыннан чак ычкынып, салам эскерте эчендә качып ятканда котны алганнары онытылмый. Шул чактагы курку буыннарга юшкын булып утырып калган. Кайсыбер төннәрдә әле һаман этләр эзенә төшә дигәндә генә шабыр тиргә батып уянып китә.

Эскерт эчендә алар икәү булып чыктылар. Семен да алар полкыннан икән. Сугышны чик буенда каршылаган армиянең тар-мар килеп таралып, вак-вак төркемнәр белән чолганыштан чыгарга азапланган көннәре иде бу. Икәү булганнарына Кәлимулла сержант сөенергә дә өлгермәде, старшина: «Ходынкидан мин. Әнә генә безнең авыл. Күренеп тора. Миңа Семен диярсең. Ночью полями к своим проползу. Хочешь, со мной пойдем. Немцы пока, говорят, местных не отлавливают. Будешь белорусом. Ты ведь тоже, как я, белобрысый. Если хочешь, конечно. А так нам хана. Немцы красноармейцев не пощадят! У тебя хоть какая еда есть? А то я уже вторые сутки тут голодный лежу».

Концлагерьда – чәнечкеле чыбык эчендә булып өлгерде инде Кәлүк. Семен да булган икән. Җирле кешеләрне тоткарламауларын шунда белеп алган. Аңа җайлы. Ул үз туган телендә сөйләшеп, полицайларны ышандыра да алыр. Ә менә татар малае Кәлүкнең белорусчасы түгел, урысчасы да чамалы. «Ул ягы әйбәт тә әле аның. Чиста итеп русча сукалый башласаң, тиз төшенеп алырлар иде», – ди Семен. Туп тавышларының көнчыгыш тарафка таба китеп ераклаша баруын көтеп ятканда Семен михнәттәшенә үз телен аз-маз өйрәтергә тырышты. Бу көннәрдә алар, тычканнар кебек, эскерт эченнән тук башаклар эзләп, ярма уып тукландылар. Салам чәйнәделәр. «Хорошо, что жито есть!» – дип күңелне күтәреп торды Семен. Әйбәт кеше иде бугай ул арыш саламы кебек чәчле белорус егете. Ходынкига



мин сине сеңлем Марфаның кияве дип алып кайтырмын. Сеңлем сугыш алдыннан Гроднода укыган иде. Кем дә белми аның кияве барын-югын.

Инде сугыш янгыны түргәрәк – көнчыгышкарак китеп, туплар гөрселдәве тына төшкәч, тәвәккәлләделәр. Семен бер төнне качып кына Ходынкига китте. Ул аннан гап-гади бер авыл егете кыяфәтендә урап килде. Кәлимуллага да киемнәр алып килгән. Гимнастеркаларын, погоннарын җиргә күмделәр. Солдат кенәгәләрен якындагы урман авызындагы имән куышына яшерделәр. Аннары, аркаларына салам төяп, авыл ягына киттеләр.

Семен сеңлесе белән сөйләшеп куйган булып чыкты. Марфа «киявен» кочаклап алды. Хәтта елап та маташты. Әллә чыннан да сугыш эченә китеп югалган кияве булган инде? Күрше-тирә генә түгел, Марфаның әнисе дә кызының «кияве» табылганга куанып йөрде. Шулай гаиләле булып яшәп киттеләр. Марфаның исеме Мәрфуганыкына охшаган булуы да күңеленә хуш килде, ахрысы, Кәлүкнең.

Урман ышыгындагы бу авылда баштарак немецлар сирәк күренде. Тәртип саклауны тулысынча полицайларга тапшырганнар бугай. Кияү кеше, артык кашык булмас өчен, Марфаның әнисенә өй тирәсендә булышып йөрде: утын ярды, кар көрәде, мал карашты, хәтта зур күәс чиләгендә камыр басышты. Ә аңа ярдәмче бик кирәк. Галина Ивановнага якындагы урманнарны күзәтеп тору өчен калдырылган җәза ротасына ипи пешереп тору вазыйфасы йөкләнгән иде. Түтәй көн дә мич тутырып ипи сала. Мич түрендә посып калган шишара үз тамакларын ач итмәс өчен бик тә ярап куя. Галина Ивановна камыр басып, әнәләп куйган ипиләрен агач көрәккә кунаклата да җәйлы гына итеп кайнар мич төбенә төшереп куя. Берәр сәгать, сәгать ярым үтүгә төбенә көл-күмер ябышкан икмәкләр пешеп тә чыга. Ипи исе кайда да бер инде ул – авыл өстенә кетердәп пешкән ипинең баш әйләндергеч хуш исе тарала. Әй шул чакларда Кәлүкнең өен, әнисен сагынудан үзәкләре өзелердәй була. Йөгереп кенә, йә кош канатында гына очып кайтып, әнисе пешергән калачның кибән башын сындырып алып, шуны салкын сөт белән ашап җибәрсәң иде ул! Кәлүкнең әнисе ипине көлдә аунатмый: калайда күпертеп, калач итеп пешерә. Хикмәтле ул калачлар. Учка сыеп бетәрлек итеп кысып бетерәсең аны, ә ул «иреккә чыгуга» янәдән тәгәрмәч кадәр күпереп китә. Калачның һәр күзәнәге бал белән тулган кәрәз рәвешен ала. Өрдереп тарткан бодайдан пешерелгән ул ипи тәгәрмәчләрен калач дип әйтү генә дөрестер дә. Нигә калач диләр икән ул? Калай савытта пешерелгәнгә күрә микән әллә? Күпереп пешүе дә шуннан – калай савыттан түгел микән әле. Ипи калайларын менә дигән итеп ясый инде Кәлүк. Хәзер дә яртылар… юк, бөтен авыл ипие Кәлүк ясаган калайларда күпереп пешә.

Тик менә соңгы елларда ялкауланды киленнәр. Ипине кибетнекен, дөресрәге, Сәйдүкләр пешергәнен ашый башладылар. Шакир малае Сәйдүк каяндыр, ниткәндер мичләр алып кайтып, ипи пешерә башлады. Ягъни мәсәлән, пекарня корып җибәрде. Рәхәтләнде ялкау бичәләр. Хәзер инде кем ипие уңа, кем ипие ләчтә пешә дип итәк астыннан сүз йөртүләр юк. Сәйдүкләрнең ипие һаман саен уңып пешә. Ә менә Кәлүкнең Хәкимәсе үзе сала ипине! Ипи пешерү серен дә бөтен кешегә әйтеп бетерми. Кәлүк кенә белә. Ипи – аларның уртак сере, гаилә бәхетенең тоткасы кебек. Ипи тәмле булсын өчен Кәлүк белән Хәкимә әрәмәгә бөрлегәнгә барган җирдән күп итеп колмак җыеп кайталар. Ел буена җитәрлек итеп. Әзер чүпрә шакмаклары тулып ята хәзер. Тик үзең өйдә ясаган чүпрәгә җитәме соң?


Аның Хәкимәсе бер стакан коры колмакны бер литр суда ун минут кайнатып алып, зур тишекле иләк аша сөзә. Аннан суыта. Бармак пешмәслек булганчырак инде. Шуны арыш оны белән туглап куя да тәүлек буе ачыта. Икенче көнне әзер чүпрәдән ипигә баш куя. Тагын әллә ниләр эшләтә бугай инде ул ипи камырын. Ипи табынга килгәнче аны бик күп хасиятләргә кирәк шул. Ипи үзен назлаганны, көйләгәнне ярата. Ипи бит ул, ипи! Икмәк тотып ант итәләр. Ипи белән кунак каршылыйлар, туйга баралар!

Кәлүкнең борын канатлары әчкелтем арыш ипие исен сизгәндәгедәй киңәеп китте. Бабайга гайрәтле бер рәвеш керде. Бу гайрәт аның авыл капкасы янына башланып, ерак офыкка кадәр җәйрәп яткан иген басуларын хуҗаларча бер кинәнү белән күздән кичергәндә ниндидер матди рәвеш алган кебек булды. Бу бит аның иген басулары! Ул басуларга аның маңгай тире байтак тамды. Кәлүк бу җиргә сугышу өчен түгел, иген үстерү өчен килгән авыл баласы иде…

Сугыш игенчедән солдат ясады. Менә шул каһәрле елларда ипигә хыянәт итәргә туры килде дә инде аңа.

Семен белән Ходынкида, яшеренеп-посып дигәндәй, яшәп ята болар. Кәлүк – атлы эштә: Галина түтәй пешергән ипиләрне немецларга илтеп кайту аның өстендә. Әллә ни хәтәрлек юк та кебек. Тик иртәгәсен ни көткәнен кем белә? Немецларның холкы фронттагы хәлләргә генә түгел, бәлки партизаннарның аларны тынгысызлап торуына да бик бәйле. Вакытлыча иминлек давыл алды тынлыгына охшаган. Шул партизаннар ягына элдерергә кирәк кичәге кызылармеецларга. Моны Семен да, Марфа да аңлый. Тик партизаннар янына буш кул белән генә качасы килми бит әле совет солдатының.

Немецлар белән көн аралаш күрешеп торган Кәлүк алар арасында ниндидер киеренкелек барлыгын сизеп алды. Гадәттә ипле генә сөйләшә торган фельдфебель бу юлы ничектер сынап карады. Китеп барганда да сизде ул аның усалланган карашын. Партизаннар белән бәйләнеше булу ихтимал кешеләрне җыя башлаганнар иде инде. Димәк, аннан да шикләнәләр. Кәлүк Галина түтәйнең ипине көн аралаш кына түгел, бәлки көн саен пешергәнен, Семенның шул ипи белән урманга утынга барып йөргәнен дә белә. Бер өй эчендә сер була алмый бит инде.



Рәсем: Наталья Васильева

Тәвәккәлләргә кирәк. Баш исән чакта. Дәррәү кузгалырга. Авылда берәү дә калмасын. Калганнарга аяу юк. Шулай итәргә булдылар. Иртәгә Коленька ипи илтә барганда калганнар урман авызына кадәр аңа утырып бара да ешкынлыкка кереп чума. Коленькага йөк белән кайтасы. Аңа бу юлы ипи пешерү өчен он салып җибәрергә тиешләр. Партизаннардан артмас. Тик бу күчтәнәч кенә аз булыр бит. Кәлүкнең үз планы өлгереп килә. Семеннарның утын сараен җыештырганда күзе бүрәнә ярыгына кыстырылган күсе агуына төшкән иде. Шул минутта башында хәтәр ният борын төртте.
Зур кисмәктә ипи басу кебек авыр эшне бүген үзе башкарырга булды. Көн дә, көн дә ипи басудан йончыган түтәй бик теләп риза булды: «Ладненько, чудненько, зятек мой. Какой ты понятливый. Хорошая мать тебя воспитала! Бог даст, когда-нибудь и с ними увидимся...»

Тәвәккәлләде Кәлимулла... Күсе агуы чупырдап әчеп утырган ипи камырына чумды. Өйдәгеләрне араларга кирәк бит инде хәзер күсе агуыннан. Серне дә ашыгып чишмәү мәслихәт. Ипидән алдарак пешеп чыккан кайнар шешараны сындырып кабу гадәте һәр халыкта да бар. Кәлүк хәйләсенә кереште. Өйдәгеләрне урманга төн карасында ук кереп югалырга күндерә алды. Ипине үзе пешереп бетерә ала ич ул. Көн дә күреп торган, берничә мәртәбә башкарып та караган эшнең аңа бер кыенлыгы да юк янәсе.

Ышандыра алды. Иртәгәсен кызарып пешкән күмәчләрне немец солдатларына илткәндә ул каршылыклы хисләр кичерде. Күсе агуы көчен югалтмаган гына булса ярар иде... Бернинди шик уятмыйча гына ипиләрен бушатып, кире борылып китә алса ярар иде... Партизаннарны адашмыйча гына барып таба алса ярар иде... Шушы ымсындыргыч, әмма агулы ипекәйләр бер рота немец солдатының башына җитсә генә ярар иде!

Бөтенесе дә алдан ниятләгәнчә барып чыкты. Немецлар өсләренә төшкән мурның сәбәбенә тиз төшенделәр. Кем эше икәнен дә тиз белделәр.

Тик урман куе иде.

Ходынки авылы гына көл булды. Бу кадәресе өчен аны Галина түтәй гомер буе каһәрләде микән? Ә Кәлүк гомер буе үзен табынга бәхет, туклык, иминлек билгесе булып кына килә торган Ипекәй алдында гөнаһлы, гаепле сизеп яшәде. Ул бит туендыручы, яшәтүче икмәкне үтерү коралы итте!

Партизаннар отрядына килешли яшереп калдырылган он капчыкларын эзләп йөргәндә капкынга юлыгып яралануын Кәлимулла ипи рәнҗеше – лаеклы каза кебек кабул итте. Тик ул «каза» азып китеп, партизаннар лагере шартларында үзен спирт белән генә исертеп, кул пычкысы белән аягын кисканнән соң ипи рәнҗеше бәхилләтелде дип санаган иде инде. Бу тәвәккәл адымы әнә шулай авыл өстенә тәмле ипи исе таралганда йөрәкне өздереп исенә төшә торган булып калды.

Сугыштан кайткан җәйдә үк аны лобогрейкага утырттылар. Комбайннар кайта башлагач, комбайнга инде. Тыныч тормыштагы гомере уңыш өчен, мул итеп икмәк үстерү өчен көрәшеп узды. Игеннәр җыелып, амбарларга салынып беткәч уза торган «Уңыш бәйрәме»ннән иңенә «Кыр батыры» дип язылган кызыл тасма киеп кайтулары рәхәт тә була торган иде. Шуннан ары бернинди дан-шөһрәт кирәкми аңа. Кәлимулла Ярул-



линны икмәк өчен шулай зурлыйлар икән, димәк, теге агулы ипекәйләр дә аңа бүтән рәнҗеми. Ә нигә рәнҗергә тиеш ди әле? Ул каравайлар да Җиңү көнен якынайтышты лабаса!

– Әй, Кәлүк, дим, Кәлүк! – Җилкапкадан сөрән сала-сала Мәрфугасы кереп килә икән. Кай арада судан кайткан да, кай арада алар капкасына килеп җиткән диген? – Баядан бирле нишләп утырасың син түбә кыегында? Төшә алмыйча тилмереп утыруың түгелдер бит? Әйдә, төш. Баскычыңны үзем тотып торам. Сеңлем ипи салып мәшәкатьләнә, ахрысы. Бөтен урамны ипи исе алган. Йә, төшәсеңме? Аякларыңны араталарга ипләп кенә куй. Егылып китә күрмә тагын...

– Куй әле, Мәрфуга. Төшәсе булсам, сикерәм дә төшәм мин. Күршеләрнең алмалары өлгергәнне көтеп утырам. Бик җитез булсаң, анау измә тутырып куелган бәләкәй бидрәне суз әле миңа. Мин моннан иелеп алырмын. Морҗа төбеннән төтен саркый. Шуны сылап төшәрмен дигән идем дә бит. Бидрәм, әнә, сине көтеп, җирдә калган.

Кызыл балчыклы измә белән морҗа төбен һәйбәтләп сылап куйгач та әле Калайчы Кәлүк тиз генә түбәдән төшеп китәргә ашыкмады. Алмалары кызарып утырган бакчаларга, су буена төшкән сукмакларга, бормаланып аккан Ыгына, яшәрә башлаган уҗым басуларына, ашлыгы җыелып бетә язган иген кырларына карап туя алмый иде ул. Дуамал этне тагын бер котыртып, күршеләрнең өй кыегына җитә язып үскән алмагачыннан яшел антоновка өзеп алды. Алма кимерерлек тешләре бар иде әле аның. Әчкелтем баллы алманы ашый-ашый манзараны күзәтә бирде.

Ашлык өлгереп утырган иген басуларыннан гомер бакый да туймады ул. Елга аръягындагы Язытамак авылында яшәүче кордашы Габделхак та шулайдыр дип белә. Габделхак ипи, ашлык, уңыш дигәндә Яруллинны да уздыра торган иде. Кордашы яңгырлар киткәнче дип, игеннәр кар астына кергәнче дип кырдан кайтып керә белмәве аркасында гына Кәлүк кебек аяксыз калды. Соңгы бункер ашлыгын машинага төяп озаткannan соң гына басу читенә үрмәләп чыгып егылган ул. Айлар буе көнитек эчендә сызлап интектергән аякның үкчәсе итеге-ние белән бергә кубарылып чыккан. Шуннан соң аягын кистеләр дә инде аның. Габделхак исә икенче ел урагына да төште. Тагын «Кыр батыры» тасмасын иңенә салды. Менә шулай зурладылар алар иген бөртеген. Галиҗәнап Икмәкне! Нихәл икән анда Габделхак кордашы? Узган көздә, комиссия килә икән дигәч, урылмаган җир калмады дип күрсәтер өчен иген өстенә төрәнле трактор керткәч, Габделхакка инфаркт булган икән дигәннәр иде. Ничек икән хәле? Барып кайтырга кирәк булыр. Машиналар йөреп тора. Хәл белешми ярамас.

Ярый әле иген өстенә трактор менгәнен Кәлимулла күрмәде. Тракторчысын бәреп үтергән булыр иде. Менә кайда ул ипи рәнҗеше! Җиде кат тиреңне тамызып үстер дә син ул игенне, бер ишарәт белән кара җиргә күмеп куй. Ичмасам, көтү кертсәләр дә ул кадәр әрнешле булмас иде. Хәзергеләр ачлык күрмәгән! Хәзергеләр ипине Сәйдүк кибетендә тулып ята дип белә! Хәзергеләр ак күмәчне малга ашата. Их!

Өй ишеге ачылып китеп, аннан бу юлы апалы-сеңелле икәүләп килеп чыктылар: «Картым, дим! Кәлүк, дим! Төш әле, дим. Кызык хәбәр бар. Безнең теге Марфаның кызы Машадан хат килгән. Картечкә дә җибәргән. Исәннәр икән бит!»

Бу хәбәр чыннан да ашыктыра торган хәбәр иде. Ике әби ике яктан баскычка килеп тотындылар. Кәлүк исән аягы белән чатан аягын буталдыра-буталдыра, аратаның кайсына баса, кайсыларын үткәрә биреп, апалы-сеңелле әбиләр кочагына дөмбердәп килеп төште:

– Кем исән дисең? Кайта дисеңме?

– Кайта, димим. Хат бар, дим. Бая пушталиун Хәдичә тәрәзәдән генә биреп үтте. Син күккә карап утырып күрми дә калгансыңдыр аны... Әйдә, түтки дә монда чагында кайнар көлчә белән чәй эчеп алыйк. Хатны да шунда бергәләп укырбыз. Мәрфуга түтки, кулларын юдыр Кәлүгеңнең...

Китеп югалганнан соң бер хәбәре булмаган хатынның кызы, адресны онытмаганмы, соңыннан юллап тапканмы, чыннан да, русчалатып хат язган. «Папа, я тебя не забыла, – дигән. – Мама в прошлом году нас покинула. Она тоже тебя не забывала», – дигән. Хәбәрнең иң зурысы ахырдан әйтелгән икән. «Папа, я ведь теперь живу в Германии. Твоя внучка Марина замуж вышла за немца. Вот посылаю тебе фото. Она там со своим Куртом. Если можешь, ответь. Все-таки у меня в вашем селе живут сестры и брат. Может быть, сумеем восстановить родственные отношения...» Адресы бик төгәл итеп немец хәрефләре белән дә язылган икән.

Алай. Партизан кызым исән икән. Марфа вафат икән. Йәгез, аның рухына дога кылыйк.

Кәртечкәдәге оныгының йөзе ят иде, ә менә кияүнеке Кәлүккә бик таныш кебек тоелды. Бу немец егете белән очраша алмый иде бит инде ул? Кемгә ошата соң ул аны? Төсле фотодан зәп-зәңгәр күзләр карап тора. Сынап карый торган күзләр. Немец кияү Кәлүкнең оныгын бик сак кына кочып алган. Елмая да икән әле үзе.

Фельдфебель! Кәлүкне сынаулы караш белән озатып калган немец офицерының күзләре иде бу. Кәлүкнең өстенә гөжләп торган самавыр аугандай булды. Агулы икмәк бу егетнең бабасын алып китсә дә, теге немецның җирдә нәселе калган икән ләбаса. Һәм шул нәсел, Кәлүк нәселенә ялганып, тармакланырга маташа... Кешенең Җирдәге ризыгы үзенекен итә. Менә, күрдеңме инде, Кәлүк, ипи рәнҗеше сине барыбер эзләп тапты. Хәерлегә була күрсен!

– Йәгез, тагын бер дога кылыйк, бичәләр! – дип, ул учларын догада кушырды. Кәлүк эчендә кайнаган давыллы уйларын дога сүзләренә кушып йотып җибәрде. «Бичәләр» картның йөзенә төшкән уйчан күләгәнең сәбәбен белми калдылар.

АВЫЛ ТУЕ – АВЫЛ КӨЕ



Авыл бәйрәменә чакыру алгач, йөрәк Сабантуйга әзерләнгән чабыш атыныкыдай ярсып, тарсылдап куйды. Яңавыл, халык телендәге исеме Җаңавыл (минем өчен – Җан авыл ул), 90 еллык юбилеен бәйрәм итә икән. Исеме җисеменә муафыйк – яңа авыл ул. «Зур тарихлы Көчек авылыннан күчкән бабаларыбыз», – дип хәтер яңарта Сәмига апа – сиксәнне узып, яше туксанга авышса да, авылның яшь абыстае. Яшь гаиләләргә тормыш корыр өчен җирлек, эш бар! Авылга кул сузымы җирдә – тау башында заманча агроферма сафка баскан. 200 баш мөгезле эре терлек – читтән кайтартылган, мул сөтле савым сыерлар асрала торган ферма замана техникасы белән җиһазланган. Агрофермада безнең авылдан утызлап кеше эшли.

Җирле үзидарә башлыгы Хәлил Ногманов, әнә, горурланып сөйли:

– Бу бәйрәмне – 1929 елда нигез салынган авылыбыз туе итеп, җәй белән көз кисешкән мәлдә – август уртасында үткәрәсе иттек. Вакыт табып кайтуыгызга зур рәхмәт, – дип, авыл офыкларын киңәйтә торган эшләргә туктала. Сүз, билгеле, агрофермага барып тоташа. – Эш урыны, акча булса, иренми халык, йорт та сала, бакчасын да тота, иркен яшәү җаен таба!

Ачык һавада – Мәдәният сарае эргәсендә бәйрәм тантанасына җыелган халык тамаша башланганчы ук дулкынлана. Ничә еллар күрешмәгән якташлар, дуслар, туганнар белән очрашу, хәл-әхвәл белешү күңелләрне кузгата шул. Барысы да үз, якын икән! Балачактан таныш йөзләр... Яшьләрне апа-абыйсына, әти-әнисенә охшатып төсмерләргә тырышасың...

Мәдәният сарае гөрләп эшли икән әле. «Шатлык» бию ансамбле үсмерләренең табаннарыннан ут чыгарып, төрле халыкларның биюләрен биюләре тамашачыларны дулкынландырды. Ансамбль җитәкчесе – Рәзинә Османова, заманында Хәлил-Галиябану булып уйнап, безне гашыйк иткән Рәйсә апа белән Мәгъсүм абый Бикмөхәммәтовларның төпчек кызлары икән. Сызылып киткән кара кашлы, дулкын чәчле Рәйсә апаның чибәрлеге, зәпзәңгәр күзле Мәгъсүм абыйның моңлы тавышы магнитофон тасмасына язылгандай йөрәккә уелып калган шул. Сәнгать дип, талантлы балаларга мәйдан кирәк дип, җаны-тәне белән тырышып йөргән Рәзинәнең игелекле эше, матурлыкка омтылышы, димәк, әти-әнисеннән – каннан килә. Бәйрәмне оештыруга күп көч, осталык сарыф иткән мәдәният хезмәткәрләренең тагын берсе, гаҗәеп матур, эчтәлекле ошбу кичәне алып баручы – нәфис сүз остасы дисәң дә арттыру булмас, Рәсимә Галиева да үзебезнең авылныкы, Гөлсем апа белән Мансур абый кызы. Фани дөньядан китсәләр дә, игелек орлыкларын мул чәчеп калдырган әти-әниләре!

Истәлекләр, хатирәләр дә күңелне кузгата икән. Колхоз оешкан, беренче трактор кайткан, сугышка киткән ир-егетләрнең җырлап урам әйләнгән чаклары, «похоронкалар» килгән вакытлар да җуелмаган әле хәтердән. Яңа Бәзәкә авыл советына кергән сигез авылга фельдшер-акушер итеп җибәрелгән Кафия апа Минһаҗева истәлекләре дә тәэсирле: «Минзәләдә ФАШ бетереп килгән идем. Медпункт та, торыр җир дә юк. Сугыш чорында хәлсезләнгән авылны йогышлы чирләр баскан, – дип сөйли 93 яшьлек хезмәт ветераны. – Авырлыклар үтә, чирләр дә... Илләр генә тыныч булсын!» Яңавыл килене булып, балалар, оныклар үстергән, кырык ел халык сәламәтлеге сагында торган Кафия апага багышланган язманы «Сөембикә»не укучылар яратып укуын хатлар сөйли.

Төрле елларда колхоз рәисләре булып эшләгән Котдус Сәлахиев, Сәгыйрь Гобәйди, Ильяс Кәрәмиев чыгышларын да авылдашлар алкышлар белән каршылады. Йөзләгән кунак сыйланырлык итеп әзерләнгән мул табын, бәйрәмгә ямь бирүче гаҗәеп чыгышлар турында озаклап сөйләп булыр иде әле. Чиләк ярым сыешлы алты самавыр кайнап торуы, зур казанда пешкән пылауның, КамАЗ кузовына кунаклаган күчмә мичтә – табаларда туктаусыз биегән коймакларның тәмлелеге...

Сый-хөрмәттән хушланып, кичке тамашага кадәр ял итү өчен тәнәфес ясалды. Күптән күрешмәгән дуслар, таныш-белеш белән кочаклашып, хәлләр белешеп юанган арада бер кызык хәлгә юлыктым. Армый-талмый баян телләрен тарта-тарта тирләп-пешкән баянчы янына җыйнак кына буй-сынлы бер апа килеп тә басты: «Мин борынгы кеше, шуңадыр элекке көйләрне яратам. Уйна, туган, «Иске карурман»ны, – дип әйтеп тә өлгерде. Егет баян телләрен барлаган арада моңлы тавыш белән җыр сузарга да тотынды: «Кара да гынай урман, караңгы төн, / Яхшы атлар кирәк лә үтәргә; / Кара урманга кергән чакта, / Кисеп алдым пар усак, / Ай, аерылмаек дус булсак... / Дус-иш кирәк гомер итәргә лә...» Халык көенә һич хилафлык китермичә, мин белгән, һәм дә белмәгән сүзләрен өсти-өсти озак җырлады апабыз. Күзеннән яшьләре тәгәрәп төшкәнче, баянчы тәмам арып туктаганчы... Мин аны танымадым.

«Сәмига апаны белмисеңмени? Бәйкидә яши, 85 яшьтә. Машинага утырмый, Бәйкидән авылга җәяү кайта. Розалияләре белән бер класста укыдың ич, Гакыйф, Сәгъдүнәләрнең апасы бит ул», – диделәр. Бәйки бездән егерме биш-утыз чакрым ары, ә Сәмига апалар әллә ничә бездә...

Җирсү! Сагыну йөртә торгандыр адәм балаларын! Авыл туен күреп, авыл көйләрен ишетеп куанырга һәм моңланырга авылың булсын ул! Сагынганда кайтып керергә, бер хозурланырга өебез бар. Бердәнбер энекәшебез Радик йорт-җирне карап тора. Шөкер, уңган, ачык йөзле киленебез – Яңа Бәзәкә кызы Венера – кайчан кайтсак та, якты йөз белән елмаеп каршы алыр. Шөкер, Җанавылым исән әле дип куану үзе бәхет бит ул.

Роза МУЛЛАНУРОВА

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Күңелдән бик күп хатирәләр, бик күп кешеләр җуела, ләкин яраткан укытучы һәм аның белән бәйле вакыйгалар мәңгегә саклана икән. Без үскән чорда авылда иң абруйлы кешеләр укытучылар иде. Алар безгә белем генә түгел, тәрбия дә бирде.

Мин Актаныш районы Пучы авылы мәктәбендә укыдым. Укытучыларның иң көчлеләре, иң әйбәтләре укытты безне. Класс җитәкчебез Гөлшат апа ана телебезнең матурлыгын, аһәңен ачты. Флүрә апа саннар дөньясы белән таныштырды. Тарихтан мәктәп директоры Зәйнуллин абый белем бирде. Аның хатыны Мәсгудә апа бик матур киенеп йөри иде. Аның: «Кызлар, кара төсле кием кияргә тырышмагыз, кара төс кәефне төшерә ул», – диюе гомер буе истә торды.

Ул елларда укытучының хезмәт хакы бик аз, аңа, күп булса, ике капчык бәрәңге тигәндер. Ә безнең укытучылар һәрвакыт чиста, пөхтә киенеп йөрде. Һәр сүзне үлчәп сөйләүче, зәвыклы, затлы кешеләр иде.

Директор абый әкрен генә басып йөрүче олпат гәүдәле, бик җитди, коры кеше иде. Ык-мык килеп торсаң, кашларын җыерып карап тора да, кинәт елмаеп җибәрә: «Утыр, «икеле» куям. Әле журналга төшермим, күңелдән генә куям. Икенче дәрестә төзәтерсең», – ди.

Бер егетебез шигырьләр язарга ярата иде. Кайчак хәтта дәресне дә онытып җибәрә. Гөлшат апа сорау бирә, ә ул ишетми дә ишетми. «Икеле»не журналга куярга туры килә инде», – ди укытучы. Тегенең исе дә китми. Тәнәфестә безгә яңа шигырен сөйли: «Тышта буран көчле бүген, / Яфрак хәтле кар төшә. / Андый ук эре кар түгел – / Журналга «ике» төшә».

Укытучы аның хәленә керә, дәрестән соң алып калып, шигырьләренә анализ ясый. Чирек ахырында берәүгә дә начар билге чыгармый.

Физика дәресләре дә хәтердә. Берсендә электр турында тема үтәбез. Флүрә апа урындыкка утырды да, төрле төстәге төймәләргә баса башлады. «Сез минем пассажирларым. Мин сезне трамвайда кирәкле тукталышка илтеп куям», – ди. Ә без, 15–20 чакрым җәяү йөреп укучы балалар, трамвайның ни икәнен дә белмибез. Авыр теманы да шулай җайлы итеп аңлата иде ул.

Химия һәм биологияне Мәрзия апа укытты (Минтимер Шәймиевнең бертуган апасы). Бакчага эшләргә чыксак, гаилә кору, мәхәббәт турында киңәшләрен бирә иде. Ире Кыям абый хезмәт дәресеннән керде. Бик матур, тату гаилә булдылар.

Класс җитәкчебез Гөлшат апа соңгы елларда Чаллыда яшәде, «Татарстанның атказанган укытучысы» исеменә лаек булды. Гаҗәеп сабыр холыклы, безне чын күңелдән кайгыртучы киңәшчебез, безгә икенче әниебез кебек иде.

Яраткан укытучыларым үрнәгендә үзем дә шушы һөнәрне сайладым. Гомерем буе аларга рәхмәтле булып, искә алып яшим.

Дания БОРҺАНОВА.
Ижау шәһәре.



«Азат хатын» журналының 1986 елда басылган ул саны – гаиләбезнең кадерле ядкаре. Мин аны кулыма алганда әле дә бер тетрәнү, дулкынлану кичерәм, күзләремә яшь тула. Әйтерсең лә журнал бите аша Рокыя апам үзе эндәшә: «Әни, бәгърем, мин кайттым!»

...Буадан сугышка чыгып киткән дүрт кызның берсе – безнең Рокыя апабыз. «Әни, бәгърем, көт, җиңеп кайтырбыз», – дисә дә, көрәшүләр

Фото: Газинур Хафизов

башка насыйп булмый аңа. Бу кызлар турында журналист Эльмира апа Әдиатуллина әле 1968 елда ук журналда язып чыккан булган. Рокыя апаның әти-әнисе – Нигъмәтҗан абый белән Гөләндәм апалар да исән әле ул вакытта. Гөләндәм апа кызының хатларын гомер буе кадерләп саклый. Өчпочмаклы хатларның берсе бигрәк үзәкләрне өзә, кулларны өтә торган: «Медицина хезмәте сержанты Рокыя Мусина Социалистик Ватан өчен сугышта батырлык һәм фидакарьлек күрсәтте, хәрби антына тугрылыклы булып, батырларча һәлак булды».

1943 елның 27 июлендә Орел өлкәсендә минага эләгеп башын салган ул.

2016 елда үзем эшләгән редакциягә бер хәбәр килде: Буаның М. Вахитов урамында туган Рокыя Мусинаның туганнарын эзлиләр. Башта мин моңа ышанмый тордым, аннары, исемә килеп, тиз генә күрсәтелгән номерны җыйдым. Эзтабарлар отрядының активисты Владимир белән мин әнә шулай танышып киттем. Интернет аша аларга Рокыя апаның фотоларын җибәрдем. «Чынлап та шул микән, ялгышмыйлармы?» – дигән уй да борчып алгалады. Өч елга сузылды бу эш. Ә быелның апрель аенда Рокыя апаның бертуган сеңлесе Зәйтүнә апа ризалыгы белән ДНК тикшерүе үткәрү өчен материаллар җибәрдек. Өч айдан тестның нәтиҗәсе билгеле булды – 99,9 процент! Болар өчен бездән бер тиен алмыйча, шушы игелекле зур эшне башкарып чыккан эзтабарлар отряды егетләренә мең рәхмәт.

28 август көнне ислам диненең барлык йолаларын үтәп, догалар кылып, Рокыя апа Мусинаны Орел өлкәсеннән иң соңгы юлына – Татарстанның Буа шәһәренә озаттылар. Вафатына 76 ел булганнан соң, 29 август көнне Буаның батыр кызы туган ягына кайтып җитте. Шатлыклы да, үзәкләрне дә өзәрдәй вакыйга иде бу. Барлык туганнары җыелып, апабызны – Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән гвардия сержанты, комсомолка Рокыя Мусинаны туган җиребез куенына салдык. Мәңгелек йорты – әти-әнисе һәм туганнары янында, «Иске татар зираты»нда хәзер.

Рокыя Мусинаны соңгы юлга озатырга ярдәм иткәне өчен Буа муниципаль районы хакимиятенә, социаль яклау идарәсенә, эзтабарлар төркеменә, барлык туганнарга рәхмәт белдерәбез.

Рөстәм ӘХМӘДУЛЛИН.
Буа шәһәре.

Без Казанның Идел буе районына кергән Тынычлык (Мирный) бистәсендә яшибез. Элеккеге елларда Лесное Матюшино авылы янында обком дачалары бар иде. 25–30 еллар элек бу дачаларга юл безнең Тынычлык бистәсе аша булды.

Мәскәү тарафларыннан килеп чыккан кадерле кунаклар да күп узды бистәбездән. Сәкинә ханым да гел безнең тирәләрдән уза иде. Кайсы Сәкинә турында язуымны әйтмәсәм дә, чамалыйсыздыр: беренче Президентыбызның хәләле Сәкинә ханым Шәймиева турында әйтүем.

Олы юл буендагы авылларда яшәүче халыкның бер шөгыле бар – үз хуҗалыгында җитештергән ризыгын үткән-сүткәнгә сатарга тырыша. Безнең бистә халкы да урам башындагы буш урынга җыелып, кечкенә генә базар оештырды. Сәкинә ханым бу базарга еш туктала, сөткаймакны, иртә өлгергән яшелчәне шушыннан сатып ала иде. Аның татар хатыннары, татар апалары белән шулкадәр матур, ипле итеп сөйләшкәне сокландырырлык иде. Ул үзен шулкадәр гади тота, бернинди дә тәкәбберлек, мин-минлек юк иде анда. Кайчагында, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен дия-дия, әбиләргә сәдака өләшә. Базарда йөргәндә сатучыларның аягөсте торуын, утырып сатарга өстәл-урындыкларның юклыгына да игътибар иткән булган икән Сәкинә ханым. Петровский торак массивында урнашкан «Пригородное Матюшинское лесничество» җитәкчесе Маннур Миннәхмәт улына мөрәҗәгать итеп, сатучыларга утырып торыр өчен эскәмияләр ясаттыруын үтенгән. Бер-ике көн эчендә товарларны куеп сатарга уңайлы өстәлләр, эскәмияләр ясап куйдылар.

Халык Сәкинә ханымга өстәлурындык сорап кына мөрәҗәгать итмәде. Ул һәркемгә игътибарлы иде, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Шул рәвешле күпләргә кешелеклелек үрнәге күрсәтте.

Ә хәзерге күп кенә җитәкчеләрнең халыкның көндәлек тормышына игътибарсызлыгын, кешеләрнең гозеренә колак салмавын күрәбез. Безнең бистәнең Мәктәп тукталышында иске бер фургонны ипи сатарга көйләгәннәр иде. Шунда гына бер озын эскәмия дә торды. Ипи алырга килүчеләр өчен дә, тукталышка чыгып тегесен-монысын сатучылар өчен дә бик уңайлы иде ул. Иске фургонны алып, яңа ипи кибете салганда теге эскәмия дә юкка чыкты. Шуны кабат булдыру артыннан йөреп, дүрт елым узып китте... Кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем. Ахыр чиктә шәп кенә бер эскәмия ясап куйдылар. Ә менә Югары Кабан тукталышына эскәмия куйдыруга ирешеп булмады, ахыр чиктә үзем ясап илттем. Соңыннан ике калын тактадан яңасын ясап куйдылар куюын...

Язмам озынга китсә дә, безне борчыган тагын бер мәсьәләне язмый булмый. 2011–2012 ел башларында Тынычлык бистәсе белән Казан арасында йөреп торган 69 һәм 69 а автобус маршрутлары туктатылды. Бу безгә аяз көнне яшен сугу кебек тәэсир итте. 129 нчы мәктәптә эшләүче укытучыларга, 3 нче хастаханә табибларына, медперсоналга юл йөрү бик кыенлашты. Ул вакытта җитәкчеләр моны вакытлыча гына хәл дисә дә, ул автобуслар бүген дә юк. Вакытлыча дигәне ничек була икән: көнме, аймы, елмы? Безгә ул автобусларны тагын күпме көтәсе икән соң?

Рәшит НУРГАЛИЕВ.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru









Фотолар Иске Байсар авылы мәктәбе тарихы тупланган альбомнардан алынды.

«МИНЕМ МӘКТӘП – ДӨНЬЯДА БЕР!»



Эльмира ЗАКИРОВА

Кайчак мәктәпнең исемен генә әйтү дә җитә. Мәгариф дөньясында ул визит карточкасы сыман.
Кешегә белемне дә, тәрбияне дә, әдәп-әхлак кагыйдәләрен дә, тормыш дәресләрен дә иң башта мәктәп бирә, мәктәп сеңдерә. Югары белемнең нигезе – үзең укыган мәктәптә. Ә институт шул белемне тулыландыра, системага гына сала. Шәхесләр мәктәптә үсә.
...Класс бүлмәләренә кереп йөргәндә, мәктәп музеенда үзеңнең балачак фотоларын караганда, укытучыларың, классташларың белән кабат очрашканда, ниндидер яңа бер халәттә каласың. Үзең – олы кеше, үзең – бала-чага! Мин үзем инде йөз елдан артык тарихы булган үз мәктәбемне – авыл мәктәбен, татар мәктәбен – теләсә кайсы элиталы мәктәптән дә өстенрәк күрәм! Калын альбомнарга том-том итеп язылган мәктәбебез тарихы әллә нинди уку йортлары тарихыннан да баерак, кызыклырак тоела. Класс җитәкчем Сәлимә апа Якупова җибәргән фотоларны барлап утырам...

Күпләр белми генә: укытучы кызы булу җаваплы да әле ул!

Мәктәпләрдә тагын укулар башланды... Бик кызык чор бу! Укытучылар, әти-әниләр, бала-чага, бер-берсен тел төбеннән үк аңлап, (кайчак аңлаша да алмыйча!) берара бары бер генә телдә сөйләшә. «Форма», «дәфтәр-ручка», «фломастер», «дәреслекләр» телендә...

Көз килүен хәбәр итеп, мәктәп сукмагына берән-сәрән яфрак төшә. Ул әле сарыга манчылмаган. Ул инде яшел дә түгел. Койма рәшәткәләре артында ак, ал, шәмәхә кашкарыйлар, дәлияләр күренеп кала. Шул чәчәкләрне тоткан беренчеләр мәктәпкә атлый... Яңа уку елы башланган көннең шушы сурәте шәһәрдә дә, авылда да бер бугай. Рәссам шундый картина язса, исемен, һичшиксез, «Беренче сентябрь» дип куяр иде.

Мәктәптә – буяу исе, чәчәк исе, яңа китап исе, акбур исе... Монысы да бары уку елы башындагы мәктәптә генә шулай. Мәктәпләр барысы да бер-берсенә охшаган кебек... Юк, беренче карашка гына шулай бу! Һәр мәктәп үзенчә матур, үзенчә көчле. Ул башка мәктәпләрдән үз тәртипләре, үз традицияләре белән аерылып тора.

Минем өчен ул мәктәп дөньясы бигрәк тә якын, кадерле. Чөнки әти белән әни озак еллар шул мәктәптә укыттылар. Еллар узгач кына алар күпләрнең яраткан укытучылары булганын аңладым. Укучылары сагынып сөйлиләр, төрле кызыкларны искә төшерәләр. Ул кызыклар миндә дә шактый. Укытучы кызы булыйм да!..

Укытучы кызы

Бу үзенә күрә бер статус, нindидер элитага каравыңны белдерүче билге бугай. Кайберәүләр «кыланчык», «тәкәббер», «иркә» дигән ярлыклар тагарга ашыга. Һич тә килешмим инде! Нечкә күңелле, хыялый, риясыз дисәләр соң... Син яхшы укырга, масаймаска, мактанмаска, әләкләшмәскә, кеше сөйләмәскә тиеш... Юк, беркем өйрәтми боларны. Нindидер эчке тоемлау белән үзең чыгарасың ул кагыйдәләрне. Чөнки син уч төбендә кебек: Роза апа, Мизхәт абый кызы дип, гел сынап карыйлар. Әти-әниең синең класста дәрес биргәндә, башкалар аңлап бетермәслек ситуацияләрдә дә калырга туры килә әле. Куелган сорауга җавап бирергә кирәк булса, кул күтәрә башлыйлар, түземсезләнеп: «Апа, мин!..», «Абый, үзем әйтәм!» – дип кыбырсыйлар. Ә мин берара югалып калам. «Әни» йә «Әти» дип кычкырып утыра алмыйм бит инде! Көлә башларлар... «Апа, апа!..» дип, кул күтәрәм. Класс гөжләп ала, көләләр. Әни дә елмая...

Җир тишегенә кереп китәрдәй хәлләрдә дә калганым бар. Китап, дәфтәрләрем өйдә онытылган нишләптер. Әти дәрестән куып чыгарды. Үпкәләүдән түгел, аны кыен хәлдә калдырудан күзләремә яшьләр килде. Укытучы балалары шундый буладыр инде ул: әти-әнисенең дәресе кызык үтсен дип эчтән гел янып утырадыр!

«Укытучы баласын яклыйлар» дигән йөремсәк сүзләрнең дөрес түгеллегенә дә инандырырга кирәк әле. Әзерләнми килеп кенә кара берәр дәрескә – «Учительская» дигән бүлмәдә фән укытучысы шундук әти-әниеңнән «сөенче» ала! Ояты ни тора бит! Алар йөзенә кызыллык китерү һич гафу ителми торган гамәл инде. Әти-әни – авылның абруйлы кешеләре. Бөтенесе аларга киңәшкә килә. Алар сүзе үтемле дә, дәрәҗәле дә. Күп укыйлар. Кочак-кочак газета-журналлар алдыралар. Төннәр буе дәрес планнары төзеп утыралар, дәресне кызык итеп үткәрү өчен ниләр генә уйлап тапмыйлар, ниләр генә эшләмиләр!.. Ә монда «кызың җавап бирә алмады» дигән үтерический хөкем карары... Шуңа күрә без һәр җирдә үрнәк булырга тырыша идек. Ә укытучылар, мәктәп тормышы турындагы китаплар, фильмнар күңелгә аеруча якын. Кайбер геройларны бөтенләй идеал итеп күрәбез. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романын кулдан-кулга йөртеп укып чыктык. Укытучы кыз Нәркис образы күңелемә аеруча хуш килгән иде. Зыялы, матур киенә, матур сөйләшә, күп укый... Университетта укыганда исә язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев җитәкчелегендә диплом эше язу насыйп булды миңа. Бер сөйләшкәндә язучыга күңелдәгесен әйтеп бирдем: «Күпләр сезнең Ләйләгөл образын яратты. Ә миңа менә Нәркис ныграк ошый!» – дидем. Мөхәммәт абый шунда: «Чөнки син үзең Нәркискә охшаган», – дигән иде. Белсәгез иде, бу минем өчен шундый зур мактау сүзе булып яңгырады!

Укытучы кызлары булуыбыз үземә дә, сеңлем Ритага да офыкларыбызны киңәйткәндер. Ул әле дә төрле-төрле сурәтләрдә сагындырып искә төшә.

Дүшәмбе – политуку, җомга – педсовет...

Бу укытучыларның бер буш көне юк! Сишәмбе көнне әни классы белән газета чыгара, пәнҗешәмбе түгәрәкләр көне, җомгада ата-аналар җыелышы. Кич репетицияләр... Көзге кросс. Көзге бал, өмәләр.. Укытучылар спектакль куярга әзерләнә. Алдагы атнада РОНОдан фронталь тикшерү... Аннары чирек йомгаклау.

...Безнең өйгә әллә никадәр журналлар килә. Башка кызлар аларның күбесен ишетеп тә белми. «Москва», «Знамя», «Роман-газета», «Журналист», «Юность»лар...

...Әти-әни, сеңлем, мин пароходта дүрт кешелек каютада Казанга, Уфага барабыз, самолетта Ижауга очабыз...

...Кино артистларының фотоларын җыю – минем хобби. Берзаман алар 500 дән дә артып китте! Махсус альбом сатып алдым. Аннан хәзер Марк Бернес, Тихонов, Мордюкова, Табаков, Вертинскаялар елмая.

...Авыл клубына концерт-спектакльләр еш килә. Ә без директор кызы Гөлшат белән артистларга чәчәкләр менгерәбез, автографлар алабыз... Ул Әлмәт театры актрисасы Дамирә Кузаева белән хатлар язышa башлады. Ул хатлар берзаман медицина институты тулай торагында яшәүче студент Гөлшатка килә иде инде.

...Әни атаклы рәссамнарның картиналарыннан репродукцияләрне гел җыеп бара. Аннан ул аларны төпләтте, һәм калын альбом килеп чыкты. Айвазовский, Суриков, Серов, Левитан, Шишкин картиналарын кечкенәдән таный өйрәндек шулай.

PRESSA

Укытучы ул – баланың гына түгел, авылның да тәрбиячесе.

...Советлар Союзының хоккей җыелма командасы безнең кумирлар иде. Без, бер төркем фанат кызлар-малайлар, эти җитәкчелегендә (ул шәп җанатар!) әлеге дә баягы «Учительская»га җыелып (телевизорлар берәүдә дә юк чак – 70 нче еллар башы), һуштан язып, «Әйдә инде, Харламов!», «Мальцев, тизрәк!», «Молодец, Фирсов!» дип кычкыра-кычкыра, ять-яшь капкачы Третьякны мактый-мактый, әле чехлар, әле шведлар белән матчларны төне буе карыйбыз. Мәктәп директоры да сүз әйтми. Хәер, директор кызлары үзләре дә безнең арада!

...Әни немец теленнән укытты безне. Аның елмаеп: «Guten tag, die schuler!» дип класска килеп керүләре, һәр дәресен күңелле уен кебек үткәрүләре (лото да уйныйбыз, җырга салынган немец теле алфавитын пластинкадан да тыңлыйбыз, диалоглар да оештырабыз) безгә ял кебек тоела иде. Әти башлангыч хәрби әзерлек дәресләрен алып барды. Ул исәнләшеп керүгә һәрчак: «Здравия желаем, товарищ капитан!» дип сәламлибез. Ул хәрби киемнән керә, погоннарында – дүрт кечкенә йолдыз. Калашников автоматын күзне дә бәйләп вакытка җыепсүтәбез, тирда кече калибрлы винтовкадан атабыз. Малайлар әтине аеруча ярата. Кайберләре хәрби училищеларга китеп, хатлар язып торалар...

...Мин «Зәңгәр шәл»не 3 нче класста ук укып чыктым инде. Әти көн саен рольгә кереп, кичке репетициягә әзерләнә, миңа кызык. Тагын ниләр булыр, дип, качып кына Кәрим Тинчурин пьесаларына ябышам. Безнең авылда укытучылар куйган спектакльләрне аеруча яраталар, клуб шыгрым тулы була. Ә әти һәрчак төп рольләрдә. Шулай «Зәңгәр шәл»дә ул ишанны уйнады. Башлангыч класс укытучылары Вәсирә, Галия, Бәһиҗә апалар, татар теле укытучысы Гөлсем апа – ишан хатыннары, Рәсимә апа – «абыстайлар куера, токмачлар килсен», дип кунакка чакыручы малай ролендә, Әлфия апа – Мәйсәрә, Рим абый – Булат...

...Безнең Байсар урманында ел саен район туристик слеты уздырыла. Палаткаларда поход тормышында яшәп алабыз. Кулга карта, компас тотып, урында ориентлашу буенча командалар арасында ярышабыз. Миңа төньяк-көнчыгыштагы сазлыкны, тар урман сукмагын, яшь нарат үсентеләрен табып, контроль пунктта билгеләтергә һәм тиз генә финишка йөгерергә кирәк. Барысы да табылды! Безнең мәктәп командасы – тагын беренче! Укучылар гына түгел, укытучылар командалары да ярыша шулай. Һәм алар районда гына түгел, республика ярышларында да җиңеп, беренче урынга чыга. Ул командада, әлбәттә инде, әти дә бар! Бер елны укытучыларыбызны Пушкин исеме белән бәйле урыннарга сәяхәт белән бүләкләделәр. Ә икенче елны алар, кабат җиңеп, Төньяк Кавказга җәяүле походка чыгып киттеләр.

...Безнең мәктәп һәрчак спортта – беренче, смотр концертларында – беренче, фән олимпиадаларында – беренче... Физика, химия, биология буенча район олимпиадаларында җиңеп, Байсар мәктәбе укучылары Казанда, республика олимпиадаларында Актаныш данын яклап кайталар хәтта.

...Бу уңышларның башында, әлбәттә, тәҗрибәле, белемле, укытучыларның да, балаларның да, ата-аналарның да җаен белгән зирәк җитәкче Басыйров абый тора. Мәктәп директоры, РСФСРның атказанган укытучысы, сугыш ветераны Басыйров Миргалим Шәйхелгыйлем улын әнә шулай йөртәләр иде бездә.

Август киңәшмәсе

Без – укытучы кызлары өчен яңа уку елы августтан ук башлана. Мәктәпкә яңа укытучы килгәнен иң алдан без беләбез. Исеме ничек, нинди фәннән керәчәк, кайсы классларда укытачак – әнисеннән җебенәчә ачыклыйбыз, һәм ул хәбәр яшен тизлегендә бөтен авылга тарала.

Безнең тормышта август киңәшмәсе дигән укытучылар конференциясе бар бит әле тагын! Юк, аның бар кызыгын, ыгы-зыгысын, бәйрәмчә үзенә бер атмосферасын укытучы балалары кебек куанып кабул итүче башка берәү дә булмас. Укытучы апалар районга киеп төшәр өчен яңа күлмәкләр тектерә, биек үкчәле туфлиләр сатып ала, йә чәч кистерә, йә чәч бөдрәләтә. Әнинең зәңгәр гофре итәге, кримплен күлмәге, ак «шпилька» босоножкалары – бар да килешле, чәчләрен «бабетта" итеп өеп куярга сеңлем белән без киңәш итәбез, ул күз алдында үзгәрә, шәһәрчә күренә башлый. Әти дә ак күлмәкләрен үтүкли, костюм-чалбарын, галстукларын хәстәрли. Алар район үзәгендә яшәүче укытучы дусларында тукталачак. Күчтәнәчкә әни колмакка мичтә үзе пешергән ипине, балан бәлешен, җиләк-бөрлегән вареньеларын тутыра. Шулай итеп, мәктәп машинасының әрҗәсенә тезелгән эскәмияләргә утырып, өч көнгә (!) Актанышка төшеп китә укытучылар. Бездә дә, директор абый кызлары Гөлшат, Гүзәлләрдә дә, завуч Әгъзамов абыйларның Резедаларында да – аулак өй! Өч көн үзебез генә дөнья көтәчәкбез. Сарыкларны иртүк көтүгә чыгару, тавык-казлар, бакча... Ә кичен клубка киногә барачакбыз! Башта Гөлшатларда «Йорт эшләре» китабыннан карап печенье пешерәбез әле. Пластинкадагы җырлар бар көченә куелган. Полад Бюль-Бюль оглының «Долалай»ы, Батыр Закировның «Беглянка Хабиба»сы, Илһам Шакировның «Гөлмәрьям»е бөтен авылга яңгырый бугай! Күңелле!

* * *

Хәзер инде мәктәбем дә, класслары да – бүтән: заманча, яңа. Өченче каттагы класс тәрәзәләреннән Сөн елгасы, Чәүкә, Каравыл, Алка әби таулары, Тимер тырнак әрәмәләре, бакчалар, мәчет манарасы, яшел, кызыл түбәләр күренә. Күр әле, хәтта табигать тә дәрес бирә икән туган мәктәптә! Матурлык, зәвык, соклану дәресләре. Тәрәз төбендәге гөлләр, өстәл, парталар... Бар да үз урынында. Хәтта кара такта да тылсымлы сыман! Акбур алып, шул тактага язам: «Безнең мәктәп – дөньяда бер!» Бу сүзләрдә әйтелеп бетмәгән әллә никадәр кадерле хатирәләр, укытучыларыма булган рәхмәт хисләрем...

БАЛАДАН КӨНЛӘШӘМ

ИЛСАФ, Татарстанның халык артисты, җырчы

Безгә Аллаһы Тәгалә бар якны да тигез күрергә кушкан. Кайсы хатыныңнан тууларына карамастан, барлык балаларның да әтиләре өстендәге хаклары бертигез. Әти белән әни аерылышты дип кенә, бала әтисенә мохтаҗ булудан туктамый, ул үсә, аның ихтыяҗлары да арта гына бара. Кайсы никахтан туулары мөһим түгел, иң мөһиме: алар синең балалар һәм син аларны үзең үстерергә тиеш. Ирнең икенче хатыны кияүгә чыкканда бу баланың булуын белгән бит, хәзер инде үзе дә акыллы, сабыр булырга тиеш.

Ә инде беренче никахтан туган балаңның әнисе акыл беләнме, хәйлә яки ялган беләнме, балага дигән сылтау белән ир кешедән акчаны күбрәк таләп итә икән, анысы аның җаваплылыгында. Кылган гамәлләре өчен һәркем үзе җавап бирә.

Иремнең беренче никахыннан туган баласы бар. Җае чыккан саен, ул тизрәк аның янына ашыга. Көчтәнәчен, бүләген бер дә калдырмый. Ярый, барсын да, күрсен дә ди. Ачуымны башка нәрсә кузгата: берәр нәрсә кирәк булса, ул баланың әнисе тизрәк иремә шалтырата башлый. Баласына аркаланып, аны рәхәтләнеп «сава» кебек тоела миңа. «Үземнең балам бит ул. Мин карамый кем карасын аны», – ди ирем, шул хакта сүз башласаң. Безнең үз балабыз да бар, миңа калса, аңа әтисеннән шуның кадәр игътибар эләкми дә бугай.

Исемем редакция өчен генә.
Казан шәһәре.

Илсөя БӘДРЕТДИНОВА, җырчы

Бала ул һәрвакытта да бала, чит балалар булмый, диләр. Ә бу – иреңнең газиз баласы. Ул баланың синең алда бер гаебе дә юк. Үзем дә иремнең икенче хатыны булып яшәдем. Аның да беренче никахыннан туган балалары бар иде. Мин аларга читләргә караган кебек карамадым. Алар да безнеке иде, бары – бергә, югы уртак булды. «Минекеләргә шундый яхшы караштa булганың өчен, сине тагын да катырак яратам», – дигән чаклары булды Илфакның. Ләкин мин моны аңа ярарга тырышып эшләмәдем. Әтиләрен яратып чыккач, балаларын да кабул итәргә тиешсең. Әле балаларын гына түгел, туганнарын да кабул итәбез бит. Ул баланың да әтиләре ярдәменә таянырга хакы барын онытма.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

Гаилә өч төрле мөнәсәбәтләргә нигезләнеп төзелә. Алар: социаль (акча мәсьәләсе дә шушы төргә керә), эмоциональ һәм интим мөнәсәбәтләр. Әлеге хатта сүз аларның икесе турында бара.

Бу ханым язганнардан чыгып, ир кешенең беренче хатыны белән социаль һәм эмоциональ мөнәсәбәтләренең сакланып калуын һәм шактый ук яхшы булуын күрәбез. Димәк, ул ханым аларны алдан ук дөрес итеп төзи белгән, үзенә кирәгенә ирешкән һәм ир кеше дә моны кабул иткән. Җитди адымга барганчы, хатны язган ханымга иренең беренче гаиләсендә туган баласы белән мөнәсәбәтләре, ата бурычы, уртак балагызның ихтыяҗлары хакында алдан ук ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк иде. Күрәсең, мондый сөйләшү булмаган, аның әһәмияте турында уйланылмаган.

Бу ханымга әлеге хәлгә башка яктан карарга киңәш итәр идем. Беренчедән, сез ул хатыннан социаль һәм эмоциональ мөнәсәбәтләрне ничек итеп корырга кирәген өйрәнә аласыз. Әнә бит, интим мөнәсәбәтләр булмаган шартларда да ул башкаларын нинди югары дәрәҗәдә саклап кала алган. Хаттан аңлашылганча, ир кеше үзенең аталык бурычларына бик җаваплы карый. Димәк, уртак балагызга да аның мөнәсәбәте шундый ук була ала. Әгәр дә бу алай түгел икән, социаль һәм эмоциональ мөнәсәбәтләрдә чатаклык бар. Үпкә-ачуларны бер читкә куеп торып, ирегезгә кояшлы ягыгыз белән борылып карагыз әле. Ачуланып, тәнкыйтьләп кенә бернәрсәгә дә ирешеп булмый. Мөнәсәбәтләрне усаллык белән түгел, күңел җылысы белән генә төзәтергә мөмкин.



ИРЛАНДИЯ



Айсинә МИНҺАҖЕВА

Маргарет Митчелл романының төп герое Скарлетт О'Хараны, бөтен теләкләреңне чынга ашырырга ярдәм итүче ирланд тылсымчылары – леприконнарны, искиткеч ирланд музыкасын һәм Конор Макгрегорны дөньяга бүләк иткән мәңге яшел утрауга сентябрьнең матур бер көнендә килеп төштем. Бирегә аяк басуыма ике атна уздымы икән, UFC турнирларын күзәтеп баручылар мине кардәшебез, Дагстан егете Хәбиб Нурмагомедовның җиңүе белән котлый башлады. «Рәхмәт, рәхмәт», – дип елмаеп утырдым – ирланд көрәшчесе Конор Макгрегорны үзем җиңгәнмени?! Сүз уңаеннан, Конор Ирландиядә бигүк популяр түгел икән. Үзен бик дорфа тота, урамда кешеләр белән әләгешкәне дә бар, диделәр – шуңа күрә халык мәхәббәтен яулый алмаган. Шулай да туристлар өчен шәп кармак.

Кышын каникулга кайткач, көчтәнәчкә аларга чәкчәк алып килдем. «Бу нинди ябышкак сосискалар?!» – дип, башта бик шаккатканнары да соңыннан мактый-мактый ашады.

Туризм, мәгърифәт һәм IT – Ирландия икътисадының нигезен тәшкил итүче өч кит шушылар. Мин үзем бу илгә инглиз теле өйрәнергә, белем һәм тәҗрибә тупларга дип сигез айга бардым. Чит илдә яшәп карау күптәнге хыялым иде. Ирландиянеме, әллә АКШны сайлыйммы, дип икеләнеп йөргән вакытта бер музыкант һәм сәяхәтче дустым миңа: «Америка – ул зур хөкүмәт, ә Ирландия – зур мәдәният», – диде. Бу сүзләр алдагы елымның кайда узачагын хәл итте дә куйды...

Беренче караштан ук Ирландия үзенең авыл рухлы ил булганын аклады. Очкычтан төшүгә, аэропорттан ике генә метр читтә – киртә артында ат көтүе йөргәнен күреп алдым. Үлән чемченәләр... «Миңа монда ошаячак икән», – дип уйлап куйдым.

Нигә ошамасын ди? Кешеләре шәп! Безнең кебекләр: гадиләр, юмор белән сөйләшәләр, сөтле чәй эчәләр... Мәктәпнең аш бүлмәсендә татарлар белән ирландиялеләр тәмләп сөтле чәй эчкәндә, латиноамериканнар безгә, үз күзләренә ышанмыйча, аптырабрак карап тора иде. Әйтерсең лә ашка варенье салып ашыйбыз! (Татарлар дидем, әйе, мәктәптә без Татарстан һәм Башкортстаннан килгән дүрт-биш татар укыдык).

Ирландиялеләр дә безнең кебек үк куе чәй ярата. Гомумән, теләсә нинди эчемлекнең катысы гына булсын аларга. Мин эшләгән Картлар йортындагы әбибабайлар да чәй белән каһвәне шулкадәр каты итеп ясаттыралар иде – хәтта аның исеннән дә ике төн йокламассың. Ә аларга таман гына!

Картлар йортында эшләргә дип мин башта ук ниятләп килдем. «Официант яки хаускипер булып урнашсам, инглиз телем әллә ни чарланмас, ә өлкән кешеләр белән курыкмыйча озаклап сөйләшеп булыр», – дидем. Ялгышмаганмын – эшем күңелле иде. Инглиз телен ныклап өйрәнергә теләвемне белгәч, Картлар йортында яшәүчеләр рәхәтләнеп миңа бушлай дәрес бирделәр. Күбесе икенче көнгә кем икәнлегемне оныта: кабат ачылып дәшә – тагын яңа дәрес башлыйбыз...

Картлар йортында эшләү инглиз теленнән белемнәремне генә арттырмады, гомумән, тормыш итү ягыннан да чыныктырды. Күп нәрсә турында уйландым, нәтиҗәләр ясадым... Тормышны сәяхәт белән чагыштырдым. Сәяхәттә вакытың чикле икәнен бик яхшы аңлыйсың, шуңа күрә аның һәр минутын файда белән уздырасы килә. Кием, кыйбатлы чүпрәк-чапрак, өй җиһазлары туплау мәшәкате үзеннән-үзе юкка чыга. Нәрсәгә алар? Барыбер үзең белән алып китә алмыйсың лабаса...

Анда яшәгән сигез ай эчендә бер ял көнендә өйдә утырмасам да, Ирландиянең мин күрмәгән урыннары байтак иде әле. Шуңа күрә соңгы ике атнамны тулысынча сәяхәткә багышладым. Һәр көне мәңге онытылмаслык булып истә калды!

Ирландиянең ике иң зур шәһәрләрен – Дублин белән Коркны аркылыга-буйга йөреп чыккан идем инде, шуңа күрә Атлантика ягына юл тоттым. Иң элек *Килларни* дигән шәһәргә килеп туктадым. Хостелга урнашканда бер егет белән сөйләшеп киттек. Аның: «Әйдә, шәһәр күрсәтәм», – дигән тәкъдименә: «Ярый, хәзер намаз укып алам да, барырбыз», – дип ризалаштым. Егет авыз эченнән генә: «Baaaad luck» (уңышсыз), – дип суздыда, күз ачып йомганчы юк булды. Шуның белән дуслык та бетте – шәһәр күрсәтү нияте дә юкка чыкты...

Сезнең белән дә шундыйрак хәл килеп чыкса, борчылмагыз, Килларни – кечкенә шәһәр. Аның үзендә, берничә пабтан кала, башка бер карар җир дә юк. Туристлар монда бөтен дөньяга билгеле булган Gup of Dunloe, Dingle Peninsula һәм Ирландиянең иң биек тавы – Carrauntouhill күрер өчен килә. (Кычкырып укырга тырышмагыз, телегез бәйләнүе ихтимал.)

Икенче көннең иртәсен зарыгып каршы алдым: мине Гап оф Данлоэ тарлавыгы көтә иде.

Яңгырлы һәм җилле көн туры килде. Экскурсиягә илтүче машина шоферы өс-киемемне җентекләп карады да, кырыс тавыш белән: «Башта – көймә, аннан соң – җәяү», – диде. Бераз аптырап калдым: гадәттә, бу экскурсиянең киресенчә узуын – көймәдә күлне гизү белән тәмамлануын белә идем.

Сүз уңаеннан, Донлоэ тарлавыгы җебегәннәр өчен түгел. Башта автобус белән юлның бер ягына киләсең, аннары биш метр киңлектәге тарлавык буенча унбер чакрым җәяү яки велосипедта барасың. Юл азагында сәяхәтчеләрне моторлы көймә көтә: бер сәгать эчендә сине кире Килларнига алып кайтып куялар.

Моторлы көймә белән су ярып баруы шундый рәхәт! Үземне чын-чынлап иректә тойдым! Ике минутлык ирек җиле өчен чыланып беткән чалбар һәм куртка белән түләргә туры килде... Ә алда бит әле унбер чакрым җәяү барасы бар! Һава торышы исә ачы көзне хәтерләтә!

Нишлисең инде, өс-башымны хатын-кызлар бәдрәфендә азмы-күпме киптердем дә юлга кузгалдым.

Күз алдында берсеннән-берсе матур күренешләр ачылганда унбер чакрым ара алай күп түгел икән. «Нарния» фильмын караганыгыз бармы? Караган булсагыз, онытыгыз! Донлоэ тарлавыгы мең өлеш гаҗәбрәк! Барган юлыңда кинәт кенә озын текә таулар пәйда була, ә алар арасында су шарлавыклары белән бизәлгән чиста күлләр җәйрәп ята... Болытлы күк йөзе бу пейзажга моңсу бер матурлык өсти... Каядыр башка галәмдә түгел, ә Җирдә икәнлегеңне төсле-төсле тамгалар куелган сарыклар гына искә төшерә.

Ирландиядә сарык яки бәрән очрамаган бер адым җир дә юк бугай.



...Ә машина шоферы юкка гына бирмәгән теге киңәшен. Юл буе җил аркамнан куалап барды: юеш, салкын булса да, сәяхәтем җил белән көрәшүгә әйләнмәде.

Галлуэй. Бу кечкенә генә кала Ирландиянең иң матур шәһәрләреннән санала. Туристлар өчен дөнья рәхәте: телисең икән – музейлар карыйсың, телисең икән – ресторанга кереп утырасың яки диңгез буенда йөрисең. Тик бу шәһәр белән якыннан танышу насыйп булмады... Мине Килларнида каршылаган яңгыр бөтен Атлантика буен каплап алган икән. Коя да коя... Бу яңгырда шәһәр карап булмас инде, дип, Cliffs of Moher, ягъни Мохер кыя ташына киттем. Сыйныфташлар белән анда бер тапкыр булган идем инде, ләкин 300 метрлык бу текә кыялар мине шулхәтле дулкынландырды, анда тагын барып озаграк йөрисем килеп калды. Корабта экскурсия алып, кыяларны диңгез ягыннан да карармын дип өметләнгән идем. Корабта экскурсиям дә түләнеп куелган иде. Океан ярында урнашкан Дулин бистәсендә автобустан төшеп калдым да, кораблар туктаган яр буена киттем. Ә җил көчәйгәннән-көчәя генә... Корабтагы бер матрос: «Бүген диңгезгә чыкмыйбыз, «урыс җиле» исә бит. Иртәгә кил», – диде. (Алар шундый каты җилне «урыс җиле» дип йөртә икән.)

«Foolhardy» – батыр һәм сәеррәк кешеләрне Ирландиядә шулай атыйлар. Мин инде ул! Әле бу сүзгә татарларга хас булган «без булдырабыз»ны да өстәсәң, минем кыяларны күрәм дип үҗәтләнгәнемне аңларсыз. «Вакыт заяга үтә бит», – дип, тизрәк автобус тоттым да киттем Мохер кыялары өстенә. Тугыз чакрым гына атлыйсы дип, әле ярый җәяү чыгып китмәгәнмен. (Бу урында битен куллары белән каплаган смайл булырга тиеш.)



Изге Патрик бәйрәмендә бар халык яшелдән киенеп, парад карарга чыга.

Барып җиттем... Кошлар утырган җирләреннән очарга дип кузгалмый. Кытай туристлары бер-берсенә ябышып та баскычтан төшә алмый интегә: җил аларга каршы исә. Мондый чакта табигать кодрәте алдында үзеңнең бер бөҗәк кенә икәнлегеңне аңлыйсың. Хәтта бөҗәкнең дә аяклары алтау, ә синең – икәү генә...

Шторм... Евразия континентының 300 метрлы таш кыялары Атлантик океанга ыргыла... Бу күренеш берәүне дә битараф калдырмас.

Ахыр чиктә мин дә җиңелдем һәм бу көннең азагын бер мавыктыргыч нәрсә дә булмаган Дулинда уздырырга карар кылдым. (Вакыт үтеп, артка борылып карагач кына аңладым: ул көнне бик рәхәт ял иткәнмен икән. Китап укып хостелда яттым, кич белән музыка тыңларга пабка бардым. Менә шулай: пабка шәраб эчәргә генә түгел, концерт карарга да йөриләр... Һәм, әлбәттә, инде юл читенә үк сузылып ятып, кичкә таба сүрелгән океанның тыныч сулышын тыңладым.)

Икенче көн миңа кичәге борчылуларым өчен икеләтә матурлык белән җавап кайтарды. Янәдән кыялар ягына барганда урта гасырлардан ук сакланып калган кечкенә сарайларны, үлән күшәп яткан пошмас сыерларны һәм... болытлар фабрикасын күрдем. Әйе, әйе, болытларның ничек барлыкка килүенә мин хәзер үзем шаһит! Океан өстеннән текә ярларга таба ап-ак пар күтәрелә, ә инде җир өсте белән очрашкач, ул пар бәләкәй мендәрләрне хәтерләткән кечкенә болытлар булып оеша... Болытлар барлыкка килгәндә, кыяларга барып та тормаска булган икән, чөнки тирә-як ап-ак томанга күмелде. Кулыңны сузсаң, бармакларыңны югалтырлык...



Автор фотолары

■ Искиткеч, дулкынландыргыч, тынны кыса торган матурлык! Тирә-якта беркем юк. Шундый сихри ялгызлыкта үзеңне Ходай Тәгалә белән икәү сәяхәткә чыгып киткән кебек сизәсең...

Мохер кыя ташы читләре буйлап йөри алмасам да, күңелемне төшермәдем, чөнки корабта Атлантика суларын гизү бөтен һушымны алды. Сәяхәт вакытында берничә сәгатькә Аран утрауларына тукталдык. Андагы җитез халык, бай туристларны җигүле атларга утыртып, утрау буенча экскурсиягә алып китте. Америка, Азия, Европа – Җир шарының төрле почмакларыннан җыелган халык, шул ат арбасына куана-куана утырып, бик бәхетле булып йөрде. Күбесе өчен экзотика! «Безнең авылда да шәп бизнес булыр иде бу», – дип уйлап куйдым...

Дублин һәм Корк – Ирландия башкаласы булыр өчен көрәшкән ике шәһәр. Туристик Дублин хәзер инде Европа шәһәрләренә ошап барса, Коркта туксанынчы еллар хәерчелеге әле дә күзгә бәрелә. Тик монда да туристларга карар урыннар шактый. Мәсәлән, Бларни сарае. 1446 елда салынган бу таш сарай бик яхшы сакланган. Биеклеге буенча алты катлы йортны хәтерләтә. Эченә керсәң, XV гасыр яшәешен күз алдына китерергә була. Бу сарайның иң югары катында «сүз осталыгы» ташын томалап калдырганнар. Тәмле телле буласың килсә, идәнгә ятып, башыңны кечкенә генә тәрәзәдән тышка чыгарырга кирәк. Ике ярдәмче бу вакыт сине, төшеп китмәсен дип, тотып тора. Тәрәзәдән башыңны чыгарасың да, шул тәрәзә ярыгында сакланган ташны үбәсең. Хезмәт түләүле.

Дублин янында да борынгы сарайлар, искиткеч диңгез ярлары җитәрлек. Әмма җиде кат ишеткәнче, бер кат барып күрүең барыбер хәерлерәк. Дублинны матур һәм бизәлгән килеш күрәсегез килсә, монда Раштуа яки Изге Патрик көннәрендә килергә кирәк. Соңгысында бар халык яшелдән киенеп парад карарга чыга. Кич белән алар пабларга, төнге клубларга таралышып бетә. Бөтен дөньяда бу бәйрәм, гадәттә, сыра эчүгә бер сәбәп кенә, шуңа күрә мин аны ошатып бетермәм дип уйлаган идем. Ялгышканмын. Парад бик матур һәм мәгънәле иде: милли хәзинәләре белән чын-чынлап горурланган кешеләрне дә байтак очраттым. Бу көнне генә булса да ирландиялеләр кельт телендә сөйләшергә тырышты. Яхшы адым, минемчә.

Кельт телендә Ирландиядә нибары ике процент кеше генә сөйләшә. Дублинда туып-үскәннәр телне бөтенләй белми диярлек. Кайберләре миңа үз телләрен белергә теләмәүләре, «бигрәк гади» дип фамилияләреннән оялулары һәм бабаларының итальян булуын ассызыклаулары белән Казандагы кайбер танышларымны хәтерләтте.

Белмим, әллә яшел төс һәм бәрәңге яраткангамы, сөтле чәйгә мөкиббән киткәнгәме, охшаш тарих тәэсиреме, татарлар белән ирландларны ниндидер бер уртак хис-тойгылар бәйлидер кебек тоелды миңа. Ышанмыйсызмы? Сез аларның милли көйләрен генә тыңлап карагыз. Ә иң яхшысы – барып үзегез күреп кайтыгыз.

Нәрсә алып кайтырга:

- Ireland дип язылган толстовкалар. Киеп йөрергә менә дигән;
- God father's shirt дип исемләнгән җитен күлмәкләр;
- матур итеп тегелгән курчаклар;
- алып кайтмасагыз да, тозлы майларын (атланмай турында сүз бара) татып карагыз.

«ХАТЫН-КЫЗНЫ ГАФУ ИТӘРГӘ КИРӘК...»



Әнвәр НУРГАЛИЕВ, җырчы, Башкортстанның атказанган артисты; гаилә стажы – 20 ел; балалары – кызы Элина, улы Рафаэль.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Иң элек кыяфәт күзгә ташлана. Ләкин минем өчен хатын-кызда иң мөһиме – аның акылы. Матурлыгына уш китәрлек хатын-кызлар була, тик сөйләшә башласа, чибәрлеге юкка чыга. Гүзәл затларның көлүеннән дә аларның акыл дәрәҗәсен чамалау кыен түгел. Дөрес, кайбер чакларда хатын-кызларга «җиңел акыллы» тәэсире тудыру кулайрактыр да һәм ул кирәк тә. Тик урынына карап һәм чама белән генә. Бик төпле хатын-кызлар да була. Алар миңа әниләрне хәтерләтә. Ә була бар яктан килгән гүзәл затлар: Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне дә әзәзләп биргән. Алардан да чибәр хатын-кызлар юк инде... Шәхсән үземнең хатыным бик төпле кеше. Клублар, «девичник»лар дигән җирләрдә йөрү юк бездә. Аның өчен өй генә бар.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Нинди булуга карамастан, хатын-кызларны гафу итү зарур. Алар һәрвакыт бәхетле булырга тиеш. Алар бәхетле икән – без дә бәхетле. Ялгышмаган кеше юк. Ялгышларны төзәтә белергә кирәк. Мин гаиләмне дә, үземне дә идеаль дип әйтә алмыйм. Камиллеккә чикләр юк. Без камиллеккә ирешергә тырышучылар. Бәгырьне кисеп алырдай сүз әйткән хатын-кызларны да гафу итә белү кирәк ир-атка. Хатын-кыз хыянәте турында уйламыйм да, чөнки мин Иринага 200 процентка ышанам.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә якын, чөнки Иринада ике сыйфат та бар. Ул мине илһамландыра да, очынып китсәм, тиз генә җиргә дә тартып төшерә. Гүзәл затлар ир-атка илһам чыганагы булырга тиеш. Моның өчен аңа үзен-үзе караган, рухи яктан үскән ханым да, кирәк вакытта иренә идеяләр бирерлек хикмәт иясе булу да шарт. Шул вакытта гына кешелек алга таба барачак. Янында рухландыручы хатыны булганда ир-ат таулар күчерә ала. Ул моның өчен көч тә, җай да табачак. Кызганыч, хәзер хатын-кыз доминант булган парлар бик күп. Урамга чыгып карасагыз да күрергә була: хатыны ялт итеп киенгән, ә ире көн саен бер чалбардан, шул бер үк курткадан. Дөрес, ул чиста, пөхтә йөри. Тик хатыныныкы кебек 105 күлмәге юк инде. «Сиңа кием нәрсәгә, кызлар каратырга җыенасыңмы әллә?» – дип әйткән хатыннар барлыгын да беләм. Бу – ир-атның хатыны янындагы ролен ачып сала торган гади генә бер мисал. Әлеге ханым янындагы ир көчле зат була алыр микән, ай-һай... Әгәр хатын-кыз, мәми булып, тыңлаучан бала кебек иренең авызына гына карап торса да, гафу итегез, бу инде гаилә түгел – колбиләүчелек. Безнең эштә, беләсез, вәсвәсәләргә бирелергә җай чыгып кына тора. Хатын да куләгә кебек йөрсә, ике дә уйламый уҗымга чыгып китәсең. Тик ярату, бигрәк тә аңа карата хөрмәт әлеге адымны ясарга юл куймый.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Берсүзсез! Бар шундый серләр, аны инәйгә кайтып сөйләп булмый, аңа авыр булачак, дусларга да бар серне ачып бетерергә ярамый – дошманга әйләнүләре бар. Иң якын дустым – хатыным. Элек, танылу казанмаган чорда, ул һәрвакыт, барысы да яхшы булачак, син тырышачаксың, булдырачаксың, дип әйтә торган иде. Минем күңел төшкән вакытларда да аның ышанычы өзелмәде. Үз гомеремдә ике мәртәбә депрессия кичердем. Берсе узган ел булды... Бик авыр үткәрдем. Бу халәттән үзенең киңәшләре белән хатыным алып чыга алды. Башка хатын-кызлар колагына да әйтәм: 40–45 яшь – ир-атлар өчен иң авыр чор. Бу вакытта ирегезгә берүк бик игътибарлы булыгыз!

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Без тулай торак ишек төбендә танышкан идек. Минем армиядән кайткан чак. Иринаны күрдем дә, аннан калмадым инде... Гашыйк булам икән, башымны югалтам, бер генә кешене яратам. Ул читтән торып институтта укый иде. Әтисе аңа Бөредән эш тапкан. Шунда китәм

ди. Беләм, хәзер аерылышабыз икән, аны югалтачакмын. Гаилә корырга акча да, торыр җир дә юк иде... Уфа урамы буйлап Иринага эш эзләп киттем. Очраган һәр кибеткә кереп эш урыны белешәм. Йөри торгач таптым бит! Үзем яшәгән тулай торак янындагы кибеткә сатучы итеп урнаштырдым. Һәм гел аның янында булдым. Җәй көне каникулга авылга да кайтмыйча аны саклап яттым, имеш, беркемгә дә бирмим. Ирина бик чибәр, гел егетләр бәйләнә иде. Яшьлек бит, аның өчен сугышып беткән чаклар да булды. Биш ел буе шулай саклап кына йөрдем. Ялган сөйләп утырмыйм, дөресен әйтәм, ничек тәкъдим ясаганымны хәтерләмим. Мин аңа хәтта балдак та алып бирә алмадым. Ул чорларда акчасызлык җанга үткән иде. Тормышны кашык-чәнечкедән башлаган кешеләр без. Романтика турында уйларга мөмкинлек юк иде.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Бәлки... Тик минем очракта алай түгел. Әнием бөтенләй башкача. Гаилә дилбегәсе аның кулында. Безнең әти күпме акча эшләгәнен дә белми иде. Әни нәрсә әйтсә, әти шуны эшләде. Әле дә шулай. Әни бик тыйнак, гаиләдә аның баш булганын читләр белмәгәндер дә әле. Хәзер сезгә сөйләгәндә уйлап куйдым: бездә дә шулайрак бугай инде. Мин – акча табучы, тормышны Ирина алып бара. Тик соңгы сүз, гаилә башлыгы буларак – минеке.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Гаилә корганда мин студент идем, хатыным эшләде. Сатучыдан кибет директорына кадәр күтәрелде. Хатынның күбрәк акча табуы ир-ат өчен бик начар: йә башыңны сантыйга салырга, йә бик түзем булырга кирәк. Гаиләдә ир хатыннан түбән булырга тиеш түгел. Берничек тә! Акча мәсьәләсендә генә түгел. Белем буенча да. Хатының югары белемле икән, синеке аннан да югарырак булырга тиеш. Икенче бала туганнан соң хатынымны эшләтмәдем инде. Гаиләне туйдырыр өчен үземә кем генә булып эшләргә туры килмәде: ишегалды себерүче, каравылчы, слесарь, балта остасы... Әйе, альфонслар да бар, тик мин гаиләдә малны ир табарга тиеш дип саныйм. Ничек кенә булмасын, ир-ат лидер булырга тиеш.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мин аны хатын-кызлар өчен түбәнчелек дип саныйм. Юашрак ирләр дә бар бит әле дөньяда. Алар сүз башларга кыенсынып торганда, нигә әле хатын-кызга беренче адым ясамаска?! Ике арада мәхәббәт булганда аның бер начарлыгы да юк.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Ирлеге дип уйлыйм. Дөнья куа торган, сүзендә тора белгән көчле затлар хакында сүзем. Хатын-кызга аның янында уңайлы икән, димәк, ир-ат аны бәхетле итәчәк. Үзен яклаган итеп тою өчен гүзәл зат янәшәсендә инициативалы ир-ат булуы шарт.

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Мине иң элек ир-ат итеп кабул итсеннәр иде. Юкса җырчы гына итеп күрәләр. Ир-атның асылы да бит чын ир булуында.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Чибәрлек – алдагыч ул. Кайберәүләр хыянәт итәр дип курка. Чөнки чибәрләргә кызыгалар. Әмма чибәрлек чагыштырмача төшенчә бит. Төрле ир-ат аны төрлечә кабул итә. Кем өчендер матур булган хатын-кыз башкалар өчен ямьсез тоелырга мөмкин. Минем өчен ямьсез хатын-кызлар юк. Дөрес, салкын чибәрләр бар. Хатын-кыз җылы, нәфис булсын инде ул.

12 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Никах күктә укыла диләр бит. Аллаһы Тәгалә үз парларыбыз белән очраштырып кавыштыра. Һәм яшияши бер-беребезгә охшап бетеп, барбөтенгә әвереләбез. Дөрес, мантыйк кушылмый. Ул төрлечә булып кала. Минем фикеремчә, ир-ат берничә адымга алга карап яши, ә хатын-кыз офыкка кадәрен генә күрә, ә аның артында нәрсә булганы хакында уйланмый. Хатын-кызның рульдә барган килеш телефонында хәбәр язганын аңлый алмыйм. Юл фаҗигасенә китерергә мөмкин бит. Ә ул уйламый бу хакта. Куркыныч очрак туса, хатын-кыз рульне ташлап, тизрәк битен каплый. Монысы бөтенләй башка сыймый торган хәл. Гаепләп тә булмый, табигатьләре шундый. Бик эмоциональ алар. Шундый булулары белән үзләренә каратып тоталар да.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Минем тормышта алай булганы юк. Соң кайткан чаклар бар. Булган ризыкны суыткычтан алам да җылытып ашыйм. Җылытырга да булмасамы? Йомырка пешереп ашый беләм ич мин. Аннан, хәзер бит нинди генә кафе-рестораннар юк!

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Минем иң ачуны китергән нәрсә инде бу. Тыныч кына кабул итә алмыйм моны. Машинага чыгып утырам да шалтырата башлыйм, кычкыртам. Минем мәрхүм бабай, Ириналар озаграк җыенсалар, машинасына утырган да китеп бара торган булган. Соңга калучылар автобуска чыккан. Мин алай ук булдыра алмыйм. Тик соңгы чиккә җиткерсәләр... Кайвакыт ашыктырам-ашыктырам да үзем соңга калам. Андый хәлләр дә булгалый.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Бүләк бирешеп яшибез дип әйтә алмыйм. Чәчәкләр биреп тә кинәндермим. Дөрес, ачуланышкан вакытта чәчәк күтәреп кайткалаганым бар. Ирина да бүләкне истәлекле даталарга гына бирә. Бездә шулай кабул ителгән инде. Һәм алар барысы да алдан сөйләшенеп алынган кирәкле әйберләр. Без – авыл балалары: күктә очмыйбыз, җирдән йөрибез.

Талчыгу нәрсәгә китерә



Балаларның, арыдым, дип зарлануын күпләр җитдигә алмый. «Нинди ару ди бу яшьтә. Арысаң, ятып тор», – дибез дә, бетерәбез. Ә бит йончуның һәм хәлсезлекнең сәбәбе вегетатив дисфункция булырга мөмкин, ди балалар кардиологы, Республика балалар клиник хастаханәсенең 2 нче поликлиникасындагы кардиология бүлеге табибы Ләйсән АЛИУЛЛИНА.

Үзәк һәм периферия нерв системасының йөрәк, кан тамырлары, эчке органнар, эчке секреция бизләре эшчәнлеген көйләүче бүлегендәге тайпылышларга вегетатив дисфункция синдромы дип әйтәләр.

Аның сәбәпләре күп булырга мөмкин. Бу – нерв системасының органик зарарлануы, акыл һәм физик көчәнеш аркасында килеп чыккан неврозлар, баланың рухи үзенчәлеге, акыл ягыннан һәм физик яктан бик көчле ару, аз хәрәкәтләнү, гормоннарның тиешенчә булмавы (бигрәк тә яшүсмерлек чорында), кискен яки дәвамлы чирләр белән авыру, балада яман гадәтләр күзәтелү...

Вегетатив тамыр дистониясе балада бер яшь тулганчы ук башланырга мөмкин. Бу аның карындагы үсеше бозылу, туганда алган имгәнүләре сәбәпле килеп чыга. Әгәр дә нарасыйның бик еш эче авырта, аппетиты юк, йокысы начар, тәрәте бозыла һәм ашаганын еш кына кикереп чыгара икән, болар вегетатив дистониянең чагылышы булырга мөмкин.

4-5 яшьлек балаларда исә ул күңел халәтенең еш һәм кинәт үзгәрүчәнлеге, балалар бакчасына яки түгәрәкләргә йөрүдән баш тарту, еш салкын тию, күңел төшенкелеге, йоклаганда бәвел тотмау, тын бетү, тиз ару кебек билгеләр белән уза.

6-8 яшьләрендә вегетатив тамыр дистониясе баланың тормышындагы яңа этап – мәктәп чоры башлану белән аңлатыла. Көндәлек режимның үзгәрүе, яңа коллективка ияләнү, яңа вазыйфалар, акыл эшчәнлеге аркасында барлыкка килгән талчыгу эчке органнарның эшчәнлегенә зыян китерергә мөмкин. Кече яшьтәгеләрдәге кебек үк, бу очракта да ару, хәлсезлек, күңел төшенкелеге, йөзнең агарынуы, тиз туңу һәм тиз эсселәү, тын бетү кебек билгеләр күзәтелә.

Әлеге синдром бигрәк тә яшүсмерләрдә еш очрый. Бу организмда гормоннар үзгәреше белән бәйле рәвештә килеп чыга. Гормональ фон үзгәрә, ә рухи-эмоциональ һәм физик үсеш әле тиешенчә түгел. Мәктәптәге нагрузка, дәресләрнең күплеге, йокы туймау, баланың аз хәрәкәтләнүе, саф һавада сирәк булу, негатив мәгълүмат күплеге (көчләү, үтереш), яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр каршылыгы кебек факторлар да әлеге патологияне көчәйтә.

Әгәр дә балагызда әлеге билгеләрнең берничәсен генә сизсәгез дә, педиатрга мөрәҗәгать итүне кичектермәгез. Анализлар һәм тикшеренүләр нәтиҗәсенә карап, тиешле дәва билгеләнә. Әлеге чирне ачыклауда һәм дәвалауда бер генә түгел, ә берничә белгеч катнаша. Диагнозны ачыклау өчен дә комплекслы чаралар кулланыла: ЭКГ, йөрәккә УЗИ, СМАД, ХОЛТЕР ЭКГ, кан анализы, канны гормоннарга тикшертү, калкансыман бизне, баш миендәге кан тамырларын ультратавыш белән тикшерү, кайчагында МРТ һәм вегетатив пробалар үткәрү дә кирәк булырга мөмкин.

Вегетатив тамыр дистониясе, нигездә, даруларсыз дәвалана.


- Иң элек баланың дөрес һәм тиешенчә туклануы мөһим;
- физик нагрузкалар баланың сәламәтлегенә тәңгәл килерлек булсын;
- гел дәресләр белән мавыгып яки компьютер каршында утырып, баланың саф һавада булуы чикләнмәсен;
- көндәлек режимны саклауның мөһимлеген дә истән чыгармагыз;
- стресслы ситуацияләрне бетерү, баланың чамасыз аруына юл куймау бик әһәмиятле;
- физиотерапия, массаж, электросон, ароматерапия, энә кадап дәвалау да баланың хәлен җиңеләйтә;
- гаиләдәге җылы һәм дустанә мөнәсәбәтләр – болар бар да дәвалауның нигезләре!

Фитотерапия исә тынычландыручы һәм стимуллаштыручы чаралардан тора.

Табиб киңәше

- баланың аруын, хәлсезлеген, баш авыртуын, күңел төшенкелеген, сәбәпсез һәм даими куркуын игътибарсыз калдырмагыз;
- физик һәм акыл эшчәнлеге кирәгенчә ял һәм саф һавада йөрү белән чиратлашырга тиеш;
- үсүче организмга дөрес һәм тиешенчә туклануның никадәр мөһим булуын да онытмагыз.

Тавышың бетсә



Тавыш бетү яки халык телендә «казтамак» дип йөртелгән бу чир белән үз гомерендә бер тапкыр булса да һәркайсыбыз очраша. Әллә ни сызлану сизелмәсә дә, гаять зур уңайсызлык тудыра ул. Беркем белән сөйләшә алмавың, хәтта телефонга җавап биреп булмавы да борчылырга мәҗбүр итә. Тавыш бетүнең сәбәпләре һәм аны дәвалау ысуллары турында Казандагы 16 нчы клиник хастаханәнең лор-үзәге мөдире Екатерина ЛАПТЕВА белән сөйләшәбез.

Тавыш карлыгуы медицина телендә дисфония, ә аның бөтенләй бетүе афония дип атала. Ул кискен яки дәвамлы ларингит – бугаз һәм тавыш ярыларының ялкынсынуы аркасында килеп чыга.

Сәбәпләре күптөрле. Тавыш – көчле стресс кичерү яки тавыш ярыларына көч килү аркасында да бетәргә мөмкин. Монысы бигрәк тә артистларга һәм укытучыларга хас. Стресс сәбәпче булса, тавыш кинәт югала.

Икенче бер сәбәп һәм ул иң еш күзәтелгәне дә – вируслы ялкынсыну. Бу очракта башта тамак авырта, ютәл башлана, тавыш акрынлап карлыга, дәваламасаң, бөтенләй дә бетәргә мөмкин. Тавыш югалу тамактагы шешләр аркасында да булырга мөмкин. Тәмәке тарту да тавыш ярыларының ялкынсынуына китерә. Еш күзәтелә торган тагын бер сәбәп – аллергия.

Тавыш бетү – кичекмәстән табиб-отоларингологка күренүне сорый торган чир. Ялкынсыну процессы аркасында тавыш югалып кына калмыйча, шешенкелек көчәеп, тын юллары бөтенләй капланырга мөмкин.

Тамаклары авыртса, күпләр пышылдап сөйләшүгә күчә. Бу – иң зур хатаның берсе. Болай эшләргә ярамый. Пышылдап сөйләшкәндә тавыш ярыларына басым көчәя генә. Сөйләшми калу мөмкин булмаганда, киресенчә, кычкырып сөйләшергә тырышырга кирәк.

Дәвалау ысуллары комплекслы билгеләнә. Беренчедән, чирнең бик кискен чорында тавыш ярыларына көч китермәскә тырышырга кирәк. Салкын һәм артык кайнар ризыклар куллanудан тыелу да бик мөһим. Тозлы, кырку, ачы, маринадланган, каты ризыклар ялкынсынуны көчәйтә генә.

Дару препаратларына килгәндә, әлбәттә, аларны табиб билгели. Беренче чиратта бу – тамакны физраствор яки гормональ препаратлар белән чайкату. Кайсысын куллану авыруның ни сәбәпле килеп чыкканына бәйле. Шулай ук антигистамин препаратлар да билгеләнә. Болары шешне бетерү өчен кирәк. Вируслы ялкынсыну булган очракта табиб антибиотиклар да билгеләргә мөмкин.

Тавыш бетүне җитди чиргә санамыйча, дәваламыйча калдырырга ярамый. Кискен формадан даими формага күчеп, кешенең тавышы бик озакка бетәргә мөмкин. Дәва дөрес һәм вакытында билгеләнсә, ларингит катлауланурларсыз атнаун көн дигәндә бетеп тә китә.

Профилактика чараларының иң беренчесе һәм иң мөһиме: тавыш ярыларын көч килүдән саклау. Салкын ризыклар белән сак булырга кирәген дә һәркем белә. Һәртөрле салкын тиюләрдән, вируслы инфекцияләрдән саклану, иммунитетны ныгыту – иң үтемле профилактика чарасы.

Тавыш ярыларының торышына умырткалыкның муен өлешендәге остеохондроз да тәэсир итә. Җиңелчә массаж, гимнастика – болар бар да организмның гомуми халәтен яхшыртырга ярдәм итә.

Тавыш карлыгуын сизү белән, сөйләшүне чикләргә, җылы чәй яки җылы сөт, җылымса морс эчәргә кирәк. Температура югары булмаса, муенга җылы шарф урарга, спиртка су кушып, җылы компресс куярга мөмкин. Җылы эремә белән тамакны чайкау, аякларны җылы суда тотканнан соң, корытып, тиз генә йон оекбаш киеп кую – болар, әлбәттә, чирне дәваламый, ләкин хәлне сизелерлек җиңеләйтә.

Ә менә күпләр яраткан шифалы үләннәрне, балны кискен ларингит вакытында кулланырга ярамый. Болар шешне арттырачак кына.

Табиб киңәше

- артык кычкырып сөйләшү зыянлы булган кебек, озак пышылдап сөйләшү дә тавыш ярыларына көч китерә;
- ризык бик салкын да, бик кайнар да булмаска тиеш, тавыш ярыларына икесенең дә зыяны бар;
- ларингит булганда аллергия китереп чыгара торган ризыклардан, үлән төнәтмәләреннән тыелып торырга кирәк;
- температура югары булганда муенны җылытырга, компресслар куярга ярамый;
- кискен ларингит булганда кайнар мунчага, саунага керү тыела.

Превентив медицина дигән сүзне ишеткәнегез бар идеме? Булса да, мөгаен, бик сирәкләрнеңдер. Превентив медицина дип сәламәтлекне саклауга юнәлдерелгән индивидуаль чаралар комплексына әйтәләр. Ул – организмга молекуляр дәрәҗәдәге диагностика һәм даими мониторинг уздырып, төрле чирләрне әле башлангыч чорда ук (авыруның ниндидер билгеләре күренә башлаганчы) юк итүгә корылган медицина. Ике генә сүз белән әйткәндә, сез ниндидер чирдән дәваланмыйсыз, ә чирләмәс өчен алдан ук чараларын күреп куясыз. Медицинаның әлегә безнең өчен бөтенләй яңа төре хакында йогышлы чирләр, эпидемиология, гигиена һәм туклану өлкәсе белгече Резеда ЖУРАВЛЕВА белән сөйләшәбез.



Сәламәтлек серләре яки

нәрсә ул превентив медицина?

Превентив медицинаның фәлсәфәсе бүгенге традицион медицинаныкыннан бик нык аерыла. Хәзерге медицинаның, һәрхәлдә, аның «көнбатыш» (шул исәптән, бездәгесе дә) вариантының нигезендә сәламәтлекне саклау түгел, ә аны «ремонтлау» принцибы ята.

Француз хирургы Рене Лериш (1879–1955) сүзләренчә, «чир ул – ике күренешле драма. Беренче күренеш озын: дөм караңгылыкта безнең органнарыбыз һәм тукымаларыбыз тынлыгында башкарыла, фәкать икенчесендә – кыска күренештә генә ниндидер сызлану һәм башка күзгә ташланырлык күренешләр барлыкка килә». Клиник симптомнар авыруның беренче билгеләре түгел. Хроник чир ул акрынлык белән барлыкка килә һәм баштагы мәлдә берничек тә беленми. Ләкин молекуляр дәрәҗәдә инде үзгәрешләр башланган була. Менә шул стадиядә чирне әле җиңәргә яки аның организмга зур зыян салмавына ирешергә мөмкин.

Элек-электән сәламәт яшәү рәвеше алып баруда һәм сәламәтлекне саклауда рациональ туклану беренче урында торган.

Ашау-эчү мәсьәләсендә кеше «үзенә-үзе хуҗа» дип әйтергә була. Аңа монда нәрсә эшләсә дә ирек. Үзебез керткән гадәтләр, ниндидер ризыкка өстенлек бирүебез, матди мөмкинлекләребезгә бәйле рәвештә («Мин бу әйберне алып ашый алам!») еш кына бу өлкәдә чаманы да югалткалыйбыз. Дөресен генә әйткәндә, ризык кайберәүләр өчен бердәнбер шатлык чыганагы ролен башкара. Сүз дә юк, ашау кешегә ләззәт хисе бирергә тиеш. Әмма бер зур гына «ләкин» бар. Әлеге «ләкин» белән килешмәвебез өчен кайчак бик кыйммәт түләргә туры килгәли.

Гиппократ үзенең трифология буенча язган хезмәтләрендә: «дару ризык булырга түгел, ә ризык үзе дару булырга тиеш», дигән.

Рациональ туклану ул – аңлы рәвештә төрле ризыкларны билгеле бер нисбәттә куллану гадәте. Кеше организмы йөзләрчә триллион тере күзәнәкләрдән тора һәм ашаган ризыгыбыз шушы күзәнәкләрнең сыйфатына тәэсир итми калмый.

Бүгенге кеше узган гасыр ахырындагылардан үзгәчә туклана. Хәтта ризыкны өйдә үзебез әзерләсәк тә, ингредиентларның сыйфаты инде башка.

Итне консервланган азык ашатып үстергән терлектән алабыз, ябык бассейннарда үстерелгән балык та диңгез суүсемнәре һәм вак балык белән тукланмый, йомырка һәм кош ите махсус үсеш стимуляторлары белән үстерелгән тавыкныкы... Болар бар да ризыкның азык кыйммәтенә һәм ахыр чиктә безнең күзәнәкләргә, тукымаларга турыдан-туры тәэсир итә. Ризыкның азык кыйммәте дигәндә, без кеше организмында синтезлаша алмаган, фәкать ризык белән генә кергән һәм шул ук вакытта күзәнәк дәрәҗәсендә мөһим роль уйнаган туклыклы матдәләрне күздә тотабыз. Алар шулай атала да: алыштыргысыз политуендырылмаган май кислоталары (незаменимые полиненасыщенные жирные кислоты). Уңайлылык өчен аларны омега 3 һәм омега 6 дип атап йөртәләр.



Резеда ЖУРАВЛЕВА:
– Тиздән бар да үзгәрер дигән өмет бар. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 2018 елның 24 апрелендә кабул ителгән «Предиктив-превентив һәм персонализацияләнгән медицина концепциясен раслау турында»гы 186 нчы санлы карары медицинаны бөтенләй башка юнәлешкә таба борырга вакыт җиткәнлегенә ишарәли.

Узган гасыр ахырында ук Вашингтонның Генетика, туклану һәм сәламәтлек үзәге галимнәре омега 3 һәм омега 6 арасындагы дисбаланс күзәнәкнең ялкынсынуына китерүен ачыклаган. Күзәнәкнең ялкынсынуы, үз чиратында, хроник чирләрне кузгатып җибәрүче «пусковой механизм» ролен үти. Әлеге ачыш шул заман медицинасы тарафыннан җитди кабул ителми, чөнки туклану мәсьәләсе әле ул вакытта бу кадәр үк кискен тормый. Әлеге нисбәт 1 гә 1 булырга тиеш (бу идеаль булганда). 1:4 яки 1:5 нисбәте инде проблема башлануын күрсәтә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы биргән статистика мәгълүматлары буенча бүген европалыларның 95 процентында әлеге нисбәт 1:13 күрсәткечендә. Моның сәбәпчесе: ризыгыбызда омега 6 май кислоталарының артык күплеге. Глобаль индустрияләштерүнең һәр аспекты иммун системабызга тәэсир итеп, аны өстәмә активлыкка этәрә. Шуның аркасында берөзлексез үзгә молекулалар барлыкка килеп, күзәнәкнең ялкынсынуын китереп чыгара. Әлеге дисбалансны капларга омега 3 май кислоталары җитешми.

Инновацион компанияләр тәкъдим иткән биологик актив өстәмәләрнең дә, төрле диеталарның, спортны популярлаштыруның да чирләрне киметмәве, киресенчә, һәртөрле авыруларның артуы һәм «яшәрүе» әнә шуның белән аңлатыла да.

«Ә ул нисбәтнең торышы Россиядә ничек соң?» диярсез. Кызганыч, әлегә берничек тә түгел. Бездә организмдагы омега 6 һәм омега 3 нисбәте әлегә бөтенләй тикшерелми. Югыйсә бу күрсәткечне белү кешенең хроник чирләр буенча кайсы хәвеф төркеменә керүен ачыкларга һәм анализ нәтиҗәләренә карап, чирне булдырмый калу өчен һәркемнең үзенә генә туры килүче чаралар билгеләргә мөмкинлек бирер иде.

Белмәсәң бел

ОМЕГА 6 МАЙ КИСЛОТАСЫНА БАЙ РИЗЫКЛАР

■ кыздырылмаган көнҗет, көнбагыш, кабак төше, чистартылмаган көнбагыш, кукуруз, соя, көнҗет майлары; эрбет, пестә (фисташка), җир (арахис) чикләвекләре; арыш, бодай, арпа, ясмык, нут; йомырка; үпкә-бавыр; авокадо; диңгез балыгы.

■ **ОМЕГА 3 МАЙ КИСЛОТАСЫНА БАЙ РИЗЫКЛАР**

җитен мае һәм орлыгы, чиа, киндер орлыгы; әстерхан чикләвеге, соя; сардина, скумбрия, сельдь, сөләйман балыклары, тәрәч (треска) бавыры; устрицалар, суүсемнәр. Әмма канның молекуляр анализыннан күренгәнчә, чикләвек һәм балык кебек ризыклар гына организмдагы омега 3 дисбалансын тулысынча үзгәртә алмый. Моның сәбәбе – күпчелек балыкның ясалма җим белән үстерелүендә.

Фото: www. pixabay.com



Авар хинкале

Дагстан – Россиянең иң күп милләтле төбәге. Гомер бакый шушында көн күрүче милләтләр саны рәсми рәвештә ундүрт дип саналса да, чынлыкта монда утыздан артык кавем яши. Милләтләре төрле булса да, барысын да бер сүз берләштерә, алар – дагстанлылар! Бу сүздә чиксез горурлык та, ватанпәрвәрлек тә, гаярьлек тә! Гаилә традицияләренә, дини йолаларга, ата-бабага хөрмәт, хатын-кызга ихтирам, ир-атны олылау – аларны аерып күрсәтә торган төп сыйфатлар. Дагстанда кызларны әле дә күп гаиләләр фәкать яучылап кына кияүгә бирә. Бүгенге кунагыбыз Җәмилә ханым да ире Ренат белән туйга кадәр очрашып йөрмәгән. «Әгәр сиңа ошамаса?» – дип гаҗәпләнүебезгә каршы: «Ир-егет өчен матурлык түгел, гаиләне тота белүе мөһим. Әти-әнием мине аңа бирергә тели икән, димәк, бу кеше чынлап та миңа лаек», – ди ул. Кызлы гаилә барламый кияүләрне, егетнең әти-әнисе балалары әле кечкенә чакта ук кайсы нәселдә нинди кыз үскәнен күз уңыннан ычкындырмый. Ә нинди туйлар уза аларда! Кунаклар саны меңәр кешегә җитә. Аптырамагыз, җиде буынга кадәр якын туган санала, берсен дә калдырырга ярамый. Шуңа да өчәр көн бәйрәм итәләр. Ә туйдан соң шул ук төнне яшь кәләш иренең дусларын кайнар хинкал белән сыйлый. Грузиннарныкы белән бутый күрмәгез, дагстанлыларның хинкале бөтенләй башка. Шәһәр тирәсендә яшәүчеләр юка хинкалне үз итсә, авыл җирендә – тауларда яшәүчеләр туклыклы да, тәмле дә, йомшак та булган авар хинкален ярата. Әмма аны чын осталар гына әзерли белә. Дагстан кызы Җәмилә РӨСТӘМОВА үз серләрен безнең белән дә бүлешергә риза булды.



Фото: Анна Арахамия

Кирәк:
- бер кисәк ит (гаиләнең зурлыгына карап аласыз);
- 2 баш эре суган;
- 1 кг он;
- 1 чәй кашыгы тоз;
- 1 чәй кашыгы сода;
- 800 г кефир (1% майлылыктагы);
- 100 г атланмай;
- 3 аш кашыгы томат пастасы;
- чак кына үсемлек мае;
- 2 тырнак сарымсак.

Эш барышы:

■ Иттән шулпа кайнатабыз. Аңа бер баш суган һәм түбәнчә тоз салабыз.

■ Тирән эчле савытка онны иләп, уртасын чокырлыйбыз. Шунда бер чәй кашыгы тоз белән бер чәй кашыгы соданы салып бутыйбыз. Кефирны чокырның уртасына акрынлап кына агыза-агыза, он белән туглыйбыз. Камырны үзләнгәнче басып, 20 минутка өстен каплап торабыз.

■ Ит әзер булгач, шулпаны сөзәбез. Аның беразын калдырып торабыз.

■ Зур, иркен кәстрүлгә бер өлеш шулпа, ике өлеш су салып, кабаттан кайнатырга куябыз. Майлы шулпада гына пешерсәң, хинкал күперми – бу беренче сере.

■ Камырны кунага салып, бер бармак калынлыгында җәябез. Җәемне турыпочмак рәвешенә кертеп, 5 кә 5 см тирәсе зурлыгындагы шакмакларга кисәбез.

■ Кайнап торган шулпага шушы шакмакларны салып (барысын да берьюлы салмагыз, өлешләп пешерегез), өскә йөзеп чыккач, әйләндерәбез һәм капкач белән томалап, 8 минут пешерәбез.


■ Пешкән хинкалне шулпадан алуга ук, суши таягы белән берничә урыннан тишкәлибез. Моны бик тиз эшләргә кирәк, югыйсә хинкал сорылана һәм ялпаклана – монысы икенче сере.

■ Бер баш суганны блендерда ваклап, атланмайда кыздырабыз, аз гына үсемлек мае да кушарга була. Суган кызаргач, 3 аш кашыгы томат пастасы салабыз, ярты аш кашыгы он өстибез, Томат кызгач, 1 стакан шулпа кушып, кайнатып чыгарабыз. Сүндерер алдыннан гына издерелгән сарымсакны салабыз, кирәк булса, тоз сибәбез.

■ Дагстанлылар хинкалне табынга уртак тәлинкә белән чыгара. Ит аерым тәлинкәдә бирелә. Зур бер касәгә салып соус куела. Шулпаны исә һәркемгә аерым касәгә салып бирәләр. Теләсәгез, хинкалне дә һәркемгә аерым тәлинкәдә бирә аласыз.

■ Авар хинкален кайнар килеш кул белән алып, соуска манып ашыйлар. Суынып китсә, төбенә аз гына шулпа салынган казанда җылытып алырга кирәк. Микродулкынлы мичкә тыксаң, хинкал катып китә. Ашларыгыз тәмле булсын!

Мастер-классны оештыруда ярдәм иткәннәре өчен Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.



Яңа уку елы башланганын истә тотып, бу юлы балаларыгыз, үзегез өчен дә файдалы һәм туклыклы солы коймагы рецептын бирергә уйладык. Менә дигән иртәнге аш ул. Гадәттә, мондый коймакны эре бөртекле солы лачавы белән йомыркадан әзерлиләр. Ә Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА аны солы көрпәсеннән әзерләргә тәкъдим итә.

Зифаларга – солы коймагы

Солы көрпәсе – бөртекне эшкәрткәннән калган кабык ул. Элек көрпә кушып пешергән икмәк ярлылар ризыгы гына булып саналган. Ләкин XX гасыр диетологлары аның никадәр файдалы һәм кыйммәтле булуын ачыклады инде.

Башка бөртекләләр белән чагыштырганда, солы көрпәсе иң файдалысы. Ул A, F, D, C, H һәм B төркеменә кергән витаминнарга бай; калий, йод, күкерт, магний, фосфор, кальций, тимер, хлор, бакыр, цинк, бор – болар солы көрпәсендә булган микроэлементларның барысы да түгел әле.

Солы көрпәсе тупас җепселле булганга, ул эшкәртелми. Эчкә кергәч, бүртеп, үзенә барлык токсиннарны, шлакларны сеңдерә һәм шушы сыйфаты белән эчәклекне дә бик шәп чистарта.

Коймагыбызны менә шундый файдалы ризыктан әзерләрбез дә.

Кирәк:

- 50 г көрпә (көнлек норма – 30–50 г);
- 130 г су яки сөт;
- 1 йомырка;
- бераз гына тоз.

Эш барышы:

■ Көрпәне 5 минутка суга яки сөткә салып бүрттерәбез. Шушы вакыт эчендә ул куерып, тыгызланып китәргә тиеш. Аннары бер йомырка өстәп, яхшылап туглыйбыз. Шушы күләмнән ике зур коймак чыга. Коймакны аз гына май салынган табада кыздырабыз.

Эчлекнең төрлесен әзерләргә була – баллысын да, тозлысын да. Без сезгә берничә вариант тәкъдим итәбез:

■ кызыл балык белән эремчекле сырдан әзерләнгән эчлек тә бик тәмле була;

■ сырны уып, кайнар коймак өстенә салабыз да икенчесе белән каплыйбыз. Коймакны табада җиңелчә генә кыздырып алсаң, сыр йомшабрак китә;

■ балык белән авокадо;

■ шикәрсез арахис пастасы белән банан;

■ эремчек һәм үзегез яраткан берәр төрле җиләк-җимештән әзерләнгән эчлек тә ошамый калмас.

Ашларыгыз тәмле дә, сихәтле дә булсын!

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Кучкар. Үзегезне штормга эләккән корабль капитаны итеп тоярсыз. Бер-бер артлы алышынып торган вакыйгаларны йөгәнләр өчен, карарларны бик тиз кабул итәргә туры килер. Бу айда бары тик үзегезгә генә ышаныгыз.

Үгезбозау. Бераз күңел төшенкелеге булырга мөмкин. Нәрсәгәдер ирешер өчен дүрт тапкыр күбрәк көч түгәргә туры килер. Әмма тормышка башкачарак карарга тырышыгыз әле: «стакан яртылаш тулы бит».

Игезәкләр. Сабырлыкта сыналырсыз. Эштә ниндидер көтелмәгән хәл килеп чыгуы бар. Шуңа да мәгълүматларга игътибарлы булыгыз, барысын да җентекләп тикшерегез, уйламыйча эшләмәгез.

Кысла. Кемнеңдер йогынтысын тоярсыз. Эшегезгә, шәхси тормышыгызга тыкшынырга теләүчеләр бар кебек – уяу булыгыз. Акча белән бәйле мәсьәләләрдә игътибарны арттырыгыз, банк карталарын җыебрак йөртегез.

Арыслан. Алда җитди карарлар һәм зур эшләр тора. Моңарчы тыныч кына эшләп килгән схеманы үзгәртергә туры килер. Бүген бу күңелне борчыса да, ахыры хәерле булачак.

Сөмбелә. Узган айның тискәре энергиясе берникадәр сизелер әле. Бу чорны сабырлык белән уздырып җибәрергә кирәк. Нәрсәнедер үзгәртү өчен кулай вакыт түгел. Ай уртасыннан хәлләр җайланачак.

Бизмән. Үзегезне көрәш кырында кебек хис итәрсез. Идеяләрегез күп, ләкин аларны тормышка ашыру өчен шактый көч сорала. Яңа танышларыгыз белән саграк булыгыз, карталарны ачарга ашыкмагыз.

Чаян. Киләчәккә планнар кору, аны тормышка ашыру юлларын эзли торган вакыт. Актив эшчәнлекне бераз кичектерегез. Мөһим эшләрне дә бу айга планлаштырмый торсагыз яхшы – айның энергиясен уңай дип булмый.

Укчы. Яшәү көчегезнең бераз артуын тоярсыз, югыйсә соңгы вакытларда бигрәк йончыган идегез. Көч алу белән, яңа идеяләр туар. Сез активлык чорына керәсез, мөмкинлекләрне ычкындырмагыз, уҗәтрәк булыгыз.

Кәҗәмөгез. Иҗади активлык уянган чор. Интеллектуаль даирәдә эшләүчеләрне зур күләмле ниндидер кызыклы эш көтә. Билгеле, әҗере дә куандырыр – хыялыгыздагы әйбергә ия булырсыз.

Сукояр. Гаять үзгәрүчән, мәшәкатьле ай. Фикерегезгә аяк чалучылар булыр. Хаклы булуыгызга инансагыз, үз сүзегездә нык торыгыз. Зур планнар корыр өчен яхшы вакыт түгел.

Балык. Идеяләрегез күп, ләкин аларны хәзер генә тормышка ашырып булмастыр. Уйларыгызны берәүгә дә белдерми торыгыз. Бу ай ниндидер көтелмәгән керем яки зур бүләк белән куандырмагае әле!

зирәк кешедән зирәк сүз

ХЫЯЛ БАСКЫЧЛАРЫ

Бер малайның бик зур хыялы булган – дөньядагы иң биек тау түбәсенә басып, җир йөзенә күз саласы килгән аның. Зур тырышлыклар куеп, шушы тау итәгенә килеп җиткән ул. Хәзер инде иң соңгы эш – тауның үзенә генә менәсе калган. Ләкин ничек кенә тырышмасын, малай бер карыш та күтәрелә алмаган, текә кыялар аңа һич кенә дә бирешергә теләмәгән. Максаты бик якын да бит, аңа ирешү юллары гына табылмаган.

Аның аптырап торуын күргән бер карт, малайга кәйлә китереп биргән. «Нишләрмен соң мин бу кәйлә белән?» – дигән малай. «Чүкерсең», – дип җаваплаган карт. «Ничек итеп чүкергә, буем җитми бит?» «Ә син баштан ук югарыга үрелмә. Әүвәл аяк басарыңа урын әзерлә. Аннары өскәрәк үрелерсең», – дип киңәш биргән карт. Малай көннәр буе «тек-тек» таш ватуында булган. Ниһаять, текә кыяда малайның ике аягы гына сыярлык беренче баскыч барлыкка килән. Шуңа басып, ул икенче баскычны әзерләгән, аннары өченчесен, дүртенчесен… Бу аның бик күп вакытын, көчен алган, ләкин хыялы шулкадәр ымсындыргыч булган, ул арыса да, ялыкса да, эшен ташламаган – «тек тә тек» кыяны чүкегән. Көннәрдән бер көнне озак елларга сузылган хезмәтенең нәтиҗәсенә ирешкән – иң текә кыяның түбәсенә басып, җиргә кошлар очкан биеклектән күз салган.

Картның киңәше аңа кыяга менгәндә генә түгел, тәшкәндә дә булышкан. Кайчандыр ул чүкегән баскычларга басып, кыя-тауга инде башкалар да күтәрелгән. Шушы баскычларны уючыга алар рәхмәт укыган.

Кыйссаның мәгънәсен барыгыз да аңладыгыз инде. Текә кыя ул – белем дөньясы. Аны берьюлы колачлап булмый, шушы малай шикелле, бер баскычтан икенчесенә күтәрелеп кенә ирешәләр аңа. Һәм бу эш, әлбәттә, тәҗрибәле укытучы ярдәме белән генә мөмкин – аптырап торган малайга кәйлә биреп, аның белән нишләргә өйрәткән зирәк карт кебек.

* * *

Кытайга барып булса да, белем ал.

Татар халык мәкале.

Беркайчан да укымаганчы, соң булса да укуың яхшырак.

ЭЗОП (борынгы грек шагыйре).

Үз укытучысын узып китмәгән укучы кызганыч.

Леонардо да ВИНЧИ (итальян рәссамы, галим, уйлап табучы).

Үзеңнең никадәр аз белүеңне аңлар өчен бик күп укырга кирәк.

Мишель де МОНТЕЛЬ (француз язучысы, философ).

Үрнәксез бернәрсәгә дә өйрәнеп булмый.

Ян КОМЕНСКИЙ (чех педагогы).

Азны белер өчен күпне укырга кирәк.


Шарль де МОНТЕСКЬЁ (француз язучысы, философ).

Яшьлегендә укымаганның картлыгы күңелсез була.

ЕКАТЕРИНА II (Россия патшабикәсе).

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА





ХОЗУРЛЫК

Казакъстанның Караганда шәһәрендә яшәп иҗат итүче рәссам Фәния Исламованың картиналары Җирдәге яшәешкә мәхәббәт белән тулы: уйчан кешеләргә, җәйге агачларга, җилле яңгырларга, серле томаннарга... һәм аларда сурәтләнгән табигатьтә һәрчак үзенә бер нәфислек, ә менә бәндәләрнең гәүдә торышларында исә күп очракта дөнья гаменнән ераклык чагыла.

Яңа әсәрләрдә нинди төсләр булачагы һәм композициянең тулы камиллеге рәссам тарафыннан инде күптән чишелеп куелган: ул аларны җиңел һәм тиз арада яза. «Үз иҗатымда төсләрнең молекуляр калейдоскобы аша чиксезлеккә, формалар җуелырлык һәм бары тик чиста энергия генә калырлык дөньяларга барып җитәсем килә! Картиналарымны караучыларның күңелләрендә кабынган соклану хисе, аларның җаннарында туган чиста энергия әсәрләремне сафландыра һәм үземне дә куандыра бит!» – ди Фәния Якуб кызы.

Картиналарындагы композицияләр һәрчак феерия, гармония белән тулы. Киндерләрдәге тойгылы образлар әйтерсең лә ниндидер бер моңсулык белән һәрчак могҗиза тууын көтә. Үзенчәлекле мозаикага охшаш картиналарында рәссам махсус рәвештә гадиләштерү ысулын куллана. Әсәрләрдәге төс тапларының һәм һәрбер төсмер сызымының төгәл үз урыны бар.

1979 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлап, Карагандага кайтканнан бирле ирекле рәссам ул, һәм бары тик сынлы сәнгать белән генә шөгыльләнә. Җәмәгате, шулай ук сәләтле ирекле рәссам Фәрһад Исламов белән бергә талантлы балалар да тәрбияләп үстергән: Дамир, Аделаида һәм Уна – өчесе дә төпле фикерле, скрипкада уйныйлар, чит телләр беләләр, картиналар язалар, катлаулы уенчыклар ясыйлар, интерьерларның дизайн бизәлешләрен чишәләр, нәселдән килгән сәләтләрен тагын да көчәйтәләр.

Бу гаиләнең иҗаты Казакъстандагы сынлы сәнгать сөючеләргә яхшы таныш. Хезмәтләре күптән инде бу илнең иң абруйлы музейларын бизи.

Фәния Исламованың әсәрләре Бөекбритания, АКШ, Германия, Израиль, Кытай һәм Италиядәге шәхси тупланмаларда да саклана. «Татарстанда белем алдык, Казанга хәзер дә кайтабыз, балаларыбызның үзләрен профессиональ яктан шушы шәһәрдә табуларына шатланабыз», – ди Фәния ханым.

Бу рәссам иҗатындагы төп акцент кешеләр җанында якты, игелекле халәт тудырырга юнәлдерелгән, шуңа күрә аның теләсә кайсы бина диварларын бизәрлек әсәрләре карап туйгысыз, беркайчан ялыктырмый, тамашачы күңелен яулавын дәвам итә. «Әниебез, – ди талантлы дизайнер Уна Исламова, – гомер буе сәнгатьтә. Тәүлекнең күп сәгатьләрен киндерләр алдында үткәреп язылган картиналары, алар аша туган матурлык, чыннан да, күпләрне, аеруча хатын-кызларны әсәрләндерә».

Фәния Исламованың төсләр куелыгына, фон чуарлыгына, органикага һәм мәгънәви тирәнлеккә ия экспрессив әсәрләре ашкыну тулы заманны берникадәр вакытка гына туктатып, адәм балаларын: «Тирә-юньдәге табигатькә соклангыз! Җирдәге матурлыкка хозурлангыз! Тирә-юнегездән алган сихәтле нурларга шатлангыз! Аларны күрүегезгә, тоюыгызга шөкер итегез!» – дип искәртеп торалар кебек. Шуңа да Фәния Якуб кызының әлеге идеяләр белән сугарылган иҗаты күп еллар буе инде һәрвакыт тиешле биеклектә, актуаль һәм югары бәяләнә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА















ФӘНИЯ ИСЛАМОВА





«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:

ярты елга – П2204

бер елга – П8299



Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

1 сентябрьдән 2020 елның беренче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



Сайтта: www.syuyumbike.ru

ВКонтактеда: vk.com/suumbike

Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike

Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (теркәлеп) язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА